1926—1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН 2019 МАРТ № 3

СӨЕМБИКӘ

ISSN 0869-1398

УКЫТУЧЫ
остазмы, хезмәтчеме?

ЯРАТУ БЕЛӘН ЯШИ
ул гап-гади бозау караучы

ЯЗ ҖИТТЕ, КЫЗЛАР
бит тиресен тәрбиялибез

Ләйсән ВАҺАПОВА:

КӨЧЛЕЛӘР ЯРТЫ ЮЛДА КИРЕ БОРЫЛМЫЙ



Минем өчен син һаман да – 17дә!..

Минем өчен син һаман да – 17 дә!..

Бу фотосурәтләр еракта калган кабатланмас мизгелләргә – Яшьлеккә алып китә... ...Шундый зур галәмдә меңнәр арасыннан бер-береңне эзләп табу – үзе үк могҗиза! Аны күргәч кабынган хисләр – иң саф, иң ихлас, иң садә... Йөрәктәге сагышы да – якты, татлы, моңлы... Беренче очрашу... Аның кебек башка берәү дә юктыр! Дөнья – матур, яшәү шундый рәхәт! Очар өчен канатлар кирәкми дә!.. Ярату, йөрәккә генә сыялмыйча, җанда шигырь булып бөреләнә... Һәм мәңгегә Син – Шагыйрь, Ул Илһамчың булып кала...



Мостай КӘРИМ

МИНЕ ТАГЫ ТАШЛАП КИТӘСЕҢ

«Мине тагы ташлап китәсең...» – дип
Боегасың озатып калганда.
Яшәп булмый гел кавышып кына
Походлы һәм даулы заманда.

Океаннарга чыкса кораблар да
Давыл үтеп, кайта ярына;
Корабларда китсәм кире кайтам
Туган илгә, синең янына.

Самолетлар алып менсә мине
Болытларның өске ягына,
Вакыт җиткәч, тагы җиргә төшәм,
Җиргә, димәк, синең янына.

Кайда булсам да, мин илем белән
Һәрбер сулышымны алганда, –
Син дә шушы илнең кызысың бит,
Боекмачы озатып калганда.

Рәсемдә: шагыйрьнең хатыны Рауза ханым. 1949 ел.

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2019

1926 елдан башлап «Азат хатын» исеме белән чыкты. 1991 елда «Сөембикә» итеп үзгәртелде. Хатын-кызларның бөтентатар айлык әдәби-нәфис журналы 1913–1918 елларда чыккан «Сөембикә» журналының дәвамчысы.

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электронное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кульязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.

03’2019

Бәйрәмебез котлы булсын!

Фото: www.pixabay.com

Җитәкче-баш мөхәррир
Г.И. САБИРОВА

Редколлегия:
Зилә Вәлиева, Нурия Вәлиева, Искәндәр Гыйләҗев, Нәбирә Гыйматдинова, Айрат Зарипов, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Нурия Һашимова, Гөлназ Шәйхи, Рафаэль Шәвәлиев, Равилә Шәйдуллина, Лотфулла Шәфигуллин.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77

Җитәкче урынбасары 222-09-78
Рәмзия Кашапова
Баш мөхәррир урынбасары 222-09-78
Гөлнур Хәсәншина
Җаваплы сәркатип
Лариса Маликова
Әдәби мөхәррир
Эльмира Закирова
Сайт мөхәррирләре:
Сөмбел Гаффарова
Камилә Димөхәммәтова

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Тышлыкта:
Ләйсән Ваһапова
Фото: Игорь Глазырин

Верстка:
Лариса Маликова

Бүлек мөхәррирләре:
Чулпан Галиәхмәтова
Лилия Гәрәева
Эльмира Закирова
Ландыш Әбүдәрова
Фотокорреспондент
Анна Арахамия
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Гамәли хезмәткәрләр:
Нәфисә Әскәрова
Олег Сердюк

Формат: 225x290 мм
Күләме 64 бит

Басарга кул куелды: 08.02.2019 ел
Заказ О-480
Тираж 5156

Учредитель: Акционерное общество «Татмедиа»



ТР «Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77

Язылу индексы:
П2204 (ПАП рәсми каталогы буенча)
73002 («Роспечать» каталогы буенча)

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикә»
Расч/счет 40702810600020010309
кор/сч 30101810000000000805
в ПАО «АК БАРС» БАНК г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205805
КПП 165802002





Баш мөхәррир сүзе




Елның һәр көне 8 Март булуын телим! Юк, чәчәк, бүләкләр алу өчен түгел, хикмәт башкада. Журналыбызның март санын басарга тапшырыр алдыннан кабат һәр язманы карап чыктым да, безнең героиняларыбызның һәр көнне игътибар һәм назга төренеп яшәргә лаек икәнлегенә инандым (хәер, һәр ай ахырында шундый хисләр кичерәм...).
Әнә бит нинди алар: һәркайсы (!) чибәр, үзләре акыллы, үзләре тырыш, нинди генә сынаулар узсалар да, рух ныклыгын һәм тормышка ышанычын югалтмаган. Ә ни өчен алар (һәм без!) матур сүз, комплимент ишетү, күбрәк игътибар алу өчен 8 Мартны көтәргә тиеш?! Үзегез яулап алган тигез хокуклылык, ирләр белән бер рәттә булырга тырышуның нәтиҗәсе дияр кайберәүләр. Анысы да бардыр, паровоздан алда чабарга тырышучыларыбыз да җитәрлек. Әмма нинди генә булсак та, без – хатын-кыз. Елмаер, рухланыр, рухландырыр өчен безгә янәшәдәгеләрнең җылысын һәм мәхәббәтен тою кирәк. Ә бу бит һич тә авыр түгел...

Яратып,
Гөлнара САБИРОВА


Фото: Газинур Хафизов

Безнең тышлыкта



«Җитәкче кеше һәркемгә ачык булырга тиеш дип саныйм.»

10



«Барысына да өлгерергә телим!..»
Гөлнур Сафиуллина

Заман һәм без

6 Укытучы — остазмы, хезмәтчеме?
Чулпан Галиәхмәтова



Бәбиләр арзан тормый 14
Альбина Гыйльметдинова



18 Ярату белән яши
Ландыш Әбүдәрова

Гашыйк булу — сәламәтлек билгесе 22
Рафаэль Шәвәлиевнең тормыш кагыйдәләрен
Гөлнур Сафиуллина язып алды


Татар дөньясы

26 И мөкаддәс моңлы сазым...
Марат Әмирханов



30 Татар феминизмы-2
Ландыш Әбүдәрова

Мәдәни тормыш



38 Көтеп алган бәхет
Ралия КӘРИМОВА

Яшәеш




44 «Без аерылышмас идек...»
Гөлнур Сафиуллина



48 Балан ачылары
Лилия Гәрәева

Хатын-кыз галәме

58 Ак, борчак, плиссе – язгы мода быел шундый



60 Тжвжик – әрмән ашы



УКЫТУЧЫ – ОСТАЗМЫ, ХЕЗМӘТЧЕМЕ?



Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА

Мәктәп... Барыбыз өчен дә таныш һәм кадерле сүз. Кемнең хатирәләре нindiдер, миндә ул еллар гадилек, ихласлык, матурлык хисләре уята. Укытучыларга карата хөрмәт, алардан мактау сүзләре ишетергә теләп тырышып укулар, өй эшен эшләмәгән өчен бастырып шелтәләгәндә, башны иеп, мышык-мышык борын тартып торулар, дәрестә шукланып утырган өчен укытучы абыйның малайларның колак очларына тияр-тимәс кенә итеп акбур атып җибәрүләре, йә күрсәткеч таягының баш түбәсендә уйнап торуы... Мондый «тәрбия чаралары» дәрес тәмамланганчы ук онытыла иде. Сөйләп йөрү, йә булмаса әти-әнигә кайтып әләкләшү уйда да булмады. Хәзер, үз балаларыбыз мәктәптә укый башлагач, бөтенләй башка вазгыятьне күреп шаккатабыз. Җәмгыять кансызланган саен, мәктәпләргә карата да ихтирам бетеп бара. Бөтенроссия җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү үзәге мәгълүматына караганда, сораштырылганнарның 42 проценты укытучыларның абруе югала дип уйлый. Моңа кем гаепле?

Мәктәпкә ирек кергәч...

Соңгы айларда республикада атна саен диярлек мәктәп белән бәйле күңелсез вакыйгалар ишетелде. Чаллыда бер укучыны ашханәгә кертмичә тупас рәвештә борып җибәрәләр; Бөгелмәдә тактага начар мәгънәдәге сүз язган укучыга укытучы: «Хайван, кирәк кешене җәлеп итеп, гарип калдыртам», – дип яный; Казан мәктәпләренең берсендә сынау рәвешендә бирелгән БДИда математикадан өч балл җыйган кызны укытучы тозлап-борычлап әрли...

Эльза Нәбиуллина сигез ел мәктәптә эшли. Казандагы Дәрвишләр бистәсендәге мәктәпне тәмамлаган укытучы: «Элек тә андый конфликтлар булды, хәтта сугышуга кадәр барып җитә иделәр. Ул заманда укытучылар кул да күтәрделәр, ләкин бервакытта да мәктәптәге низаг киң җәмәгатьчелеккә чыкмады», – дип искә ала.

– Хәзер мәгълүмат кыры ачык. Һәр кешенең кулында гаджет булу да кулай. Ирек дигән төшенчә зур бүгенге җәмгыятьтә, тик аны да дөрес куллана белү генә юк. Тагын бер үзенчәлекне онытмыйк: үсмерләр үзләренә игътибар итүне ярата. Аны исә нинди дә булса бер «шартлау» – бөтен кеше-нең котын ала торган очрак белән генә яулап була дип саныйлар. Моннан кала, хәзер 80–90 нчы ел балалары да үсеп, әти-әни булдылар. Алар үзем рәтле тәрбия күрмәдем, балама бирим, дип фикер йөртә: һәрьяклап сакларга, якларга тырыша. Бу, үз чиратында, балага ирек куюга, кайчак теләсә нинди кыланмышларына ирек бирә, – ди укытучы. Шуңа да дәрес көрәш кырына әйләнде хәзер. Әле бит укытучыларның бетмәстөкәнмәс кәгазь эшләре җитәрлек...

Ләйсән Касыймова кызларына яхшы белем бирү өчен берничә мәктәп алыштырган. Шәхси белем бирү учреждениеләрендә дә укып караганнар. Хәзерге көндә өйдә балаларын үзе укыта. Аның укытучыларга дәгъвасы юк, укыту системасы дөрес түгел, ди. Мәктәптән кызларын алырга уйлагач, мөгаллимнәр үзләре үк аның бу адымын хуплаган. «Кәгазь эшләре күп булганлыктан, балаларга игътибарыбыз аз кала, аларга бөтен көчебезне бирә алмыйбыз», – дигәннәр. Дөрестән дә, төрле рейтинглар артыннан куа торгач, тәрбия эшләренә вакыт аз калды хәзер мәктәпләрдә. Укучы белән укытучы арасында, ни кызганыч, ихласлык, ышаныч дигән төшенчәләр юкка чыгып бара. Кара-каршы утырып сөйләшүләр юк диярлек. Ә бит бер-береңнең ышанычын яулау өчен иң элек аралашу зарур. Бәлки, балалар белән эшләү өчен сыйныф остазлары штаты булдыру кирәктер... Әмма бу фикер хәзерге оптимизация заманында утопия кебек тоела.



Фото: https://edu.gov.ru

Россия мәгариф министры Ольга ВАСИЛЬЕВА:
«Кайчак сез дә, мин дә укытучылар белән ата-аналар арасындагы низагның шаһиты булабыз. Иң аянычы шунда: әлеге конфликтларга балалар да җәлеп ителә. Ә бу укытучының абруен төшерә, балаларга дөрес булмаган үрнәк бирә».

Укытучы алҗыймы?

Дәүләт Думасы депутаты Борис Чернышов укытучыларга биш ел эшләгән саен бер ел түләүле ял бирү тәкъдиме белән чыкты. Ул моны һөнәри яктан арып китмәсеннәр өчен кирәк дип саный. Казан федераль университетының психология институты хезмәткәрләре җиде ел эшләгәннән соң, укытучының алҗый башлаганын ачыклаган. (Сүз уңаеннан: профилактика җәһәтеннән, махсус программа эшләнеп, реестрга да кертелә, тик гамәлгә ашырылмый.) Укытучыларга ярдәм итү өчен махсус психолог кабинетлары да юк. Мәгариф министрлыгының өстәмә һөнәри белем бирү бүлеге җитәкчесе Роза Шәяхмәтова әйткәнчә, алар өч елга бер тапкыр белемнәрен арттырганда махсус курслар узалар узуын... Һәм шуның белән шул... Мәктәптә килеп туган низаглар вакытында укытучы ялгызы гына кала, димәк. Ярый ла мәктәп җитәкчелеге аны яклап чыкса. Менә шушындый психологик басым вакытында кирәк бит инде аңа ярдәм! Психологик ярдәм хезмәтләре булдыру мәгариф өлкәсендә ил күләмендә гамәлгә ашырыла торган проектка кертелгән кертелүен. Тик мәктәп психологлары әлегә укытучыларга түгел, укучыларга да җитми. Оптимизация вакытында аларның штаты кыскартылып бетте.

«Укучылар – укытучының көзгесе», – ди Татьяна Анисимова. Кызы башлангыч сыйныфны тәмамлаганда, укытучы булырга карар кыла ул. 40 тан соң тормыш башлана дигән сүз – аның турында. Үз профессиясенә җәмгыятьтә ихтыяҗ бетә, дип, янә укый башлый. «Укытучы һөнәре дөнья ничек үзгәрсә дә актуаль булачак. Шуңа да сайладым», – дип аңлата үзенең бу адымын.

Мәктәптә педпрактика үткәндә укучы белән укытучылар мөнәсәбәтенә тормыш тәҗрибәсе булган кеше күзлегеннән чыгып карый.

– Үзен лаеклы тоткан, кисәтүне дә кат-кат түгел, бер генә тапкыр ясап, шунда ук оныткан укытучыны укучылар хөрмәт итә. Ә менә авторитар режим яраткан мөгаллимәләрнең дәресендә мин үземне бомба өстендә утырган кебек хис итәм. Ул кычкыра башлый икән,

укучылар тыңламый, дәресне өзәргә тели. Алар үзләренә тавыш күтәргәнне онытмый, укытучының башка дәресендә дә «үч алырга» тырыша. Күп кенә укытучылар өй эше эшләнмәгән өчен әрли башлый. Аңламыйм, ник тиккә үзеңнең дә, балаларның да нервыларын бозарга. Көндәлегенә «икеле» билгесе куйсаң, күпкә нәтиҗәлерәк бит. Ата-аналар күрә, балаларга да бу бик зур стимул. Ләкин ул билге гаделле булырга тиеш. Кызымның инглиз теле укытучысы бер тапкыр бөтен сыйныфка «икеле» куйды. Хәзер иң элек инглиз теле буенча өй эшенә тотына балалар. Укытучының да абруе артты, ул бик таләпчән булса да, балалар аңа тартыла. Чөнки ул баланың шәхесен түбәнсетми, бары тик «икеле» куя, дәрес вакытында алар белән бер дәрәҗәдә сөйләшә. Кызганыч, класс җитәкчеләре андый булмады. Аңа балалар алдында: «Синең чалбар изүең төшкән», – дип кисәтү ясау, йә: «Бу кофтаңны нинди йолкыштан алдың?» – дип әйтү берни тормый. Шуңа да балалар укытучыларын яратмый гына түгел, күралмый. Ә аларны әз генә булса да яратмыйсың икән, мәктәпкә бару түгел, ул якка борылып та карама, ди институттагы остазларым. Әйе, килешәм, хәзер балалар төрле, алар белән бик авыр. Ләкин укытучы шәхес буларак бәхетле икән, ул моңа күз йома, бер кат кисәтү ясый да оныта. Ә тормышында авырлыклар күп булганнар балаларның бөтен шуклыгын күңеленә җыя-җыя да... шартлый. Без исә ачуны, нигездә, үзебездән көчсезрәкләрдән алабыз. Мәктәптә иң көчсез кешеләр – балалар. Мин педагогиканы өйрәнү, мәктәптәге хәлләрне күзәтү барышында аңладым: балалар белән бертигез дәрәҗәдә аралашырга кирәк икән. Шул вакытта гына үзара хөрмәт туачак, – ди Татьяна.

– Ата-аналарның укытучыларга карата соравы мәгълүмат җитмәгәннән туа, – ди Роза Шаяхмәтова. – Шуңа иң элек мөгаллимнәргә ата-аналар белән тыгыз элемтә урнаштырырга киңәш итeлә. Соңгылары «балам гына хаклы» дигән позициядә тормаса ярый да... Тик, инде әйтелгәнчә, хәзер бала культы көчле. Әти-әниләр үзләре үк укытучыларның дәрәҗәләрен төшерүгә өлеш кертә. Атасы хөрмәт итмәгән укытучыны баласы ничек хөрмәт итсен?! Россия мәгариф министры Ольга Васильева тикмәгә генә ата-аналарга гаиләдә укытучыларны тикшерүне тыярга киңәш итмәде инде. Министр фикеренчә, бу мөгаллимнең абруен төшерә.

Хезмәт күрсәтүме, әллә хезмәт итүме?

Дөрестән дә, элек ата-аналар мөгаллимгә тирән хөрмәт белән карый иде. Ул алар өчен тәрбияче, остаз булды, «укытучы һәрвакыт хаклы», дип кенә әйтәләр иде.

– Хәзер мәктәптә белем бирү һәм тәрбия эшләре бүленде. Федераль канун нигезендә, белем бирү хезмәт күрсәтү категориясенә керде, – ди Татарстан укытучылары профсоюзы җитәкчесе Юрий Прохоров.

Димәк, укытучы хезмәтче булып чыга?! Әти-әниләр исә үзләрен иң яхшы мөгаллим дип саный. Баласының өлгереше буенча сораулар туа икән, дөрес укытмыйсыз дип әйтергә дә күп сорап тормыйлар. «Ә бит алар методиканы бөтенләй белми. Укытучы артыгын таләп итә дип уйлый, менә шуннан конфликт килеп чыга инде», – дип аңлата Юрий Прохоров.

Укытучылар абруена... бердәм дәүләт имтиханнары да шактый ник сукты. Ата-аналар югары уку

СОРАУ–ҖАВАП

Казан шәһәре мәктәпләренең берсендә укучылар арасында сораштыру үткәрдек. «Бүгенге укытучы нинди сыйфатларга ия булырга тиеш?» дигән сорауга аноним җавап бирде алар. Шулай итеп:

УКЫТУЧЫ ИҢ ЭЛЕК ДУС БУЛЫРГА ТИЕШ! Сораштыруда катнашкан һәр бала шуны тели. Ул уртак тел дә таба белсен, хәлгә дә керсен. Мәктәптә иң мөһиме – укытучы белән үзара аңлашып яшәргә кирәк дип саный укучылар.

Ә моның өчен укытучының **ҮЗЕН ҺӘМ ТИРӘЯГЫНДАГЫЛАРНЫ ХӨРМӘТ ИТҮЕ ЗАРУР**. Укучылар моңа да игътибар итә икән!

УКЫТУЧЫ ҮЗ ФӘНЕН ТИРӘНТЕН БЕЛЕРГӘ ГЕНӘ ТҮГЕЛ, АНЫ УКУЧЫЛАРГА ҖИТКЕРӘ, КЫЗЫКЛЫ ИТЕП АҢЛАТА ДА БЕЛЕРГӘ ДӘ ТИЕШ. Кызганыч, хәзер бик күп мәктәпләрдә укучы теманы өйдә аңлап килә дә, мәктәптә аның үзләштерү дәрәҗәсе тикшерелә дигән сәясәт алып барыла. Күрәсез: укучылар моның белән риза түгел.

САБЫРЛЫК! Сораштыруда катнашкан һәр бала аны укытучыда булырга тиешле иң кирәкле сыйфат дип исәпли.

УКЫТУЧЫ ҺӘР БАЛАГА ТИГЕЗ КАРАСЫН ҺӘМ ГАДЕЛ БУЛСЫН. Объектив бәя бирү бик авыр, әлбәттә. Мәктәптә бит укучының әти-әнисенең социаль хәле, брендлы киеме түгел, ә белеме бәяләнә.

УКУЧЫЛАРНЫҢ ҮЗЛӘРЕН ШӘХЕС ИТЕП ТАНЫТАСЫ, ФИКЕРЛӘРЕ БЕЛӘН УРТАКЛАШАСЫ, ДИСКУССИЯ АЛЫП БАРАСЫ КИЛӘ. Җаваплар арасында менә шушындый юллар бар: «Әгәр укытучы укыту программасын аны тыңламыйча, аңа сүз бирмичә алып бара икән, ул чын укытучы була алмый. Бу – әхлакый сыйфатлар юклыгы хакында сөйли...»

йортына керү өчен мәктәптә алган белем генә җитми, репетиторлар ялларга кирәк дип зарлана. Ә репетиторлар – шул ук укытучылар. Алар хезмәтен ата-ана сатып ала. «Әгәр укытучы, яхшы билгеләр аласыгыз килсә, репетитор эзләгез, дип әйтә икән, ул үзе дә сизмичә абруен төшерә», – ди Юрий Прохоров. Әлеге кәсеп укытучыларга бер-берсенә акча эшләү мөмкинлеге ачты. Ни аяныч, кайберләре мин репетиторлык белән күбрәк эшлим, дип әйтергә дә уңайсызланмый.

Тормыш булгач, акчасы да кирәк билгеле. Республика укытучылары арасында бер ставка гына алып, эшен сыйфатлы итеп башкарганнар 5 процент тирәсе генә. Болар – бай тормышта яшәүчеләр. Калганнары ирләре белән бергә тормыш арбасын тарта: ипотека, кредит түлиләр. 10 проценты, гомумән, мохтаҗлыкта яши. Араларында ялгыз аналар да бар. Тамак туйдырыр өчен берничә ставкада да эшли, кичләрен репетиторлык хезмәтенә дә алына. Ә алҗыган укытучы балаларга нинди тулы белем бирә алсын?! Мәктәпкә кәефсез килгән укытучыга балалар каршында дәрес үткәрү өчен иң элек үзенә ярдәм кирәк. Җитмәсә, балалар да кансызлана бара. Укытучыны соңгы чиккә җиткерүдән дә тайчанмыйлар.

– Бандитлык чәчәк аткан 90 нчы елларда авыр балалар белән эшләргә мәктәпләрдә оешкан аталар шурасы ярдәм итә иде, – дип искә ала Юрий Прохоров. – Алар бик актив иде. Тәртип бозган баланың ата-анасы белән барып сөйләштеләр. Алары, үз чиратында, мәктәпкә килеп: «Юрий Петрович, акылга утыртыр өчен кундырып ала белмисезмени?» – дип әйтә иде. Ә хәзер балаларга тиеп китү түгел, тавыш күтәрергә дә ярамый.

Укытучының илһам чыганагы кайда?

– Әгәр укытучы – үз эшенең остасы, фәнен югары дәрәҗәдә белә һәм дәресне мавыктыргыч итеп үткәрә икән, ул үзеннән-үзе балаларда хөрмәт уята, – ди Казандагы Лобачевский исемендәге лицей директорының тәрбия эшләре буенча урынбасары Олег Романенко.

Укучыларга шәхес итеп карау – уңай яктан гына даны таралган лицейның уңыш серен әнә шулай аңлата ул. Мондый укытучылар өчен укучылар илһам чыганагы. Бу лицейда һәр бала – шәхес, барысы да индивидуаль, шуңа күрә дә анда укучыларны бервакытта да бер-берсе белән чагыштырмыйлар. Шәхес-укучылар иркле фикер йөртә ала. Аңа фикерен әйтергә, үз сүзен яклап чыгарга мәйдан бирелә.

Олег Романенко сүзләренчә, лицейда укытучылар кайбер очракларда үзләренең тиешле дәрәҗәдә компетентлы булмавын да таныйлар, аерым бер мәсьәләләрдә балаларның үзләренә караганда камилрәк булуларын әйтергә оялмыйлар. «Менә шушындый хөрмәт үзара җылы мөнәсәбәтләрне сакларга ярдәм итә», – ди укытучы. Фәннәрне тирәнтен өйрәнгән лицей белән гади мәктәп сәясәтен чагыштыру дөрес түгел диярсез. Тик мәктәп тә бит белем бирү йорты. Анда да балалар укый. Аларның барысында да табигать биргән талант бар. Аны ача белергә генә кирәк. Ә ул әзерлек, көч, вакыт һәм балаларны ярату таләп итә. Моның өчен иң элек укытучыларга дәүләт мөмкинлекләр тудырырга тиеш. Ә бүген укытучы кем? Кирәк вакытта – зур төзелештә эшләүче, имза җыючы, кәгазь тутыручы, эштән соң йөгерә-йөгерә укучы өенә килеп бердәм дәүләт имтиханнарына әзерләтүче... Гомумән, мәктәбе дә – гомер буена кирәкле кыйммәтләргә нигез салына торган урын түгел, ә бердәм дәүләт имтиханнарына әзерләнү мәйданына әйләнә бара. Моны күрепбелеп торган тук балаларда укытучыга карата тирән хөрмәт уяну икеле...



Психология фәннәре кандидаты, КФУның психология һәм белем бирү институтының педагогик психология кафедрасы доценты Резеда ХӨСӘЕНОВА:

– Укытучы һөнәре соңгы елларда үзгәрешләр кичерергә мәҗбүр. Үз фәнеңне камил белүдән тыш, бала һәм ата-ана күз алдында абруен күтәрер өчен, мөгаллим һөнәри яктан бик тә мөһим сыйфатларга ия булырга тиеш. Ул укучы белән нәтиҗәле мөгамәлә кору, аралашу барышында килеп чыккан эмоциональ киеренкелекне бетерү, коткыларга бирелмәскә өйрәнү, шул ук вакытта балага психологик ярдәм дә күрсәтә алудан гыйбарәт. Әлеге осталыкларга вузда өйрәтмиләр. Ул тәҗрибә белән килә. Шуңа күрә укытучыга уңыш казаныр өчен һәрвакыт белемен арттыру, психологик һәм физик яктан сәламәтлеген кайгыртып тору зарур. Безнең тикшеренүләр күрсәткәнчә, беренче җиде ел эшләү дәверендә әле укытучының психологик халәте яхшы. Ә менә педагогик стаж арткан саен, һөнәри яктан ару билгеләре күренә башлый. Бу исә стресс туган очракларда укытучының үз-үзен тотышына да тәэсир итми калмый. Соңгы елларда уздырылган тикшеренүләр укытучыларга психологик ярдәм кирәклеген күрсәтә. Мәктәптә уналты ел һәм аннан да күбрәк эшләгәннәр өчен ул аеруча зарур. Вузлардагы тренинг үзәкләре эше укытучының психологик иминлеген тернәкләндерергә ярдәм итә. Тик мондый эш ихтыяҗ туганда гына оештырыла.

«Барысына да өлгерергә телим!..»





Гөлнур САФИУЛЛИНА

Лидер хатын-кыз ул нинди булырга тиеш? Башкаларны үз артыннан ияртү өчен нинди сыйфатларга ия булу кирәк? Беренче урында нәрсә тора: тирә-юньдәгеләр белән уртак тел таба белүме, әллә җаваплылык хисеме? Стрессларга каршы тора алу сәләтеме, әллә мөһим карарларны икеләнмичә кабул итә белүме? Бәлки башкалардан бер адым алда атлаудыр? Үз алдыңа куйган максатлардан беркайчан баш тартмау, үҗәтлек һәм тырышлыктыр? Әллә бүгенге көндә иң беренче урынга куела торган сыйфатларны үзеңдә үстерү – креатив һәм позитив булумы? «Ел хатын-кызы. Ел ир-аты: хатын-кыз карашы» республика бәйгесенең Зәйдә узган зона турында «Хатын-кыз – лидер» номинациясендә җиңү яулаган Россия Пенсия фонды Азнакай районы идарәсе башлыгы Ләйсән ВАҺАПОВА белән шул хакта сөйләшәбез.

– Бер генә хатын-кыз да бер көндә лидер булмый, – ди ул. – Моңа ирешү өчен баскыч арты баскыч күтәреләсең. Бар яктан да уңышка ирешкән хатын-кызны гына лидер дип атап буладыр.

Мин аның белән берсүзсез килешәм.

Каршымда – шундый гүзәл затларның берсе.

Яратканыңны гына эшләргә, ә эшләгәнеңне яратырга кирәк.

Балачак

Илдар абый белән Рәзимә апа икенче балаларын тууга югалталар. Аннан көттереп кенә кызлары дөньяга килә. Өмет бар да, юк та... Казан табибларына күренеп тору өчен йөкле килеш һәр ай саен Азнакайдан Казанга очкан әнисе тагын тоташ бер атна ут эчендә була әле: яңа туган кызчыкка җиде көн рәттән кан салалар. Һәм, ниһаять, сөенечле яңалык: резус фактор – уңай, димәк, антитәнчекләр барлыкка килмәячәк! Яшәячәк! («Мин бит инде юкка гына исән калмаган, – дип елмая Ләйсән. – Бу Җирдә, димәк, үз миссиям бар, ниндидер бер эз калдырып китәргә тиешмен...»)

Балачакның иң якты хатирәсе – туганнар белән очрашулар. Бәйрәкә авылының атаклы Латыйповлар нәселе баласы ул. Көчле нәсел! Алардан кыз алган егетләр дә Латыйповларга тиңләшергә, алар кебек үрнәк гаилә башлыгы булырга юкка гына тырышмый!

– Әтиләр алтау үскән – ике кыз, дүрт егет. Әни ягы да ишле. Ике як та шулкадәр тату иде! Бәйрәкәдә, Сәетнур бабай белән Зәкия әбиебез нигезен саклаучы Илгизәр абый гаиләсендә җыелышуларыбыз – иң рәхәт чаклар. Туганлык хисе күңелгә шул чакта ук салынгандыр дип уйлыйм. Канда инде ул безнең... Башкалар дуслары белән очраша, ә без туганнар белән! Туган көннәргә, бер өндәүсез, утызар кеше җыелабыз һәм һаман арта барабыз! Казанда – Тәфтил абый, Илсөяр апа, Рәшидә апалар, Әлмәттә – Айдар абый, Мәүзирә апа, Чаллыда – Мәүзир абый... Алар инде күбесе олылар, кемдер инде сиксәнгә үк якынлашып килә. Тик шулкадәр тормышны яраталар! Яшәүдән нинди тәм, ямь алганнарын күреп исең китә. Кая ул елап-зарланып утыру! Әле менә җыелып, нәселебез тарихын яздылар, китап бастырып чыгардылар. Җиде буын бабаларыбызны бездә һәркем белә! Әти белән әни дә – «бүген, хәзер яшибез» диючеләрдән. Алар хәзер Уразай авылында торалар. Ишекләре ябылганы юк – аларда гел кеше. Әти лаеклы ялга чыккач умартачы булып китте. Блогер дисәң дә була аны хәзер: умарта карау буенча киңәшләре белән уртаклаша. Үзенең укучылары, шәкертләре бар. Без әтинең сөйләгәнен тыңларга яратабыз. Гел акыллы сүзләр, акыллы фикерләр аңарда. Аңа карыйм да: «Әти ничек җитәкче булып күтәрелмәгән?» – дип уйлыйм. Машина йөртте ул. Гаиләнең матди бөтенлеге аның өчен өстенрәк булган бугай. Элек гади эшче җитәкчедән күбрәк ала иде бит.

5 яшькә кадәр өйдә генә утыргач, иркә кыз булганмындыр инде... Тизрәк укырга өйрәнергә теләвемне, «Бу нинди хәреф? Бу нинди сүз?» – дип, гел әни артыннан калмый йөргәнемне хәтерлим. Бакчага баруга, балаларны үз тирәмә җыеп утыртып, аларга китап укый башладым...

Гомер буе озата барачак үгетнәсыйхәтләр дә – балачактан. Ләйсәндә дә бар алар. Әтисенең: «Кешегә соңгы сүзне беркайчан да әйтмә!» диюе, әнисенең: «Берәүгә дә үпкәләмә, үпкәләү бәхетсез итә», – дип кабатлавы. «Ә дини тәрбия – әниемнең әнисе Гадимә әбиемнән», – ди ул.

Уку еллары

– Кемнеңдер классташлар очрашуы оештыруын шундый озак көттем. Һәрвакыттагыча, миңа ышандылар бугай... Иртәнге алтыда Чатыр тауга күтәрелү белән тәмамланды ул. Ил буйлап таралган сыйныфташларның күбесен чакыртып кайтарта алдым. «Онытылмаслык булды», – диделәр... Мин һәрвакыт башкаларны үз артымнан ияртергә тырыштым. Бу мәктәптә дә шулай булды. Һәм ул минем килеп тә чыга иде! Һәр кешегә аерым ачкыч ярату кирәген ул чакта ук аңлаган идем инде...

Әмма Ләйсәннең оештыру сәләте Казан дәүләт авыл хуҗалыгы академиясендә укыган елларда күбрәк ачылгандыр. Студент елларында ул факультетның профсоюзлар бюросын җитәкли. «Татарстан Республикасы студентлар лигасы» президиумына сайлана. Тулай торакта студентлар советы рәисе була. (Студентлар шәһәрчегендә хәтта ашханә дә юклыгы күпләрдә канәгатьсезлек тудыргандыр. Әмма Ләйсән сүздә генә тукталмый. III курста укыганда, факультетның профсоюзлар бюросы рәисе буларак, ул бу катлаулы мәсьәләне гыйльми советта күтәрүгә ирешә. Проблема хәл ителә: диплом проектларын алар студентлар шәһәрчегендә урнашкан яңа кафеда яклыйлар!)

– Академиядә мин сайлаган юнәлеш шактый авыр иде: авыл хуҗалыгында транспорт һәм технология машиналарын, җиһазларны техник эксплуатацияләү һәм сервис. «Икътисад өлкәсенә генә күчмисеңме соң?» – дип әйтүчеләр дә булды. Ризалашмадым! Холкым андый түгел: бер башлаган эшне ахырга кадәр җиткерү, тәмамлау кирәк миңа. Ярты юлда кире борылуны көчсезлек дип саныйм. Хәзер менә «күчсәм дә яраган булыр иде», дип уйлыйм... Ә ул чакта: «Мин моны булдырам!» – дип, үз-үземә исбатларга кирәк иде.

Юрист булырга дигән теләгем дә бар иде. Дус кызым белән Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать институтына керергә дә хыялланып йөрдек. Тик ул елларда бу өлкәдә эшләүчеләрнең хезмәт хаклары бик аз иде бит – шул туктатты бугай. Тамада дигән яңа һөнәр килеп чыгасын кем белгән? Югыйсә мин анда

Мөһим эшләрне беренче урынга куя белергә кирәк:
нигә җиде көн рәттән идән юарга?

үземне судагы балык кебек хис итәр идем. Чөнки берара вокал белән дә шөгыльләндем. Анысы инде нәрсә эшләргә белмәгәннән... Кечкенә шәһәрдә күңелсез бит – үзеңә гел ниндидер шөгыль табарга кирәк. Һәм мин аны таба идем! Вакытны бушка үткәреп булмый лабаса... Җырлый башладым. Булат Җиһаншин, Салават Миңнеханов, Фирдүс Тямаевлар белән бергә «Народный артист» проектында катнаштым. Әмма мин шактый амбицияле кеше бугай: икенче Әлфия Афзалова дәрәҗәсенә җитә алмагач, дистәләгән җырчыларның берсе булу гына нигә кирәк дип санадым. Шактый күпертеп әйтәм инде, әмма үз көчеңне, үз мөмкинлекләреңне белү кирәк ул...

«Җиде йолдыз»ның кастингы аның... никахы белән бер көнгә туры килә. Барысын да Ходай үзе хәл итә, җыр – бер мавыгу гына, ә гаилә – гомерлек...

«Мин бу шәһәргә башка беркайчан кире кайтмыйм! Ул минем өчен артык тар!» дип, башкалага укырга чыгып киткән кызның, диплом алгач, Азнакайга әйләнеп кайтуын әйтмәдем бит әле. Дөрес, Казаннан әйберләрен дә җыймыйча, башта вакытлыча дип кенә кайту була ул. БТИга да «вакытлыча» дип кенә урнаша. Тормыш үзенә бөтереп ала... («Казанга барган чакларда группадашларым белән очраша идем. Хезмәт хаклары турында да сөйләшәбез. Баксаң, кызлар анда миннән ике тапкыр азрак ала икән. Алар белән күрешкәннән соң, шундый нәтиҗә ясадым: мөмкинлекләрем зуррак икән. Димәк, районда эшләүнең уңай яклары күбрәк дигән фикергә килдем».)

«Беркайчан» дигән сүзне бик саклык белән әйтә ул хәзер.

Эш

– Ишектән кергән һәркемне елмаеп каршыларга кирәк, – дим хезмәткәрләремә. – Бусаганы атлауга, аның кәефе төшсә, хәтта гозерен үтәгән очракта да ул инде эшебездән канәгать калмаячак. Идән юучыларга кадәр кагыла бу. Берсе ялгыш кына: «Яңа гына сөртеп чыгарган идем, йөрисез инде таптап», – дип әйтеп куйса да, клиентның йөзе үзгәрәчәк бит. Кешеләрне яратсагыз гына монда эшли аласыз, дип тә гел әйтеп торам. Әгәр яратмасам, мин үзем тәгаен бу урында булмас идем. Робот кебек кенә эшләп булмый бездә...

Ләйсән дөрес әйтә, фондның эше белән якыннан таныш булмаганнар, пенсия һәм картлык белән бәйле бер оешма дип кенә уйларга мөмкин алар турында. Тамырдан ялгыш фикер! Кеше тууга, Пенсия фонды идарәсе аңа СНИЛС бирә. Үсеп җитеп, эшли башлауга ул фондка пенсия түләүләрен күчерә башлый. Эш бирүче моны чынлап та тиешенчә башкарамы-юкмы икәнен, сайтка кереп, һәрдаим карап, тикшереп тора ала.

Ләйсән Ваһапова җитәкләгән Азнакай пенсия фонды идарәсе районның 21 меңгә якын пенсионерына хезмәт күрсәтә. Әледән-әле пенсия түләү белән бәйле үзгәрешләр кереп торуын, яңалыклар булуын искә алсаң, фондта эшләүче 47 хезмәткәрнең эше очсыз-кырыйсыз. Кайбер вакытта аларга бөтен районны диярлек кабат күздән уздырып чыгарга туры килә! Һәм санаулы көннәр эчендә!

– Берәүне дә: «Бу мәсьәләләрне мин чишмим, сезгә дигән вакытым бетте», – дип борып чыгарганым юк. Һичьюгы, андыйларга җайлап аңлатырга тырышам – шуңа да күңелләре була. Ишектән керәр әби керсә, аны үз әбием кебек хис итәм. Ул шундый хәлгә калса, гозерен дә тыңламыйча аны кире борып чыгарсалар? Әйе, ул әби миңа килгән. Дөрес тә килмәгән. Миңа түгел, аңа хәзер судка барырга кирәк. Андагы танышларыма шалтыратам: «Хәзер сезгә бер әби килә, кабул итегез, бүлмәдән бүлмәгә йөртмәгез, кулдан килгәнчә булышыгыз әле», – дим. (Ә алар, чынлап та, минем үз әбием дип уйлаган икән!) Җитәкче һәркемгә ачык булырга тиеш дип саныйм. Бу яктан безгә район башлыгыбыз Марсель Зөфәр улы Шәйдуллин – менә дигән үрнәк. Ул һәркем белән кул биреп исәнләшә, хәлен белә, проблемасы булса, шунда ук аны хәл итәргә тырыша. Кешеләр шуңа аңа тартыла да...

Ел дәвамында укучы яшьләрне пенсия грамотасына өйрәтү («Лекцияләр белән мәктәпләргә чыгабыз. СНИЛСның нәрсә икәнен, «чиста» хезмәт хакы нинди булырга тиешлеген уен рәвешендә аңлатабыз»); «Өченче яшь университеты»ның эшен оештыру («Яңа гына компьютерга өйрәнү курсларына йөрүчеләргә сертификатлар тапшырдык. Иң өлкән укучыга 82 яшь иде. Актүбәдә дә, Чалпы авылында да эшләде андый курслар. Кызганыч, бөтен авылда да компьютер класслары юк шул»); ай саен өлкәннәр өчен хокукый ярдәм көне үткәрү («Мәгълүмат күбрәк биргән саен, сораулар азая. Соңгы өч елда аңлату эшләре алып бару күрсәткече буенча без республикада беренче»); балалар өчен «Ачык ишекләр» көне оештыру; район уздырган барлык хәйрия чараларында, спорт ярышларында катнашу... Боз тавының күренеп торган һәм күренмәгән өлеше булган кебек, башкалар уйга да кертмәгән эшләре бихисап аларның.

Ләйсән Ваһапова өч ел элек идарәне кабул итеп алганда, республика буенча алар утыз сигезенче урында була. Яңа гына бик күп күрсәткечләрне эченә алган рейтинг игълан ителде: узган елгы нәтиҗәләр буенча азнакайлылар унберенче урынга күтәрелгән. «Без әкрен генә, әмма ышанычлы адымнар белән алга барабыз. Бөтен коллективның уңышы бу», – дип сөенә җитәкчеләре.

Гаилә

– Нигәдер Рөстәмнең күзенә карап: «Син бит әле яшь», – дия алмадым... Башкаларга: «Үсеп кил әле башта», – дигәнем булды югыйсә. Ә аның ышанычлы икәнен беренче очрашуда ук тойдым. Сүзләре белән түгел (ул, гомумән, аз сүзле), эшләре белән үзенә каратты мине. Дүрт яшькә кече икәнен онытытым...

Казанда, егетләр генә укыган механика факультетында белем алган Ләйсән булачак ирен... үзенең Азнакаенда очрата. Очраклы рәвештә генә бер туган көнгә барып эләгә ул. Аңа «очраклы» кебек тоела, ә чынлыкта күктә инде никах укылган була... Икенче көнне үк Рөстәм аның телефонына шалтырата, кичкә инде эшеннән каршы ала. Танышуларына бер ел дигәндә никах укыталар. («Ул кешенең синеке икәнен аңлагач, нигә кавышуны озакка сузарга?!»)

Ире – тормыштагы иң зур таянычы аның. Ләйсән аның хакында күп сөйләми. (Бәхет турында кычкырып сөйлиләр димени?!)

– Рөстәм миңа терәк булмаса, эшемдә бүгенге нәтиҗәләргә ирешә дә алмас идем. Гомумән, аның белән булмас идем... Минем бит канатларымны бәйләргә ярамый. Идеяләремне тормышка ашыру өчен иркенлек кирәк. Бер генә кыз баланы да кемгәдер хезмәтче булсын өчен үстермиләрдер. Рөстәм дә моны башта ук аңлады. Моның матур үрнәге гел күз алдымда булды: әти белән әни гомер буе бер-берсенә ышанып яшәделәр.

Беренче мәлдә эштә кичке сәгать сигезгә-тугызларга кадәр утырган чакларым булды. Законнарны өйрәнеп чыгарга кирәк иде бит. Хәер, бездә яңалыклар, әйткәнемчә, гел булып тора. Әмма мин барысына да өлгерергә тырышам. Иртәрәк кайтса, Рөстәм дә пешерә анысы. Тик аңарга гына салыну дөрес булмас иде. Аннан, якыннарымны сөендерү үземә дә ошый. Тотынам икән, десертларым иң тәмлесе килеп чыга. Туңдырма да ясыйм. Тозлы карамель, капкейк, чизкейк... Ял саен коймак бездә: сыр, анар һәм эремчек яки туңдырма белән. Тел йотарлык тәмле булалар.



Сере нидәме? Белмим! Дус кызлар: «Синең табаң үзгә бугай!» – дип көләләр... Безнең нәселдә бар да шулай тәмле пешерә. Гомумән, нәрсәгә тотынсалар да – өй салаларымы, умарта тоталармы – безнекеләр булдыра. Матурлык яратам! Аш бүлмәсендә чәчәкләр тотарга. Матур чынаяктан чәй эчәргә, кичке ашны матур савыт-сабадан ашарга. Гап-гади ризыкларны да матур итеп бизәп куярга... Күзләрне сөендерергә! Балаларны да шуңа өйрәтәм.

Рөстәм белән Ләйсән ике кыз үстерәләр – Дәлилә белән Даяна. Кызлар икесе дә әниләренә охшаган. Һәркайда беренче булырга теләү ягыннан диюем. Икесе дә музыка мәктәбендә укый. Икесе дә вокал белән шөгыльләнә, әниләре кебек үк бадминтонга да йөриләр.

Бадминтон дигәннән. Аның белән Ләйсән фондка эшкә килгәч кенә чын-чынлап кызыксына башлаган әле. Ошый аңа спортның бу төре! Узган ел әнә район буенча оештырылган чемпионатта инде беренче урынны алган. Хәер, йөгерергә дә ярата ул: «Милләтләр кроссы»нда инде ике ел рәттән районда хатын-кызлар арасында беренче урынны яулаган.

– Районыбызда спортка бик зур игътибар бирелә, без дә читтә калмыйбыз. Волейбол командабыз да бар. Башлап йөрмәсәм, кызларны анда ничек тартасың?! Спорт белән шөгыльләнеп кайткач, көзгедә үзеңә ошый башлыйсың... Ярыш белән бәйле уеннарны яратам. Тик спорт белән кечкенәдән мавыкмагач, җиңелүне авыр кичерәм. Җиңелә белмим – моңа өйрәнмәгән. Эштә рейтингтан аз гына аска төшеп китсәк тә, бик борчылам. Барысын да йөрәк аша уздырам шул...

Саубуллашабыз. Ләйсән тренировкага ашыга – бүгенге киче бадминтон белән тәгәлләнергә тиеш. «Кайсы яхшырак икән, белмим, – ди ул. – Бер юнәлештә генә барып, бөтен көчеңне салып, шунда уңышка ирешүме, әллә берьюлы барысына да өлгерүме?»

Минемчә, ул инде бу сорауга җавап тапкан. Өлгерә бит әнә!

PRESSA



Безнең әниләргә тагын 20–30 елдан бала табу өчен акча түләргә кирәк була дисәләр, баскан җирдән егылып китәрләр иде, мөгаен. Бушка бәби табулар киләчәктә, гомумән, фантастика өлкәсенә күчеп бетәр кебек.

БӘБИЛӘР АРЗАН ТОРМЫЙ



Альбина ГЫЙЛЬМЕТДИНОВА

Элегрәк бала табу гадәти хәл булып саналса, бүген ул алдан шактый әзерлек, физик һәм матди яктан зур чыгымнар таләп итә торган вакыйгага әйләнде.

Мин дә кызымны түләүле шәхси бала табу йортында таптым. Ни өчен нәниебезнең нәкъ менә шунда тууын теләдек һәм, гомумән, бүгенге көндә бала табу күпмегә төшә – бу язма шушы сорауларга җавап эзләү дә.

Балага узуга, хатын-кыз алдында хәзер иң беренче сорау туа – кайда теркәлергә, ягъни учетка басарга? Ике вариант бар: яшәү адресы буенча хатын-кызлар консультациясендә яисә түләүле клиникада. Соңгылары хәзер Казанда бихисап. Ике якның да үз плюслары һәм минуслары бар. Түләүле клиникада синең өчен барлык уңайлыклар тудырылып, беренче урында синең мәнфәгатьләрең торса, хатын-кызлар консультациясендә син үзең әлеге оешманың шартларына буйсынырга мәҗбүр. Минем өчен иң үзәккә үткәне – су буе чиратлар булды. Хәзерге интернет заманында, әлбәттә, табибка алдан язылу мөмкинлеге бар. Ләкин алдан язылсаң да, язылмасаң да – чират барыбер булачак. «Безнең консультациядә бернинди чират та юк», – диючеләргә җавапны алдан ук биреп куям: сезгә, димәк, бәхет елмайган.

Һәрхәлдә, кайда – ничектер, ә безнең консультациядә һәрвакыт су буе чират. Эштән сорап китеп, табиб кабинеты ишек төбендә сәгатьләр буе керә алмыйча көтеп утыру – күпләр өчен рөхсәт ителмәслек күренеш хәзер. Бусы – беренчедән. Икенчедән, андый чиратта төчкерүче-йөткерүчеләр булмый калмый. Бигрәк тә йөклелек чоры кышкы-язгы вакытка туры килгән очракта, берничә сәгать шундыйлар янында утырсаң, авыру йоктыруың да ихтимал. Калдырырга урын булмагач, кайберәүләр чиратка кечкенә балалары белән килә (һәм еш кына алар арып елый башлый), кемдер, гомумән, чиратсыз керергә тырыша. Барысы да ашыга, барысы да каядыр соңга кала... Ә табибның ашыгасы юк – аның эш сәгате бара, өлгермисең икән – синең проблема: иртәгә иртәрәк килеп утыр. Чиратың җитеп, кабинетка үтә алсаң да, гел нидер килеп чыга: йә кичә биргән анализларыңны югалталар, йә карточкаңны таба алмый аптырыйлар... Бала көтүче хатын-кызның нерв системасына сынаулар җитәрлек монда.

Хатын-кызлар консультациясенең иң зур һәм, бәлки, бердәнбер плюсы – алар бушлай. Тик, мәсәлән, УЗИ шикелле мөһим процедураларны күпләр барыбер анда да түләп уза. Әмма дәүләтебез әлегә табиб консультацияләрен, анализларны бушка бирү мөмкинлеген тәэмин итә.

Ирем белән киңәшкәннән соң, учетка басу һәм даими рәвештә акушер-гинеколог күзәтүендә тору өчен түләүле клиниканы сайладык. Эштән еш сорап китеп йөри алмавым, район хатын-кызлар консультациясенең эш урыныннан шактый ерак урнашкан булуы әлеге карарны кабул итүдә хәлиткеч роль уйнады.

Түләүле клиникалар бала көтүче әниләргә бүген бик күп программалар тәкъдим итә. Әлеге программалар триместрлар буенча бүленгән, һәр программада нинди анализлар һәм процедуралар үтәргә кирәклеге, аларның бәяләре күрсәтелгән. Программаларның бәясе 40 меңнән башлап 140 мең сумга кадәр җитә. Мөмкинлегеңнән, кесәңнең калынлыгына карап сайлап алырга җайлаштырылган стандарт һәм киңәйтелгән пакетлар һәр түләүле клиникада диярлек бар.

Йөклелек чорымда бернинди кыенлыклар булмады, шуңа да карамастан, әлеге чорда тотылган чыгымнар 65 мең сумга җитте. Әйе, бу аз акча түгел. Тик барысы да бик уңайлы – чиратларсыз һәм тыныч узды. Бала көткән хатын-кыз өчен болар бик зур әһәмияткә ия, минемчә.

Тик тугыз ай узу белән генә эш тәгәлләнми, иң мөһиме алда бит әле – бәбине табу.

Нәрсәсе бар инде, бәби табу йортына барасың да, үзеңне табиблар кулына тапшырасың – шуның белән эшең бетте, дип уйлый идем элегрәк. Тик барысы да мин уйлаганча бик җиңел булып чыкмады.

Беренчедән, тагын шул ук сорау алга килеп баса: бушка табаргамы, әллә түләпме? Икенчедән, түләп табарга хәл итәсең икән – кем белән килешү төзергә?

Түләүле медицина яшәешебезнең барлык өлкәләренә дә керде инде.

Монда да вариантлар шактый. Кемдер – табиб, кемдер – акушерка, ә кемдер, гомумән, табарга барыбер ярдәм итәрләр, тугач, баланы әйбәтрәк карасыннар дип, педиатр-неонатолог белән төзи хәзер килешүне. Бәяләре төрле бала табу йортларында төрлечә: уртача 25–50 мең тирәсе...

Ирем белән киңәштек тә, балабызны түләп табарга кирәк дигән фикергә килдек. Моңа берничә танышыбызның шушы ук елны төрле тудыру йортларында бәбине бушлай табу тарихлары этәргеч булды. Берсенең сабыен вакуум белән тартып чыгарганнар (шуның аркасында улларына әллә никадәр вакыт хастаханәдә ятарга туры килде), икенчесен вакытында карамаганнар: балада гипоксия башланган, һәм аны тиз арада ярып алырга мәҗбүр булганнар. Әле ярый сабый исән калды... Тагын бер танышыбыз өч көн дәвамында тулгак белән тилмереп ятты, ахырда барыбер ярып алдылар... Чәчләр үрә торырлык! Бу бит XXI гасырда! Әлеге һәм башка мисалларны ишеткән саен, бушлай медицинага карата негатив мөнәсәбәтем үсә барды. Тугыз ай буе күтәргән, өметләнеп көткән сабыен, туар вакыты җиткәч кенә, куркыныч астына кемнең куясы килер икән? Бәлки, минем белән бу хәлләрнең берсе дә килеп тә чыкмаган булыр иде дә, тик кем белә... Кеше гомерендә бары бер яки берничә тапкыр гына кабатлана торган мондый сөенечле вакыйга нинди дер очракка бәйле булырга тиеш түгел бит инде. Билгеле, барысы да Ходай кулында, әмма әти белән әни дә көтеп алынган сабыйлары саусәламәт тусын өчен хәлләреннән килгәнне эшләргә тиеш. «Безнең түләп бала табарга мөмкинлегебез юк», диючеләргә киңәшем – ул очракта ышанычлы һәм намуслы табибны эзләгез. Танышларыгыз, дусларыгыз арасында андыйларны тәкъдим итүчеләр булмый калмас. Акчага корылган бүгенге заманда да, үз вазыйфаларын намус белән үтәүче табиблар очрый әле. Бигрәк тә районнарда табиб-акушерлар ул кадәр үк акча белән бозылмаган.

Үзең ышанган, бәлки, шәхсән таныш булган табиб яисә акушерка белән килешү төзүең яхшырак, әлбәттә. Андый танышларың булмаса, интернетта барлык табиблар турында да бәяләмәләр табарга мөмкин хәзер.

Кызганыч, без сайлаган бала тудыру йорты бәбиләр вакытым җиткәндә «чистартылу»га ябыла булып чыкты. Шуңа күрә бала көтүче хатын-кызлар өчен киңәшем – мондый очракларны күздә тотып, белешеп куегыз. Баштан ук альтернатив юлны сайлау да зыян итмәс.

Инде бала табу йорты белән килешү төзү вакыты җитте, беренче планыбыз барып чыкмады. Шактый борчыла да башладым. Шуңа Казандагы шәхси бала

Фото: www.pixabay.com

Кемгә ничек уңайлы – сайлау мөмкинлеге шактый киң бүген.

тудыру йортына мөрәҗәгать иттек. Әйе, бәяләре шактый югары – 105 мең сумнан башлана. Баланы ярып алырга туры килгән очракта әлеге суммага тагын 20 меңне, үзең теләгән табибта табарга теләсәң – янә 20 меңне кушып куясың. Бала тугач, аңа гадәттән тыш процедуралар ясарга туры килсә, тагын акча өстисең. Ахырда саллы гына сумма җыелырга мөмкин – моңа әзер булырга кирәк.

Әлбәттә, бу кадәр акча түләгәч, бала табучыга игътибар да бик зур: аерым палата, бөтен кирәк-ярак әзерләнгән (гадәти бала табу йортына баргандагы кебек сумка тутырасы юк), берәр якын кешең һәрчак синең белән янәшә була, ярдәм итә ала. Бала тугач та, клиникадан бер ай буе хатын-кызның сәламәтлеген белешеп, бала янына килеп торалар. Әмма мондый клиникаларның иң зур өстенлеге, минемчә, туган минутыннан башлап баланың әнисе янында булуыдыр. «Ана һәм бала» форматындагы палаталарга башта мин шикләнеп караган идем. Әни кеше беренче көннәрдә ял итәргә, көч тупларга тиеш дип уйладым. Тик хәзер фикерем капма-каршыга үзгәрде. Эгоизм ич бу! Мин ял иткәндә, балам каядыр елап ятсынмы? Кем аны юатыр, куенына алыр? Бәлки аның табиблар билгеләгән вакытта түгел, ә алданрак ашыйсы килер? Ә асты юешләнеп, аны күрмәсәләр, алыштырмасалар? Туңып ятса? Баласы тууга читкә китеп ял иткән берәр хайванны күргәнегез бармы? Юк бит, табигать алай яратмаган.

Бу бала тудыру йортын, әйткәнемчә, акчабыз күп булганга түгел, ә башта уйлаган планыбыз барып чыкмаганга, бәбиләүче хатын-кыз өчен барлык уңайлы шартлар тудырылган һәм әйбәт табиблар эшли торган урын булганга сайладык. Ә байлар һәм дөрестән дә акчага аптырамаучылар хәзер, гомумән, балаларын өйдә таба. Табигыйлеккә кайтумы бу, мода артыннан куумы, әйтә алмыйм. Һәркемнең үз сәбәбе, үз сайлаган юлы. Тик, минемчә, үз организмын 100 процент белгән кеше генә мондый адымга бара аладыр. Өйдә нинди хәл килеп тумас, тиз арада медицина ярдәме кирәк булуы да ихтимал бит.

Бәби табучы хатынга доула ярдәме минем өчен ачыш булды. Бүген ирең белән бергә бала табып беркемне дә шаккаттырып булмый. Казанның күп кенә бала табу йортлары мондый мөмкинлекне тәкъдим итә. Ә менә бала табучы хатын-кызлар өчен психологик ярдәм итүче мондый сирәк һөнәр ияләре турында күптән түгел ишеттем. Алар бала табучы хатын-кыз белән акушер һәм табиб арасында бәйләүче звено булып тора, хатын-кызның барлык теләкләрен үти: теләсә шәмнәр яндыра, музыка кабыза, массаж ясый, су бирә... Казандагы бала тудыру йортларында доулалар барлыгы турында ишеткәнем юк әле, ә менә Мәскәүдә инде алар бик киң таралган. Доула ярдәме 50–80 мең сум тирәсендә тирбәлә. Бу төр хезмәткә кылану, иркәләнү дип карарга кирәк түгел, минемчә. Алар хатын-кызны 30–32 атнадан башлап бала туганчыга кадәр әни булырга психологик яктан әзерли. Беренче тапкыр әни булучыларга мондый ярдәм аеруча кирәк. Яшь әни өйгә кайткач, гадәттә, кечкенә бала белән ялгызы кала (беренче чорда ире, әти-әнисе булышырга мөмкин, әлбәттә, тик бу ярдәм бит бик кыска вакытлы). Шул чакта депрессияләр дә шактый еш күзәтелә. Әгәр дә барлык хатын-кызлар да психологик яктан тиешле әзерлек алса, мондый хәлләр сирәгрәк очрар иде, мөгаен.

Мин бөтен кешегә дә доула эзләргә киңәш итмим. Бары тик гаиләгә кечкенә кеше кайтканчы мөмкин кадәр мораль яктан әзерләнергә генә тәкъдим итәм. Коляска, бала караваты һәм башка кирәк-яраклар алып кую мөһим, әлбәттә, ләкин тулы әзерлек матди әйберләр исемлеге белән төгәлләнергә тиеш түгел. Махсус әдәбият уку, булачак әти-әниләр өчен оештырылган курсларга йөрүне дә бу исемлеккә өстәп куярга була.

Без үзебез бу шатлыклы вакыйгага шактый вакыт әзерләндек. Планлаштыру чорында ук табибларга күрендек, сәламәтлегебезне тикшерттек. Булачак әниләр өчен махсус курсларга да язылдым һәм, әйтергә кирәк, аның файдасын да күрдем. Шулай ук тудыру йортында баламның гел янәшәмдә калуы да яхшы булды: өйгә кайткач, бәбине кайсы яктан тотарга икән дип аптырап тормадым – кызымны шактый оста карарга өйрәнгән идем инде.

Инде кабат бәяләр турында. Авырлы чакта түләүле клиникада күзәтү узу, шәхси бала табу йортында бәбиләү безнең гаиләгә 170 меңгә төште. Әйе, бүгенге бәбиләр һич тә арзан түгел...

Күргәнегезчә, замана белән бергә бала табу кебек гомерлек процедура да үзгәрешләр кичерә. Бу чорда хатын-кызның психологик халәтенә зур әһәмият бирелә башлады: аңа бала табучы робот итеп карау артта калып бара – эмоциональ сәламәтлеге беренче урынга чыга. Партнер белән бала табу мөмкинлеге, өйдә бәбиләү, доулалар хезмәте – барысы да хатын-кызның психологик халәтен кайгырту эволюциясе.

Ә инде сабыең дөньяга килеп, аны күкрәгеңә куюга, бала туу белән бәйле сораулар гына түгел, ә дөньяның барлык мәшәкатьләре дә артка күчә икән, бөтен булган проблемалар югалып, кинәт кечерәеп кала сыман. Күңел шатлык, җиңеллек хисе, горурлык һәм шул ук вакытта нindидер адреналин һәм көч белән тула. Берни белән дә чагыштыргысыз һәм алыштыргысыз минутлар! Берәр вакыт: «Ә сез кайчан үзегезне 100 процентка бәхетле итеп тойдыгыз?» – дип сорасалар, мин ике дә уйлап тормыйча, һичшиксез шул мизгелне искә төшерәчәкмен... Барлык хатын-кызларга шушы илаһи минутларны кичерергә насыйп итсен!

ФОТОБӘЙГЕ:
«ОБЪЕКТИВТА – ӘНИ»



Фото: Олеся Чегаева. Казан.

«Объективта – әни» бәйгесе дәвам итә. Аның оештыручылары – «Сөембикә» журналы редакциясе һәм «Казан Кремле» музей-тыюлыгы. Фотосурәтләрегезне 31 октябрьгә кадәр җибәрә аласыз. Исегезгә төшерәбез: иң уңышлы дип тапкан эшләр журнал битләрендә дөнья күрәчәк, ә көзгә – Әниләр көнендә – Казанда, «Манеж» күргәзмәләр залында алардан күргәзмә оештырылачак. Җиңүчеләрне планшет, кесә телефоны кебек кыйммәтле бүләкләр көтә.
Конкурсның нигезләмәсе һәм шартлары белән сайтыбыздан таныша аласыз: www.syuyumbike.ru.

ЯРАТУ БЕЛӘН ЯШИ



Март ахырларында хайваннар йон алыштыра башлый. Кыш буена салкыннан саклап торган калын йон катламы куба, аның урынына чиста, яңа төкләр чыга. Сыерлар утарга чыгып, кояшка карап басалар да утар баганасына муеннарын ышкыйлар. Озакламый сарык-бәрәннәрнең йоннарын алыр вакыт җитә… Терлекчеләр әнә шундый календарь белән яши. Көннәре дә иртәнге һәм кичке мал карау вакытына бүленә. Алар өчен календарьдагы кызыл ял көннәре юк, бары тик сыер «каплаткан», «бозаулаган»ны аңлаткан көннәр генә түгәрәк белән билгеләнә. 365 көн буена, еллар буена, дистә еллар буена…



Без аны «Ел хатын-кызы-2019» бәйгесендә күрдек. Мөлаемлыгы, тыйнак елмаюы белән җәлеп итте ул безне.

«Ярый әле бозаулар бар»

Питрәч районы Шәле авылында яшәүче бозау караучы Тәслимә апа Миндубаева 47 нче хезмәт елы белән бара. Ярты гасырга якын вакыт эчендә дөньялар ничек кенә үзгәреп бетмәде, бары тик терлекче хезмәте генә иң тотрыклысы булып калды бугай: бозаулар һаман ашарга сорый, һаман да аларның астын чистартып торырга кирәк.

– Ярый әле бозаулар бар. Алар янына фермага менеп, сөйләшеп төшсәм дә күңел була. – Тәслимә апаның бүгенге хакыйкате бу. Сөйләшеп кенә йөрми, билгеле. Фермада авыр-авыр фураж капчыкларын да үзенә ташырга туры килә. «Эшләмә! Син пенсиядә инде», – дип кенә җибәрә үзләре дә пенсия яшенә якынаючы хезмәттәшләре. «Әйтерсең лә бозау карарга чират торалар, – дип каршы төшә Тәслимә апа, яшьләрнең фермада эшләргә ашкынып тормавына ишарә итеп. – Эшләмәс идем. Бер көн дә. Өйдә ялгыз утырудан качам». Ә кайчандыр беренче улы Ниязны тапкач, колхоз рәисе балага алты ай тулганчы ук эшкә чакырып ала: «Крестьян баласы әни белән өйдә ятарга тиеш түгел», – ди. Бала кайнаналар тәрбиясенә кала. Ярый әле алар булган!

Яшьләрнең фермага эшләргә килмәвенә дә канәгатьсезлек белдерми Тәслимә апа: «Яшьләр хәзер безнең кебек фермага бармый инде ул. Андагы хезмәт хакына гына яши алмыйлар, ипотекада, кредитта утыралар. Заманы шул. Безгә генә ярады ул ферма. Бүгенге көндә дә ярый әле». 8 мең сум пенсиясенә шуның кадәр үк хезмәт хакы өстәлгәч ярый дию.

8 генә мең сум өчен хөкүмәтне дә, җитәкчелекне дә, язмышын да сүкми Тәслимә апа. Ул, гомумән, зарлана белми бугай. Яше шактый олыгаюга таба барса да, аның әле дә зәңгәрлеген җуймаган күзләрендә татар апаларына хас шөкрана тынычлык бар. Бөтен нәселшәҗәрәсе белән Шәле авылыннан ул. Казан ханлыгында ук билгеле булган Шәледән...

Әкият кебек башланган тормыш

– Шәледән китеп караган чаклар булды. Нужа күрәсе килгәндер инде: мәктәпне бетергәч, 1972 елда Кукмарага барып ипи пешерүче булырга укып кайттым. Бер ел Питрәчтә ипи пешердем. Аннан Казанга чыгып киттем. Бер ел сыр заводында эшләдем. Сагынуга түзә алмадым – яңадан кайттым. Әле дә Казанга бер генә көнгә барам. Никадәр нужалы булса да, авылда рәхәт. Үз өең, үз көең...


Казаннан кайткач, Тәслимә Казан күн эшләнмәләр берләшмәсенең Шәледәге филиалында тегүче булып эшли башлый. Алты ай – тегүдә, алты ай колхозда бозау караучы булып эшли-эшли 19 ел үтә. 2000 нче елларда хезмәт хаклары бирелмәгәндә, филиалда «плүс»кә эшләп йөриләр. Колхозда таякка эшләгән кешеләр белә: пенсия саный торган «система» таякларны да, плюсларны да танымый. Әнә шулай итеп, иң аз пенсия белән кала да инде авыл кешесе.

Хәләл җефете Исмәгыйль абый белән ун ел очрашып йөреп өйләнешә алар. Параллель сыйныфларда укыйлар. Кыз егетне армиягә озатып кала. Исмәгыйль армиядә вакытта башка егетләр күз салмасын дип, булачак кайната Тәслимәне карап-саклап тора. Хезмәтен тутырып кайтуга тиз генә өйләнешә алмый әле яшьләр. Исмәгыйль үзенең 25 яше тулган көнне туй итеп, Тәслимәне үзләренә алып кайта.

– Кайнана белән кайнатага шунда ук әни, әти дидем. Безнең белән әтинең әнкәсе, каенсеңел, каенапа, каенапаның ике баласы – әнә шулай ишле гаилә булып яшәп киттек. Ике як күршедәге ике әби иртән дә, төшкә дә, кич тә керәләр иде. Ул вакытта өебез зур түгел, әмма һәркемгә урын җитте. Колхоз өстәле чаклы өстәл тирәли тулып утыра идек табынга. Торабара өебезне киңәйттек. Кызыбыз Гөлия, улларыбыз Нияз белән Рияз туды, – дип искә ала Тәслимә апа, бүген болын кадәр иркен өенә







Авырмасаң, эш рәхәт кенә бит ул.

күрсәтеп. – Без бик матур яшәдек. Әти йортына бер генә көнгә дә кайтып киткәнем булмады. Мәрхүмә әнием озак еллардан соң: «Мин сине бу тормышта бер көн дә яшәмәс дигән идем», – диде. Кая ул? Без әниләргә кереп кенә чыга идек, балаларны да кайнаналарым карады, үз әниемә ике сәгатькә дә илткәнем булмады. Әнигә барып бер сүз зарланмадым. Үзе дә сорашмады да, җәлләмәде дә. Иремнең әти-әнисе миңа да әти белән әни булды, бик ярattылар...

«Ишектән башын тыгар да «Әни!» дип дәшәр төсле»

Миндубаевлар балаларын да эшсөяр итеп үстерә. Малайлар ишегалдындагы эшне карый, кызлары Гөлия – өйдәгесен. Әнисен аш бүлмәсенә дә кертми кызлары: ашарга үзе пешерә, идән чүпрәге дә тоттырмый. «Әни, син бар әби янына, аннан эшеңә китәрсең, үзем эшлим барысын да», – дип әйтә торган була. Җитез, шаян, шук булып үсә. Мәктәпне тәмамлагач, Казанга педагогика институтына укырга керә.

– Икенче курста укый иде. Ялга кайткач, иптәшләре белән йөргән егетенең туган көнен үткәрергә киткәннәр. Барганда авариягә очрап, кызым һәлак булды. Егете эчкән килеш рульгә утырган... Ә егетне машина йөртү хокукыннан да мәхрүм итмәделәр. Исмәгыйль дә шуннан соң бетереште. Телендә гел Гөлия булды...

Ул кайгылы көннәрдән соң 16 ел үткән инде. Бу вакытта тегү филиалы ябылган, Тәслимә апа бозаулар карауга гына күчкән була. «Кызым үлгәндә, вакытлыча эшләп торырга алмашка кеше табылмады. Кемнедер үз урынына калдырасың икән, акчасын үз кесәңнән түлисе. Аның бәләкәй генә акчасына кем риза булсын?.. Кызым әле дә: «Әни, мин кайттым», – дип ишектән башын тыгар төсле. Ул гел шулай итеп дәшә торган иде...» – Тәслимә апаның йөрәк әрнеткеч сүзләреннән соң тынлык урнаша. Сәгать телләре генә текелди.

– Исмәгыйль белән бергәләп тегү берләшмәсендә эшләдек. Аннан соң ул колхозда ремонт эшләренә йөрде. Соңгы елларында шабашка да чыккалады, – дип дәвам итә Тәслимә апа. Кызы вафатыннан соң җиде ел узгач, Исмәгыйль абыйның да җансыз гәүдәсен авария булган урында табып алалар: йөрәге тоткан, диләр.

Хәзер инде Тәслимә апа ике улы, киленнәре, оныкларының шатлыкларын уртаклашып яши. Олы улы – Питрәчкә, кечесе Казанга барып урнашкан. Ялларга кайтып йөриләр. Шимбә саен табын тутырып ризык пешереп, мунча ягып, балаларын көтеп тора Тәслимә апа.

– Шулай, – ди күпне күргән авыл апасы. – Елап яшәп булмый. Юкны да үткәрдек, барны да.

– Эше авыр бит.

– Ә нишләп була соң, кызым?! Кемнән өмет итик? Исән-сау вакытта яшисе инде. Эш булмаса, ничек яшәр идем, әйтә алмыйм. Җитәкчелеккә дә авыр. Авыл хуҗалыгы кайчан үзен-үзе аклаганы бар соң? Андый хәлнең булганын хәтерләмим. Ә без өйрәнгән инде, акча да димәдек, пенсияне дә уйламадык, безгә эш кенә булсын.

Тәслимә Миндубаеваның тормыш кагыйдәсе бу. Гадилегенең галилеге. Әйе, хезмәте өчен аның Мактау кәгазьләре дә, Рәхмәт хатлары да алганы бар. Моннан ике ел элек районнан Сочига юллама белән ял итәргә барып кайткан. 47 елга бер тапкыр андый хөрмәткә дә лаек булган.

Ләкин хикмәт анда түгел. Тәслимә апа фермага да, бозауларына да тәкәббер генә караш ташлый торган токымнан түгел. Киресенчә, ул аларга тормышының бер өлеше итеп, яратып карый. Көн саен кояштан да иртәрәк торып, фермага менгәндә, ул бозаулар турында «бу киләчәктә фәлән литр сөт бирәчәк, ә монысыннан фәлән центнер ит чыгачак, ә мин шуның кадәр суммада акча алачакмын», дип һич кенә дә уйламый. Гомумән, ул саннар турында уйламый. Ул ярату белән яши...

Ландыш ӘБҮДӘРОВА.





Фото: Анна Арахамия


КИЛӘЧӘК ҺӨНӘРЕ

Хәзерге дөньяны төрле машиналар, техник җиһазлар, механизмнарсыз күз алдына да китереп булмый: автомобиль, компьютер, көнкүреш техникасы... Аларны инженер-конструкторлар ясый. Соңгы дистә елда әлеге һөнәр тамырдан үзгәрде. Компьютер технологияләренең алга китүе бу өлкәдә могҗизалар тудырды. Элек конструктор дип әйтүгә, кәгазьдәге зур сызымнар, карандашлар күз алдына килсә, хәзер белгечләр әлеге эшләрне компьютерда күпкә тизрәк һәм сыйфатлырак итеп эшли ала. Болар барысы да CAD модельләштерү ярдәмендә башкарыла. Гади тел белән әйткәндә, теләсә нинди механизм махсус программалар ярдәмендә компьютерда ясала. Инженер – хәзерге көндә иң популяр һөнәрләр исемлегендә. WorldSkills хәрәкәтендә әлеге компетенциядә тулы бер блок бар. Элек инженер булып ир-атлар гына эшләсә, хәзер аны хатын-кызлар да үз итә. Казаннан Суфия МИҢНЕБАЕВА унынчы сыйныфта гына укыса да, CAD модельләштерү серләрен белә. WorldSkills эшче һөнәрләренең бөтенроссия чемпионатында үзеннән күпкә өлкәнрәкләр белән көч сынашырга әзерләнә.

Инженер-программистлар гаиләсендә туган Суфиянең әлеге һөнәрне үз итүе очраклы түгел. Абыйсы да программист аның. Тик ул башкарак профессияне сайлый. Суфия 6 нчы сыйныфтан соң КАИ каршындагы инженер лицеена укырга күчә. Технология дәресләрендә 3D модельләштерү нигезләрен үзләштерә. Менә шунда инде ул инженер дизайнер һөнәре белән таныша. Укытучы-остазы Арнольд Альтапов кызның сәләтен, модельләштерүне яратып һәм мавыгып башкарганын күреп, аңа бу юнәлештә яхшылабрак шөгыльләнергә киңәш итә. Суфия WorldSkills ярышларына әзерлек дәресләренә йөри башлый. Ярышларда катнашып, җиңү яулармын дип уйламый да. Аның өчен ул бары тик бик кызыклы хобби булып тоела. Ә менә республика күләмендә уздырылган WorldSkills-ның юниорлар чемпионатында катнашып, икенче урынны яулый! Бу компетенциядә нибары берничә ай шөгыльләнгән, тәҗрибәсе, белеме булмаган кыз өчен бу зур җиңү, әлбәттә. Мин беренче булырга тиеш дип, Суфия тагын да үҗәтләнебрәк – ныклап әзерләнә башлый. Һәм икенче елга Татарстанда гына түгел, Россиядә җиңүчеләр пьедесталына күтәрелә. Краснодарда үткән чемпионатка барып, инженер-дизайнер компетенциясендә иң яхшы юниор булуын раслап кайта.

– Ул вакытта ярышларны уен итеп кенә кабул иттем. Шуңа берниндиi курку булмады, – дип искә ала ул. Хәзер инде киләчәктә үзенә ярдәм итәчәк бик җитди ярыш булуын аңлаган. Чөнки әлеге җиңүләр вузга укырга кергәндә язмышны хәл итәргә мөмкин: өстәмә балл биреләчәк. Аңа кадәр әле тагын ике ел бар. Хәзергә ул – Россиянең җыелма командасында. Май аенда Казанда узачак WorldSkills эшче һөнәрләр буенча бөтенроссия чемпионатына катнашачак. Чемпионатка әзерләнгәндә вакытыгыз бөтенләй калмаячак, дип кисәтәләр аларны остазлары. Кая ул урамда йөрүләр... Кайчак дәресләрне дә калдырырга туры килә Суфиягә. Биремнәрне эшләр өчен компьютер артында алтышар сәгать утырырга кирәк. Сызымнарны компьютерда модельләштереп, двигательләр ясый алар. Күпләр күз алдына да китерә алмыйдыр, мөгаен. Суфиягә исә бу бик кызыклы процесс. «Инженер-дизайнер ир-егетләр һөнәре генә түгел, киңлектә уйлау сәләте хатын-кызларда да бар. Бездә әле ул яхшырак та килеп чыгадыр», – ди кыз. Әлеге компетенциядә җиңү яулар өчен вакытны җәлләмәскә кирәк. Бигрәк тә язмышыңны бу һөнәр белән бәйләргә теләсәң. Суфия карар кабул иткән инде: Казандагы техник университетта белем алачак. Буш вакытларында ул төрле конструкцияләр модельләштерә. «Аларның күбесе фантазиягә корылган, хәзерге дөньяда кулланыла алмый», – ди. Ә без еракка китеп карыйк. Җәмгыятьтә бит феноменаль техник процесслар бара. Бигрәк тә программалаштыру, прибор төзелеше юнәлешендә. Суфиянең бүген ясаган детальләренә, бәлки, иртәгә үк зур ихтыяҗ туар. Ә инженерлар – бүген, бигрәк тә киләчәктә җәмгыятьнең элитасы булачак кешеләр.

Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА



■ Суфия Миңнебаева Татарстанда узган «Яшь профессионаллар» («WorldSkills Russia») төбәк чемпионаты вакытында.



Республика клиник хастаханәсенең баш табибы Рафаэль ШӘВӘЛИЕВнең тормыш кагыйдәләре

ГАШЫЙК БУЛУ – СӘЛАМӘТЛЕК БИЛГЕСЕ

МИН РЕЖИМ БЕЛӘН ЯШИ ТОРГАН КЕШЕ.

Табиблар турындагы сериалларны караганым юк – **ТЕЛЕВИЗОР АЛДЫНА БИК СИРӘК УТЫРАМ. КИРӘКЛЕ МӘГЪЛҮМАТНЫ ИНТЕРНЕТТАН ГЫНА ТАБАМ.** Ә нинди сериаллар бар?

Вакыт булганда китап укырга яратам. **МИҢА ТАРИХ БЕЛӘН БӘЙЛЕ КИТАПЛАР ОШЫЙ**.

Әти белән әнигә шалтыратмыйча калган бер көнем дә юк. Минем балалар да шулай – хәлемне, кәефемне көн саен белешәләр. Бер сүз булса да язалар. Шунда ук җавап бирсәм дә, бирә алмасам да. Мондый **ИГЪТИБАРНЫ БЕР-БЕРЕҢӘ ГЕЛ КҮРСӘТЕРГӘ КИРӘК**. Шуны ешрак эшли алмавым өчен үземне гел ачуланам. Негативтан, стресстан качуның иң яхшы юлы шушы лабаса.

Әти – Актанышта билгеле, дәрәҗәле, хөрмәтле кеше. Үскәндә, кая гына барсам да, исемем белән дәшүче булмады – «Фирнаял малае», диделәр. Анда **КИРЕ ӘЙЛӘНЕП КАЙТСАМ, ГОМЕР БУЕ «ФИРНАЯЛ МАЛАЕ» БУЛЫП КАЛАСЫМНЫ БЕЛДЕМ**. Шуңа күрә укуны тәмамлагач, эшкә бөтенләй башка районга китеп бардым.

Дусларым арасында табиблар күбрәк димәс идем. Гомумән, бик аз алар минем. **ДУСЛЫККА БИК ҖИТДИ КАРЫЙМ БУГАЙ...** Булганнарының кадерен беләм – арада үтә якыннары бар. Алар һәрберсе тормышта үз урынын тапкан. Мөнәсәбәтләребез ихлас: берсе дә: «Аның белән ул миңа кирәк булган өчен дус», – димәс.

ҮЛЕМ – КУРКЫНЫЧ, ЧӨНКИ УЛ ЮГАЛТУ БЕЛӘН БӘЙЛЕ.

Сабырлык – кешегә кирәкле сыйфат. Табиб өчен бигрәк тә. **«МИН – САБЫР» ДИП САНАСАМ ДА, АНЫ БАРЫБЕР ҮЗЕМДӘ АРТТЫРУ ӨСТЕНДӘ ЭШЛӘРГӘ ТИЕШМЕН**.

Тән һәм җан сәламәтлеге бергә туры килгәндә, кеше күбрәк гашыйк була. Димәк, **ГАШЫЙК БУЛУ – СӘЛАМӘТЛЕКНЕҢ БЕР БИЛГЕСЕ ДИП САНАУ ДӨРЕСТЕР**.

СӘЯХӘТ ИТҮ БӨТЕН ВАКЫТТА ДА ДАРУЛАРНЫ АЛЫШТЫРА АЛМЫЙ. Даруларсыз бөтенләй тора алмаучылар да бар. Әйтик, шикәр чирлеләр – инсулинсыз. Әмма шул ук вакытта кеше үзенең кайбер халәтен ял итеп, игътибарын башкага юнәлтеп, шөгылен алыштырып та үзгәртә ала.

ҖИТӘКЧЕ БУЛАРАК, КУЛ АСТЫМДА ЭШЛӘҮЧЕЛӘРДӘН ҮЗ СӘЛАМӘТЛЕКЛӘРЕН КАЙГЫРТУНЫ ДА ТАЛӘП ИТӘМ. Бездә тәмәке тартырга, артык юанаеп китәргә ярамый.

Үземне, әлбәттә, оптимист дип саныйм. Әмма миндә кайбер прагматизм элементлары да бар. Гомумән, һәр кеше прагматик булырга тиеш. **УЙЛАГАНЫҢНЫ ЧЫНГА АШЫРУ МӨМКИНЛЕГЕ ЮК ИКӘН, ОПТИМИСТ БУЛУДАН НИ МӘГЪНӘ?** Оптимист дөньяга аек күз белән карарга тиеш.

Әгәр хирург операция ясый һәм пессимистларча: «Барыбер килеп чыкмый», – дип уйлый икән, ул – начар хирург. Шул ук вакытта, тиешенчә эшләп бетерми (берәр иң нечкә капиллярны текмичә калдыра, аннан кан тамып торып, абсцесс башлана), әмма оптимистларча: «Барысы да әйбәт булачак», – дип әйтә икән, бу – шулай ук начар хирург. Ул перфекционист булырга, иң югары камиллеккә омтылырга тиеш. **ХИРУРГТАН ТОРМЫШКА БАШКАЧАРАК КАРАУ ТАЛӘП ИТЕЛӘ.**

ТАБИБ ӨЧЕН ИҢ АВЫРЫ – БАР ЯГЫН ҮЛЧӘП, БИЛГЕЛЕ БЕР КАРАРГА КИЛҮ. Һәм ул карар нигезләнгән, расланган (без хәзер раслый ала торган медицина шартларында яшибез), бар яктан да профессионалларча тәгъбир ителгән булырга тиеш. Диагноз куелса, калганы техника эше. Операция ясау да катлаулы түгел, дәва билгеләү һәм аны уздыру да.

Әтинең иртәнге биштән аяк өстендә булуына элек гаҗәпләнә идем. Хәзер үзем дә бик иртә торам. **ЙОКЛАП ЯТА АЛМЫЙМ – ЭШЛӘР КӨТӘ, ӨЛГЕРЕРГӘ КИРӘК.**

НИНДИДЕР ЭЧКЕ КӨЧЛӘР БАР, алар аруны компенсацияли – организмны элекке хәленә кайтара һәм сәламәтлекне сакларга булыша.

ХАЛЫК МЕДИЦИНАСЫНА ХӨРМӘТ БЕЛӘН КАРЫЙМ. Сәламәтлекне сакларга булышучы гореф-гадәтләр, киңәшләр, ысуллар байтак. Фиточәй, үләннәрдән ясалган продукция, яшьлекне сакларга ярдәм итә торган үсемлек

Фото: Анна Арахамия

майлары (бары тик алар составында гына яшьлек молекуласы бар!) – барысы да файдалы. Шул ук вакытта онкология булганда аракы белән май эчүгә мин кискен каршы. Психотерапиянең бер элементы булуы белән генә килешәм. Әмма ул бу очракта терапияне алыштырмый!

Психологларда шундый метод бар: кешедәге һәр гадәтне өч ел эчендә тамырдан юкка чыгарырга була, диләр. Ни өчен өч елда? Чөнки бу вакыт эчендә организмдагы һәр күзәнәк яңарыш кичерә. **ӨЧ ЕЛ ҮТКӘН САЕН, СЕЗ ЯҢА КЕШЕ...**

КЕШЕНЕҢ ТЫШКЫ КЫЯФӘТЕНӘ, КӘЕФЕНӘ, АНЫ АЛГА АЛЫП БАРА ТОРГАН КӨЧЛӘРГӘ РУХИ ЯК БИК НЫК ТӘЭСИР ИТӘ. 20 яшьтә үк: «Инде бернәрсә эшли алмыйбыз», дип утыручы «бабай»лар да аз түгел. Шул ук вакытта бер-берсенә яңа гашыйк булган 70 яшьлек пациентлар да очраганы бар.

Үпкәләү – яман шешнең хәбәрчесе дигән сүз бар хәзер. Әйе, онкология юктан гына бар булмый. Төрле факторлар организмда дисбаланс китереп чыгара. Шул дисбалансның үсүе аркасында яман шешләр барлыкка килә. Бу күзлектән чыгып караганда, бар төр авырулар да психосоматика белән бәйле. Тормыштан канәгать булмаган, гел негатив эчендә яшәгән кешенең авыртып китү ихтималы зуррак. **ШУҢА КҮРӘ КЕШЕ ҺӘРВАКЫТ МӘХӘББӘТТӘ, АҢЛАШЫП, ИГЪТИБАР ТОЕП ЯШӘРГӘ ТИЕШ ДИБЕЗ.**

АВЫРТУЛАР ҺӘРВАКЫТ НЕРВЛАРГА БӘЙЛЕ ТҮГЕЛ.

Югары уку йортын тәмамлаган табиблар авылга кайтырга ашыкмый бүген. Минем уйлавымча, моның сәбәбе менә нәрсәдә. Остазларымның үземне ничек эшкә өйрәткәнне хәзер дә хәтерлим. Минкадыйр Әхмәтгалиевич Купкенов: «Күрдеңме?» – дип сорый иде. «Күрдем», – дим. «Иртәгә бу операция буенча имтихан, ә берсекөнгә мин сиңа әлеге операциядә ассистент булам», – дия иде ул. Шулай итеп, ел буе операцияләр ясадым: интернатураны тәмамлаганда, районга кайтып эшләрлек, бар яктан әзерлекле белгеч идем. **МОНДЫЙ ТЕХНОЛОГИЯ БУЕНЧА БЕЛГЕЧНЕ ЭШКӘ ӨЙРӘТМИЛӘР ХӘЗЕР – АЛАР ПАЦИЕНТ ЯНЫНА БАРЫП ҖИТМИ.**

Районда сайлау, озак уйлау, кемнәндер киңәш сорау мөмкинлеге юк: анда хирург та, травматолог та, уролог та, гинеколог та – барысы да үзең. Теләсә нинди ярдәмне күрсәтергә әзер булырга тиешсең. **Ә БҮГЕНГЕЛӘР КЕШЕГӘ НИЧЕК БУЛЫШЫРГА БЕЛМИ...** Шуңа да яшьләр шәһәрдә, тәҗрибәле белгечләр янында эшләргә тели.

Ишекне ябып чыгуга, эштәге проблемаларны онытам дия алмыйм. Борчуларым һәрчак үзем белән... Һәр иртәне безнең «обход» – реанимация бүлеген йөреп чыгам. **БҮГЕНГЕ КӨНДӘ РЕАНИМАЦИЯДӘ ЯТУЧЫ БАРЛЫК АВЫР ХӘЛДӘГЕЛӘРНЕ ХӘТЕРЛИМ.** Республика клиник сырхауханәсе 1300 урынга исәпләнгән. Авыруларның йөздән артыгы – реанимациядә. Аларны истә тотарга, нииндидер карар кабул итәргә кирәк: кемгә гемодиализ билгеләргә, кан салырга, операция ясарга, федераль үзәкләрнең белгечләрен җәлеп итәргә... Авыр хәлдәге бер пациентыбызны кичә менә Санкт-Петербургка озаттык. Көн саен нидер булып тора...

ЕЛАГАНЫМ БАР. Бер тапкыр... Эшем белән бәйле түгел иде ул.

«Бу табибның кулы җиңел» дигән сүз бар. Килешәм, андыйлар очрый. Әмма ул Аллаһы Тәгалә бүләге генә түгел, белгечнең профессиональлеге белән дә бәйле. Һәр көнне осталыгын чарлавы, төгәллеккә, камиллеккә омтылуы, дөрес уй-фикерләр белән яшәве... **ЯШЬ БЕЛГЕЧНЕҢ КУЛЫ БЕРНИЧЕК ТӘ ҖИҢЕЛ БУЛА АЛМЫЙ ӘЛЕ...**

Уролог-онколог булып эшләгән чагым. Бармак битләренең сизгерлеген бик нык арттырырга кирәк иде. Көн саен утыра идем дә, кәгазь бите аша чәч бөртеген табарга, тоярга өйрәнә идем. Шулай итеп, **ТУКЫМАДАГЫ ТӨРЛЕ ҮЗГӘРЕШЛӘРНЕ ТОЕМЛАРГА ИРЕШТЕМ.**

Эш графигым бик тыгыз, соң да кайтыла. Хатынымның канәгать булмаган чаклары да бар, әлбәттә. Бигрәк тә тоткарлануым хакында телефоннан ишеткәндә. Ә кайткач, йөземә генә карый да, безнең тагын кемнедер коткарганны күрә... Ул моны тоя, белә – үзе дә табиб. Әгәр **ЗӨҺРӘ БУЛМАСА, ЭШТӘ НИНДИДЕР УҢЫШЛАРГА ИРЕШӘ ДӘ, БӨТЕН КӨЧЕМӘ ЭШЛИ ДӘ АЛМАС ИДЕМ.**

ТАБИБКА ИНТУИЦИЯ БИК КИРӘК. Әмма ул да тәҗрибә белән генә килә.

Авыртуга чыдаммы дип... **МИН СИРӘК АВЫРЫЙМ.** Моның өчен гомер буе әти-әниемә рәхмәтлемен.

Шундый диагноз бар: ЧБД дип атала (часто болеющие дети). **КАЙЧАК БАЛАЛАРНЫҢ СӘЛАМӘТЛЕГЕНӘ ӘТИ-ӘНИЛӘР ҮЗЕБЕЗ ДӘ ТӘЭСИР ИТӘБЕЗ.**

Хатыным белән дүрт бала үстерәбез. Балаларның авызборыннарын кыш көне томалаганыбыз булмады – шарф аркылы инфекция генә керә. Прививкалардан баш тартмыйбыз. Антибиотиклар кулланмаска тырышабыз. Бүлмәләрен җиллләтеп торабыз. Кулларны һәрвакыт юарга кирәген аңлатабыз... **СӘЛАМӘТЛЕККӘ НИГЕЗ КЕЧКЕНӘ ЧАКТА, ХӘТТА АНА КАРЫНЫНДА ЧАКТА УК САЛЫНА.** Шуңа күрә репродуктив сәламәтлекне сакларга кирәк. Яшүсмерләр үз сәламәтлекләрен ничек кайгыртырга икәнен белергә тиеш. Аннан гомер буе шул траектория белән яшәргә: сәламәтлекне саклап кына «тотарга».

АВЫРТУГА ТҮЗЕП ЙӨРЕРГӘ КИРӘКМИ. Организм шулай корылган, ни генә булса да, ул шунда ук сигнал бирә – сизә белергә генә кирәк. Үзең генә булдыра алмасаң – моңа табиб ярдәмендә өйрәнергә. Барча авыртуның да алхәбәрләре бар: әйтик, инсульт булыр алдыннан баш әйләнә, көтмәгәндә каты баш авыртулар башлана. Миокард инфаркты алдыннан исә стенокардия борчый. Бу бәйләнешне, бу сигналларны вакытында ишетә белү бик мөһим. Кисәтү медицинасының максаты да шушы: мондый чакларда кешегә үзен аңларга булышу.

Инде берничә тапкыр хезмәт урынын алыштырырга туры килде. Яңа коллективта минем өчен **ИҢ БЕРЕНЧЕ ЧИРАТТА КЕШЕЛЕКЛЕ МӨНӘСӘБӘТЛӘР УРНАШТЫРУ МӨҺИМ.** Калганы һәр команданың мөмкинлекләренә карап төзелә.

БАЛАНЫ ЧИТ ИЛГӘ АЛЫП БАРЫРЫРГА АКЧА ҖЫЮ ТУРЫНДА БЕЛДЕРҮ КҮРГӘНДӘ, МОҢА ҺӘР АТА-АНАНЫҢ ХАКЫ БАР ДИП УЙЛЫЙМ. Бала авырудан да зур хәсрәт юк. Әти-әниләрдән: «Реанимациядә үзем ятар идем», «Бу кювезда үзем булыр идем», дигән сүзләрне бер генә ишетмәдем... Республикабызның, Россия Федерациясенең сәламәтлек саклау системасы балаларны дәвалау өчен барлык шартларны да тудыра ала – бу дөрес. Әмма кайбер очракларда чит илдә дәвалану отышлырак. Мәсәлән, бавырны күчереп утырту, кан авырулары белән бәйле проблемалар бар әле. Һәр очракта да башта табиб белән киңәшү кирәк. Ә моның өчен табиб белән пациент арасында контакт, аңлашу, бер-берсенә ышану мөнәсәбәте урнашу мөһим.

КЕМГӘДЕР ЫШАНГАНДА ГЫНА ДӘВАЛАУ БАШЛАНА. Ата-ана акча эзләргә керешкән икән, димәк, әлеге ышаныч юк дигән сүз. Бәлки, аларның моңарчы ниндидер ачы тәҗрибәсе булгандыр, кемнеңдер сүзе тәэсир иткәндер... Без аларны моннан тыя алмыйбыз. Әмма кисәтеп куярга тиешбез: беренчедән, мошенникларга тап булулары ихтимал; икенчедән, акча җыю белән мавыгып, бала өчен мөһим булган кыйммәтле вакытны югалтулары бар. Кызганыч, табиблар бу хакта һәр очракта да кисәтми.

ТАБИБ ҺӘРВАКЫТ ПАЦИЕНТ ИХТЫЯҖЫН, АНЫҢ МӘНФӘГАТЕН УЙЛАП ЭШЛИ. Авыру кешегә зыян килерлек берни дә әйтми, киңәш бирми.

ЭШЕМНЕҢ ИҢ КҮҢЕЛЛЕ ЯГЫ нәрсәме? Кайсы күзлектән чыгып карыйсың инде. Канәгатьлек алу мәгънәсендә булса, бу, әлбәттә, **КЕШЕ ГОМЕРЕН САКЛАП КАЛУ**. Позитив момент дип уйлаганда – **КОМАНДАНЫҢ ҮЗАЛДЫНА КУЙГАН МАКСАТЛАРЫН ҮТӘВЕ**. Әле генә хәл эчендәге авыруны Чаллыдан безгә күчерү турында сөйләштек. Көн инде төнгә авышып бара – вертолет оча алмый. Белгечләр командасы Чаллыга чыгып китте. Алар хәзер юлда. Көнме, төнме – безгә аерма юк. Операцияне анда ясарлармы, монда алып килерләрме – урында хәл итәчәкләр. Бу корпоратив культура, атмосфера, профессиональлек сине үзенә бөтереп ала – вакыт узуын да сизмисең.

БАЛА БЕЛӘН КОНТАКТ УРНАШТЫРУ ТАБИБКА АВЫРРАК, чөнки арадашчылар бар – әни, әти, туганнар... Әмма бала күңеленә юл табу барыбер беренче урында тора. Кайчак шундый тренинглар үткәрә идек. Кабинетта урындыклар юк. Бала керә. Табиб аңа өстән генә карап нидер хәл итә икән, димәк, безнең коллега була алмый. Ул һичшиксез иелергә, күзләре баланыкы белән бер югарылыкта булырга тиеш. Шул очракта гына ике арада контакт урнаша. Олылар тормышында да шулай бит.

МОГҖИЗАЛАР ӘКИЯТТӘ ГЕНӘ БУЛА. Ә чынлыкта ул бик тырышып, җентекләп, басылып эшләүнең нәтиҗәсе генә.

БАЛАЛАРГА ДИАГНОЗЛАРЫН ӘЙТҮ КИРӘКМЕ-ЮКМЫ ИКӘНЕ ӘНИ КЕШЕНЕҢ ЭМОЦИОНАЛЬ ИНТЕЛЛЕКТЫНА БИК НЫК БӘЙЛӘНГӘН. Баласы белән ни булганын ул аек акыл белән кабул итә аламы-юкмы – моны һичшиксез күздә тотарга кирәк. Кайчак шундый очраклар була иде: проблема бар, ләкин бик кечкенә. Игътибар итмәс дәрәҗәдә кечкенә... Әмма кайбер сәбәпләр аркасында әни кеше аны бик күпертә. Бу, гадәттә, бер-берсе белән аңлашу булмаган гаиләләрдә килеп чыга.

ҺӘР БАЛАМА АЕРЫМ ВАКЫТ БҮЛҮ КИРӘКЛЕГЕН МИН ҮЗЕМ ӨЧЕН ХӘЗЕР ГЕНӘ АЧЫКЛАДЫМ. Кызганыч, бераз соңрак... Әмма бу минем өчен хәзер төп кагыйдә. Зөһрә – балалар табибы, ул эшләсә дә, балалар тормышы белән яшәргә дә өлгерә. Мин алай ук булдыра алмыйм... Улыбызны күбрәк бабасы – хатынымның әтисе тәрбияли. Мин аларга бик рәхмәтле – безгә бик булышалар.

ТАБИБЛАРГА АКЧА БИРЕП КАРАГАНЫМ БУЛДЫ. Баш тарттылар... Табибтан бүген коточкыч зур тәвәккәллек сорала, шуңа күрә хәтта кайберләре бик катлаулы операцияләргә алынмый да. Алар өстенә салынган җаваплылык белән матди тәэмин ителеш тәңгәл түгел. Күп эшләүче табиблар зур хезмәт хакы да алырга тиеш. Бүгенге көндә уникаль операцияләр ясаучы, башкаларга остаз булган хирурглар бар. Аларның хезмәт хакларын күтәрүгә ирештек. Иманым камил – мондый хирурглар беркайчан «взятка» алмаячак.

ХИРУРГЛАРГА, ТАБИБЛАРГА ЮГАРЫ ХЕЗМӘТ ХАКЫ ТҮЛӘНЕРГӘ ТИЕШ. Киресенчә булганда, акчаны төрле юллар белән эшләү теләге барлыкка килә. Баш табиб буларак, мин һәр хезмәткәрнең матди хәле әйбәт булсын дип тырышырга тиешмен.

Гөлнур САФИУЛЛИНА әзерләде.

И МӨКАДДӘС МОҢЛЫ САЗЫМ...

Габдулла Тукайның әнисе Бибимәмдүдә абыстайның тууына – 155 ел



Габдулла Тукайның әнисе Бибимәмдүдә. Әлфия Зәбирова графикасы

Дөньяга бөек Тукайны тудырган шагыйрь әнкәсе Бибимәмдүдә – риваятьләр алиһәсе Мәрьям анага тиң илаһи зат. Мондый галиҗәнап әнкәләр җиһаныбызда бик сирәк була. Күреп торасыз, Бибимәмдүдәнең Җиргә килүенә инде гасыр ярымнан артык вакыт узып киткән, әлегә исә татарлар арасында Тукай дәрәҗәсендәге каләм әһеленә яшәү көче биргән ана күренми.



Марат ӘМИРХАНОВ

Шушы фикеремне кәгазьгә төшердем дә уйга калдым. Ник дисәң, без, аның милләттәшләре, бу бөек Анага тиешле кадер-хөрмәт күрсәтәбезме, хәтерен үзенә лаек кимәлдә яд итәбезме?

Миңа калса, боз кузгалды: соңгы елларда Тукай көннәре Бибимәмдүдәнең каберенә чәчәкләр салу, рухына дога кылу, Коръән уку белән башланып китә. Шөкер, язучыларыбыз, зыялыларыбыз, дин әһелләребез Сасна Пучинкәсе зиратында еш булалар.

Шигырь-багышламалар да күренгәле. Тик зурдан кубып сөйләшкәндә, Тукай Анасының әле һаман әдәби һәм медиа киңлекләрендә үзенә тиң лаеклы урынга чыга алганы юк. Шушы дәвамлы чор дәверендә, мәсәлән, махсус аңа багышлап язылган бер генә чәчмә әсәр басылып чыккан. («Казан утлары», «Бибимәмдүдә», № 4, 2016 ел).

Имеш...

Хәер, бу хакта соңрак, әүвәл абыстаебызның һәм дә якын даирәсенең тәрҗемәи хәлләрен тәфсилләп китү максатка ярашлырак булырдыр, мөгаен.

Аллаһы Тәгалә әлеге гыйззе мөшфика мөслимәсен ошбу якты дөньяга милләтебезгә Бөек шагыйрьне бүләк итү өчен генә җибәргән, күрәсең. Улы Габдуллаҗан туып, аз-маз тернәкләнеп китүгә, 26 яшьлек ананы янә үз биләмәсенә кайтара. Атасы Зиннәтулла хәзрәткә исә озын гомер насыйп иткән. Арада ул иң озак яшәгәне: фанида сиксәнне ваклый.

Зиннәтулла Зәйнелбәшир улы Әмирханов 1829 елда Уфа губернасы, Уса өязе, Кожмакты авылында (хәзерге Пермь өлкәсе, Барда районы) туа. Үсеп буй җитүгә, Казан янындагы мәшһүр Кышкар мәдрәсәсенә укырга килә. Мәдрәсәне тәмам иткәч, Зиннәтулла, остазы тәкъдиме белән, Кушлавыч авылына килеп мөәзин була. Аңа кадәр Чиләбе өлкәсендә балалар укытып алган дигән фараз да бар. Ничек булса, булгандыр, мөәзин соңарып гаилә кора, 34 яшьтә генә үзеннән ун яшькә кечерәк Камилә исемле Сәрдә авылы кызына өйләнә. Абыстай бер елдан, ягъни 1864 елда җәмәгатен кыз бала алып кайтып сөендерә. Нарасидәгә Мәмдүдә дип исем кушалар.

Белекле гаиләдә туса да, Мәмдүдәнең метрикәсе (таныклыгы) сакланмаган. Шуңа күрә ел исәбе белән генә хисапларга туры килә. Туган җире барлык чыганак-белешмәләрдә дә Өчиле авылы дип тәгаенләнә. Чөнки бу вакытта Зиннәтулла шушы авылга имам итеп билгеләнә. Тукайның Кырлай музеен яңартуга искиткеч зур хезмәт куйган «Таттелеком» оешмасының мөхтәрәм җитәкчеләреннән берсе – Рөстәм әфәнде Йосыпов шулай да икенчерәк фикерне алга сөрә, Кушлавычта туган дип бара, таныклыгын табасына да ышанычы зур. Бирсен Ходай!

Зиннәтулла яраткан хатыны белән унбер ел гына яшәп кала. Бибикамилә абыстай ирен, 10 яшьлек кызын калдырып, 35 яшендә вафат була. «...Зиннәтулла үзенең гомерен китаплар күчерү һәм оригинал шигырьләр язу белән үткәрә. Ул байлыкка, малга әһәмият бирми.

Зиннәтулланың сөеп ашаганы – дөге ашы шулпасы булып, итне ашамаган, ит гомерне кыскарта, ди торган булган һәм шуның өстенә кайнар чәйне бик яратып эчкән. Үзе арык, озын буйлы, кара тутлы, озынча битле, мыеклы, сирәк кенә очлырак сакаллы булган».

Балтачлыларга рәхмәт, алар Бибимәмдүдә абыстайны олылап, хөрмәт белән искә алалар, хәтерен күз карасыдай саклыйлар.

Бу юллар Тукайның замандашы һәм дусты, шагыйрь Миргазиз Укмасиның «Шагыйрьнең тормыш сәхифәләреннән» исемле мәкаләсеннән китерелде. Аннан күренгәнчә, Зиннәтулла үз чорының укымышлы һәм белекле, дөньяви вә дини тәгълиматларны тирәннән үзләштергән киң карашлы зыялыларыннан саналган. Кызганыч, мирасыннан безнең көннәргә Тукай музеенда саклanучы Коръән китабы һәм кызы Бибимәмдүдәгә багышланган мәрсия шигыре генә килеп ирешкән.

Билгеле инде, югары гыйлем иясе ата кеше балаларында яшьтән үк белемгә омтылыш, милли тарихка, матур әдәбиятка мәхәббәт хисләре тәрбияләгән. Мәмдүдә дә уңган-булган, шагыйранә бер мөлаем сылу булып үскән. Нәрсәгә тотынса да, эше җырлап кына барган.

Зиннәтулла икенче никахта Наласа авылыннан Алтынчы Фәткулланың 18 яшьлек Латыйфа атлы кызы белән кавыша. Камилә абыстайдан аермалы буларак, Латыйфа муллабикә чын мәгънәсендә истәлек-хатирәләрнең әһле мәликәсенә әверелә. Кем генә язмый, нәрсә генә язмыйлар?! Һәм барысы да негатив. Эпитетлары гына нинди бит: усал, зәһәр, дорфа, мәрхәмәтсез... Югыйсә менә дигән, тормышта үз юлларын тапкан алты бала – өч кыз, өч ул табып үстергән Ана, һичьюгы, ихтирамга лаек зат булырга тиеш ләбаса! Ни гаҗәп, бу уйдырма-гайбәтләрнең тууында Тукайның да өлеше бар. Аның «Исемдә калганнар» автобиографик кыйссасындагы бер өзеккә генә мөрәҗәгать итик: «Минем анамның анасы булган үз әбием әни кыз чактук үлгән булганга, бабай кайсы мулланыңдыр тол калган бер хатынны аңар ияреп килгән алты баласы илә алган булган.

...Үги әбинең алты күгәрченнәре эчендә мин бер чәүкә булганга, мине җыласам – юатучы, иркәләнимдисәм – сөюче, ашыйсым-эчәсем килсә, кызганучы да булмаган, мине эткәннәр дә төрткәннәр».

Тукай тәрҗемәи хәленең бу өлешен авыл куштаннары сөйләве, ишеткәннәре (ә кешеләр гайбәттән хали түгел) буенча гына тасвир итсә дә, гөнаһ шомлыгына, аны барысы да чын көмешкә санаган. Шулай булмыйча, Тукай үзе тәфсилләп язган рисаләгә ышанмау мөмкинме соң? Мәктәп дәреслекләре буыннан-буынга шушы аксиома дәрәҗәсенә җиткерелгән кире каккысыз дип исәпләнгән постулатны укучылар аңына сеңдереп килде.

Һәм... аяз көнне яшен яшьнәгәндәй, гап-гади бер география укытучысы әлеге «ияреп килгән алты бала» теориясенә шик белдерергә җөрьәт итә.

И мөкаддәс моңлы сазым! Уйнадың син ник бик аз?

«Азат хатын» журналында эшләгәндә бу мөлаем йөзле, ыспай буй-сынлы, йомшак сүзле, зыялылыгы бөтен килеш-килбәтендә нур булып балкыган мөгаллимә апа – Зәкия Рәсүлева редакциягә килеп йөри иде, шагыйрь тормышына бәйле мәкаләләрен тәкъдим итә иде. Мөгаллимә апабызның Тукай һәм аның якыннары белән тирәннән кызыксынуы һич тә очраклы хәл түгел иде, әлбәттә. Чөнки ул Тукай күңелендә гыйшкый хисләр уяткан Зәйтүнә килене, Зәйтүнәнең улы галим һәм танылган язучы Атилла Расихның җәмәгате иде!

– Тукай буыны инде китте, шулай да аны турыдан-туры күреп белүче, аралашып йөргән туган-тумачалары, замандашлары әлегә бар, мин шуларны бөртекләп барлауга дүрт-биш ел гомеремне багышладым, тырышлыкларым бушка китмәде, күп нәрсәне ачыкладым, – дигән иде ул бер әңгәмә вакытында. – Шөкер, эзләнүләремне әле дә дәвам иттерәм.

Зәкия Рәсүлеваның «Тукай эзләреннән» исемле 142 генә битле бу китабы (1985 ел) шагыйрь һәм аның даирәсе турында язылган иң тулы, иң нәзакәтле, иң кешелекле, иң хак кимәлле мөкаммәл мәҗмуга. Ул, муенсага тезелгән сәйлән кебек, автор тарафыннан тикшерелеп, энә күзеннән үткәрелгән бихисап күп истәлекләргә, искиткеч бай тәгаен хак фактларга нигезләнгән. Профессор Зөфәр Рәмиев бик дөрес әйтә: «Күп эзләнүләр нәтиҗәсендә туган... китап менә утыз ел инде Тукайның шәхси тормышы белән кызыксынучылар кулыннан төшми». Хак, шәхсән үземә дә «Бибимәмдүдә», «Зинәтулла хәзрәт», «Саҗидә», «Газизә» исемле әдәби әсәрләремне язарга нәкъ шушы могҗизаи китап азык бирде, иҗатка рухландырды.

Инде янә «ияреп килгән алты бала» кыйссасына әйләнеп кайтыйк. Әүвәл Зәкия апа таныклыклар мәсьәләсендә Уфа Диния нәзарәтенә мөрәҗәгать итә. Ник дисәң, патша чорында туу турындагы таныклыкларны авыл муллалары тутырган, ә тиешле вакыт җитүгә, алар нәзарәткә җибәрелгән. Тик бу очракта нәзарәт инде ул елгы документларны дәүләт архивына тапшырган була. Ниндидер сәбәпләр белән Уфа да ярдәм итә алмый. Аның урынына үзебезнең Татарстан дәүләт архивы ярдәм кулын суза.

Ниһаять, озын-озак маҗаралардан соң көннәрдән бер көнне хат ташучы аңа таныклык нөсхәләре салынган конверт китереп тапшыра. Шулай итеп, «ияреп килгән алты бала» мәсьәләсе тәмам ачыклана. Алар ияреп килүчеләр түгел, Зиннәтулла хәзрәт белән Латыйфа абыстайның уртак балалары – Бибимәмдүдәнең туганнары. Афәрин, Зәкия апа!

Мулла кызларына, гадәттә, тынгы бирмиләр, бик иртә яучылыйлар. Ә менә Мәмдүдә 21 яшькә кадәр ата йортында кала бирә. Үги әнисе, әнә, дүрт бала табарга өлгерә, ә ул һаман кузгалырга артык атлыгып тормый. Моның сәбәпләре тәгаен гына мәгълүм түгел, бәлкем, сайлануыннандыр, бәлкем, кияү егетләренең аның кебек укымышлы, зыялы, чибәр мөслимәгә мөрәҗәгать итәргә кыймауларыннандыр. Кушлавычта туып-үскән язучы Әнәс Галиевнең сурәтләвенә караганда: «Мәмдүдә озынчарак йөзле, сызылып киткән кара кыйгач кашлы, матур кылыч борынлы, төскә-биткә чибәр, матур буй-сынлы» кыз булган.

Зиннәтулла хәзрәт, ниһаять, бу икеле-микеле хәлгә чик куя, кызын җәмәгате вафат булган 43 яшьлек Кушлавыч мулласы Мөхәммәтгарифка никахлый. Бу 1885 елның июнь ае була.

Яшь кызга ике бала өстенә төшү җиңел булмагандыр, билгеле. Ләкин Мөхәммәтгариф белән алар бик тиз уртак тел табалар, яратышып яшиләр. Хәзрәт тирә-якта бик күркәм кеше була. Уртачарак буйлы, коңгырт чәчле, зәңгәрсу күзле, матур борынлы. Үзе телгә-сүзгә бик оста. Мәзәкчел. Кием-салымы купшы: башында кырпулы каракүл бүрек, аны кылтык кына кыңгыр да салып җибәрсә... Ясап куйган кияү егете!

Шатлык өстенә шатлык, 1886 елның кояшлы вә якты апрель аенда бәхетле ана җәмәгатен ир бала алып кайтып куандыра. Мөхәммәтгариф үз кулы белән метрикә кенәгәсенә улының исемен «Габдуллаҗан» дип язып куя. Әнисе исә малаен: «Җан Габдуллам, якутым, гәүһәрем!» – дип сөя торган булган.

Тормыш көйләнә, үги балалар да яшь әнине үз итә, тәти апай, дип үлеп торалар.

Мөхәммәтгариф хөр күңелле, ирек сөюче, кадими кануннардан азат һиммәт иясе кеше була. Шуңа күрә булса кирәк, муллалыкны өнәп бетерми, балаларын да ул юлдан җибәрергә теләми.

Мин Ибраһим Нуруллинның «Тукай» романында хәзрәтнең хәмер эчкәләве турында укыгач, моны советларның дин әһелләренә карата чираттагы уйдырмасы дип кенә кабул иткән идем. Тик Тукай турындагы язмаларны, истәлекләрне җентекләп өйрәнә башлагач, әлеге мәсьәләгә янә бер-ике тапкыр килеп төртелдем. Шул уңайдан М. Укмасиның алдарак телгә алынган мәкаләсеннән бер өзек китерү мәгъкуль булыр: «Мөхәммәтгариф бераз эчкәләргә дә ярата торган булган. Бервакытны Арча базарыннан эчеп кайткач, кайнатасы Зиннәтулла моны сизә дә, Мәмдүдәнең китап тышына түбәндәге сүзне язып куя: «Әллә, кызым, моннан аерыласыңмы? Аерылып кайтсаң да, миннән сүз булмас», – ди. Мәмдүдә атасының бу язуын укыгач, шул ук китап тышына түбәндәге шигырьне язып куя: «*Бези мундан аергандан, / Бези утларга салганнан / Ля язырры вә лә янфәге / Моны фәһем ит, газиз әткәй*». Ягъни: «Безне бер-беребездән аерып, безне утка салудан бер файда да юк икәнен аңла син, әткәй» дигән сүз.

Ни үкенеч, күп тә үтми, бер елдан аз гына артыгракка сузылган бу бәхетле кыска никахны ачы үлем өзә. Яраткан хатынын, дүрт ай ярымлык нәни улын калдырып, Мөхәммәтгариф кырык дүртенче яшендә «кату зәхмәте илә» фани дөнья белән саубуллаша.

Тол калган Бибимәмдүдә улы Габдуллаҗанны күкрәгенә кысып, Өчилегә, болай да ишле атасы йортына кайтып егыла. Нигә ул Кушлавычта калмаган? Килен булып төшкән җирдә аның да хокукы бар ич. Иң мөһиме: мирас иясе төпчек ир бала – Габдуллаҗан лабаса!

Шәхсән мин үзем бу хәлнең эчке катмарларына төшеп җитә алмадым.

Бибимәмдүдә тагын өч елга якын үги ана канаты астында кысылып яши. Тол хатынга мунчаның актыгы, түшәкнең ястыгы, ди, монысы инде өйдәш хатын сыйфатында. Димчеләр дә сукмакны суытмаганнардыр, әлбәттә, әмма Бибимәмдүдә ашыкмаган. Бәгъзе галимнәр фаразынча, ул, үзеннән бигрәк, Габдуллаҗанның хакын хаклап сайланган. Әлеге фикер минем фикер белән дә тәңгәл килә. «Бибимәмдүдә» кыйссасы нәкъ менә шушы фараз нигезендә язылды да инде.

Шул рәвешле, 25 яшьлек абыстай 70 яшенә чыккан Сасна Пучинкәсе авылыннан килгән Мөхәммәтшакир мулла яучысына уңай җавап бирә. Никахны 1889 елның 3 гыйнварында Өчиледә Зиннәтулла хәзрәт үзе укый. Кияү 30 тәңкә мәһәр бирә. Бу вакытта Габдуллаҗанга 2 яшь тә сигез ай була. Кияүгә киткәндә анасы улын (бер кибән арыш хисабына) вакытлыча Кушлавычның Шәрифә атлы карчык тәрбиясенә калдыра. Бу ике-өч буын татар зыялылары каһәрләп каргаган мескен әбекәй кыйссасына озын-озак тукталып тормыйча, мөнәсәбәтемне Тукайның үз сүзләре белән генә белдерәсем килә: «Аллаһ аңар рәхмәт итсен».

Бибимәмдүдә өчен әлеге никахның уңайлыгы шунда – «мулланың баласы булмый» (М. Укмаси). Ә Габдуллаҗанга чын әти кирәк.

Вакытлыча дигәнебез үз эченә өч-өч ай ярым чамасы араны били. Әнисе улын бик сагына, бик юксына, бик хафалана. Сагыш хис-тойгылары шигъри теземнәргә салына: «Өй түрендә бакчада бер сандугач сайрый, / Нигә сайрый бу сандугач кагынып? / Шуны сайрый: / Минем елаганны белеп, баламны сагынып».

Габдуллаҗан үги әтисен бер күрүдә ошата. «Исемдә калганнар»ында аны ихтирам белән искә алып: «...Үги әтиемнең мине сөюе, миңа чәй янында кәрәзле балны ак күмәчкә ягып бирүе, минем шунда куанганнарым биш минутлык төш шикелле генә әле дә булса хәтеремдә», – дип яза. Бу сәмави җөмләләр белән танышкач, хәзрәтнең кайбер чыганакларда искә алынган кансызлыгы, усаллыгы ничектер тоныкланып кала. Көнчеллегенә сыеша алмыйча хатыны Бибимәмдүдә абыстайга кул күтәргән, кыйнаган, рәнҗеткән дигән гаепләүләргә ышанасы килми башлый. Хәлбуки, ул гаепләүләр, миңа калса, фаразлауларга гына корылган да.

«Хәер, бу хакта соңрак» дигән гыйбарә-җөмләбезгә әйләнеп кайтырга да, ниһаять, вакыт җитте булса кирәк.

«Мине шайтан котырта, баш миен кирәкмәгән сораулар бораулый. Мәмдүдә абыстай Пучинкәгә кияүгә чыкканда нигә сабыен Шәрифә карчыкка калдырган, нигә үзе белән алып китү шартын куймаган?»

«Татарстан яшьләре» (31 август, 2017 ел) журналисты Рәфхәт Зарипов биргән бу сорау һич тә яңалык түгел. Ул набат булып, гасыр дәвамында яңгырый һәм нәкъ менә шушы хәл Милләт анасы – Бибимәмдүдә абыстайга гаеп ташлауның сәбәбе булып тора да инде: нигә баласын үзе белән алмаган, ташлап киткән?

Ташлап китмәгән, вакытлыча калдырып торган. Алар кавыша ич, мәхдүмне Мөхәммәтшакир ат җибәреп үзенә алдыра. Тик бу бәхетнең көннәре генә санаулы була. Бибимәмдүдә сырхаулап китә һәм озак та тормый дөнья белән хушлаша.

Зиннәтулла хәзрәт кызының үлемен бик авыр кичерә: юксына, еш кына каберенә барып, догага оеп утыра. Шигырьләрен багышлый. Бер килүендә «кызына атап, түбәндәге шигырен укый» (М. Укмаси): «*Нуры газизем, кызымның төрбәседер бу мәзар. / Әйләмеш нәзек вөҗүден хак дәвре рузыклар, / Исме Бибимәмдүдәдер гаилә ирде гаян...*» Мәгънәсе: «Газиз нурымның кабере бу урын, дөньяның туктаусыз әйләнеп исә торган җилләре аның нәзек гәүдәсен туфрак иттеләр...»

Тукайның шигъри таланты бабасыннан килә. Бу талант, күргәнебезчә, Бибимәмдүдәгә дә насыйп ителә. Зиннәтулланың Латыйфа абыстайдан туган, Габдуллаҗанның иң яраткан, үз сүзләре белән әйткәндә: «йомшак күңелле ак фәрештә» – Саҗидә апасы да тезем сүзгә сәләтле булган. Шуннан соң нәсел геннары шагыйранә хәтерләрен оныткан, күрәсең, ыруны укытучылар, табиблар, архитекторлар, хәрбиләр, инженерлар, игенчеләр, эшчеләр, сәүдә әһелләре дәвам итә. Зәкия Рәсүлева шуларның утыз өчесе турында җентекләп мәгълүмат туплый.

Без Бибимәмдүдә белән Мөхәммәтгарифны архитектор Әлфия Зәбирова (Тукайның ата – бер, ана – башка Газизә апасының оныгы) ясаган график портретлардан күреп беләбез. Бу аларның берданбер төп нөсхәгә якын сурәтләре.

Тагын бер бик тә мөһим, күпләрне кызыксындыручы бер теманы читләтеп узсак, хак-хакыйкатькә хилафлык кылган булыр идек. Тукай Кушлавычка, Өчилегә еш кына кайтып йөргән. Ә менә Сасна Пучинкәсенә барып, әнисе каберенә зиярәт кылганмы?

Белгәнебезчә, Габдулла әти-әнисен һәрвакыт исендә тоткан, күңеле түрендә йөрткән. Моңа Җаектан Каенсарга, Саҗидә апасына язган хаты да дәлил. «Хәзер дә атам-анама һаман Коръән укып торам, Мәүлам кабул итсен», – дип яза.

Әнисе каберенә баргнмы – бәлки, баргандыр, бәлки, бара алмагандыр, – бу хакта мәгълүмат юк. Хәлбуки, аның әле үги атасы Мөхәммәтшакир хәзрәт тә исән була. Ул 97 яшендә 1916 елда гына вафат.

Тик әлеге җәһәттән шуны да истән чыгарырга ярамый, бу Тукайның сәламәтлеге шактый какшаган вакытлар, аның ерак сәфәргә йөрерлек кәефе дә, көче дә, хәл-хәлләте дә инде бик чикле була.

Күр, рәсма тулган иман берлә Коръән садремә!

Менә бу чын Тукай. Әнисенә шигъри һәйкәл куйган иманлы вә әһле хәтерле тәкъваи Тукай:

Бар күңелләрдән җылы, йомшак синең кабереӊ ташы, –
Шунда тамсын күз яшемнең иң ачы һәм татлысы!

PRESSA

ТАТАР ФЕМИНИЗМЫ-2

(Дәвамы. Башы журналыбызның икенче санында.)



Совет хакимияте шартларында татар хатын-кызлары нишләгәнме? ТАССРда яши башлагач, алар да туташ, ханымнардан тиз арада «иптәш»кә әйләнгән.
«Иске тормыш»ка чыдый алмыйча, Рязань өлкәсендәге Әҗе авылында яшәгән җиреннән качып киткән чая кыз Заһидә Бурнашева Казанга килеп, җәдидчеләр чыгара торган газеталарда «Гыйффәт туташ» тәхәллүсе белән шигырьләр чыгара. 1917 елгы Октябрь инкыйлабын шатланып каршы ала, татар хатын-кызлары арасында беренчеләрдән булып актив көрәшкә кушылып китә. 1918 елда Коммунистлар партиясе әгъзасы була. Шул ук елны иптәш Бурнашеваны Урта Азиягә җибәрәләр. 1952 елда пенсиягә чыгып, Казанга кайта. 1971 елда аның архив материалларына, үзенең һәм революция ветераннарының истәлекләренә нигезләп язган «Татар хатын-кызлары хәрәкәте тарихыннан» исемле китабы дөнья күрә.
1977 елда вафат була...



Ландыш
ӘБҮДӘРОВА

«Минем атамның гомер-гомергә күргәне бары биш-алты авыл булган. Ә мин – аның кызы – Москвада тордым, Ленинградта булдым, Харьков, Ташкент, Бакуны күрдем…»

Такташ белән Кутуйның мәхәббәт концепциясе

Хатын-кызны «гаилә коллыгыннан» азат итү шаукымы бөтенләй үк эзсез үтми. Өстәвенә, ул вакытта бик күп татар кызлары башкалага укырга китә. Бу турыда 1926–1929 елларда «Азат хатын»да җаваплы сәркатип булып эшләгән Һади Такташ шигырьләреннән укыйбыз. Мәсәлән, «Мәхәббәт тәүбәсе»ннән:

«Зөбәйдә…
Ул тиздән ана булыр,
Доктор шулай дигән аңарга…
– Йөрәк,
Ян син, ян син, йөрәк!
Кан бирелгән сиңа янарга!..
Ә син кайда, ата булыр кеше?
Шулмы булды синең сөюең?
Шулмы инде синең:
Иректә сөю,
Яңа тормыш диеп йөрүең?..»
(1927)

1928 елда Такташ «Югалган матурлык» дигән сәхнә әсәре яза. Бу драма 1929 елның 18 гыйнварында Татар академия театрында уйнала. Ләкин шунда ук репертуардан төшеп кала, чөнки матбугатта Такташны гаилә мәсьәләләрен дөрес аңламауда, хатын-кызларны «коры ана гына итеп, аларны бөек эшләрдән, ирләр белән тормышта берләштән барудан мәхрүм итүдә», әсәрне идеологик яктан зарарлы булуда гаеплиләр. Ә Такташ бит хатын-кызга:

«Яшьлегемне үзем
Теләп бирәм кулыңа.
Ләкин тыңла мине,
Иптәш тә бул миңа,
Ана да бул минем улыма», –
дигән иде.

Такташның «Алсу» поэмасын да бик күпләр яттан беләдер әле. Бу әсәрне ул беренче хатыны Гөлчәһрә Хәмзинага багышлап язган. Гөлчәһрә – кыю, ут чәчеп торган кыз. Ул да яңача яшәүчеләрнең берсе булган: 16 яшендә Такташка кияүгә чыгып, улы Рафаэльне тапкач, Мәскәүгә юрист булырга укырга китеп бара. Рафаэль 3-4 яшенә кадәр әтисе тәрбиясендә үсә. Мәскәүдән кайткач, алар аерылышалар. Такташ улын никадәр генә үзендә калдырырга тырышса да, Гөлчәһрә суд аша аны үзе белән Мәскәүгә алып китеп бара… Шулай да Такташның гаиләсен дә онытып бетерми: Такташ вафатыннан соң, улы Рафаэльгә тиешле пенсияне, «Мин монда (Мәскәүдә) икебезне генә туйдырырлык акча эшли алам», дип, Такташның авыр хәлдә калган әтисе Хәйрулла абзый белән әнисе Шәмсениса апага җибәреп бара…

Гөлчәһрәнең энесе Касыйм Хәмзинның әлеге гаилә турында бер матур хатирәсе бар.

«1927 ел. Такташның кәләше Гөлчәһрә Хәмзина яңа күлмәк сатып алып кайткан. Материясе дә шәп, төсе дә аллы-гөлле, әмма чабуы ерык. Нәкъ арт яктан ярты аршын чамасы икегә ярылган.

Кич. Театрга тамаша карарга барырга әзерләнәләр. Һади сырланып тормый. 10-15 минутта киенеп, галстук тагып, тройной одеколон сөртенеп чыга. Әмма яшь кәләш назлана, тегесен сала, бусын ала.

– Галя, син нәстә, әллә ертык күлмәк киеп театрга, да?..

– Ертык түгел, яңа мода.

– Ташла, пожалуйста, сурьёзно әйтәм. Арттан күренә.

– Һади җаным, син не понимаешь, бу – французская мода.

Такташ тын гына басып тора. Елмая, көксел чәчен сыйпап ала, селкенеп куя. Бер адым Гөлчәһрәгә таба атлый. Ярык чабуга кулын тидереп ала.

– Каерма!

– Галя, тыңла. Ничек залдан үтәргә? Анда интеллигенция, Фатих Сәйфи, Нигъмәтиләр, Болак арты татарлары. Сал, кимә!

– Ни за что!

Песи балалары идәндә бутала. Яшь кәләшнең чабуына сикерә. Аларга кызык. Ә Такташ рәхәтләнеп көлә.

– Брысь! Атеистлар! – ди Гөлчәһрә.

Ниһаять, чирек сәгатьтән бүлмәдә тынлык урнаша.

Икенче көнне «Җырым сиңа булсын» дигән шигырь туа. Ул яшь кәләшкә төбәп язылган.

«Әйтче, кызый, болай киенергә
Нинди шайтан сине өйрәтте?
Инде тездән узган
күлмәк итәкләрен
Ертык ясау нигә кирәкте?»

Такташның дусты, язучы Гадел Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар» повесте (1935) да яңа заман хатын-кызы образын тудыра. Яшь доктор Галия совет хакимияте биргән мөмкинлекләрдән хозурланып болай дип яза:

«Мин диңгездә йөздем, Кавказ тауларына мендем. Минем атам үз телен дә кирәгенчә белмәгән. Ә мин – аның кызы – татарча гына түгел, рус, немец телләрендә сөйләшәм. Минем атам бөтен гомерен көтүчелектә, газап-михнәт эчендә уздырган, үлгәндә дә сарыклар арасында үлгән. Ул бик еш сырхаулаган, ләкин бер генә тапкыр да докторны күрмәгән. Ә мин – Чулак Фәхри кызы – хәзер үзем доктор».

Әсәр 1934 елда игълан ителгән социалистик реализм кысаларына кертелеп, никадәр генә Галиянең уңай образы тудырылмасын, Кутуй әлеге әсәрендә мәхәббәт һәм гаиләнең зур җаваплылык булуы турында яза, шул ук вакытта бу җаваплылыкның беренче чиратта ир-атларга кагылуын күрсәтә.

Индустрияләштерү яңа герой таләп итә. Андый герой табыла да.

«100 000 иптәш кызны – тракторга»

1929 елда Украинаның бер авылында 16 яшьлек грек кызы Прасковья Ангелина, әти-әнисенең сүзен тыңламыйча, механизаторлар курсына укырга керә. Һәм авылына кайтып, трактор руле артына утыра. Ул хатын-кызның тракторда җир сөрә алуын гына исбатлап калмый, ә стахановчылар хәрәкәтеннән берничә ел алдан, ирләрне дә узып, планны ике тапкырга арттырып үтәп күрсәтә. 1933 елда бригадир була.

Сталин бу кызны шунда ук үз итә. Паша коммунизм төзүче хатын-кыз хезмәт иясе мифының тере гәүдәләнеше булып китә. Фоторәсеме журнал тышлыкларыннан төшми, тиз арада Ленин ордены белән бүләкләнә, 24 яшендә – Югары Совет депутаты, 26 да – Хезмәт Кызыл Байрагы ордены кавалеры. Ир хатыны, балалар үстерә, көндез трактор руле артында, төннәрен укый, кыскасы, тәүлегенә дүрт сәгать йоклый.

1938 елда Пашаның «100 000 иптәш кызны – тракторга» дигән шигаре басылып чыга. Нәтиҗәдә, хатын-кызлар 200 мең тракторны басу-кырларга алып керә. Шушы хатын-кызларга сугыш һәм репрессияләр вакытында ирләрне алмаштырырга туры килә.

«Азат хатын»ның 1939 елгы һәр санында «Стахановчы Сара» (август), «Тракторчы Зифа» (сентябрь), «Стахановчы Бану» (октябрь), «Коммунисткалар – производство алдынгылары» (ноябрь) кебек мәкаләләр дөнья күреп бара.

1938 елда журнал «СССР Верховный Совет депутатлары арасында 184 хатын-кыз, РСФСР Верховный Совет депутатлары арасында 157 хатын-кыз бар. Хезмәт фронтында да хатын-кызлар шулай ук беренче сафта торалар», дигән мәгълүмат бастыра.

«Безнең илебезнең барлык хезмәт иясе хатын-кызлары, нинди милләттән һәм нинди расадан булуларына карамастан, дәүләтне идарә итүдә турыдан-туры катнашалар. Социализмның җиңүләре теркәлгән Сталин Конституциясендә Совет власте елларында хатын-кызларның яулап алган барлык казанышлары да чагылдырыла», – дип яза журнал.

Җитештерүдә, индустрияләштерүдә төп көч булып киткән хатын-кызларга Ватан яңа бурычлар йөкли. Дөресрәге, искесен кайтара.

Бөек Ватан сугышы тудырган демографик кризис хатын-кызлардан күп бала табып, Ватанга хезмәткә батыр уллар, матур кызлар үстереп бирүне дә сорый. 1944 елда СССРның Югары Советы Президиумы карары белән аерылышулар катлауландырыла, ә инде ун бала тапкан аналарга «Герой-ана» ордены бирелә башлый. Дөрес, балаларның унысы да исән, иң кечесенә 1 яшь тулган булырга тиеш. Шулай ук «Ана даны» медале дә булдырыла. 1995 елга кадәр әлеге бүләккә СССРда 5 534 724 хатын-кыз лаек була.

Шулай ук абортлар ясау 1956 елга кадәр тыела, бала табу, киресенчә, хуплана. Бу җәһәттән вакытлы матбугат та пропаганда алып бара. Мәсәлән, «Азат хатын» да сугыштан соңгы елларда «Мин бәхетле ана» исеме астында: «Абортларны тыю, бала тудыручы аналарга материаль ярдәмне арттыру, күп семьялыларга дәүләт пособиесе билгеләү турында»гы закон чыкканнан бирле тугызынчы балама дәүләт пособиесе алып киләм. Хәзер унынчы балам туды...» дигән эчтәлекле хатлар басылып тора.

Шул рәвешле, Россиядә хатын-кыз үзе дә сизмәстән, Ватанның төп көченә әйләнә. Бүгенге хатын-кызларның гаиләдә – яхшы хатын, әйбәт әни, эштә алдынгы хезмәткәр дигән стереотибына нәкъ шул вакытта нигез салына. Дөрес, бераз соңрак хатын-кызларга карата таләпләр күпмедер йомшара (мәсәлән, аерылышулар җиңеләя, декрет ялы, балаларга пособие бирелә башлый, белем алу мөмкинлекләре зурая), ләкин болары «җепшеклек»тә, «җепшеклек»тә...

Елына бер көн...

1940 елның март санында «Азат хатын» журналы «Халыкара коммунистик хатын-кызлар көне – 8 Март турында» ВКП(б) Үзәк Комитеты карарын бастыра. «Сөембикә»нең март санына шул карардан өзекләр тәкъдим итәбез:

«Совет хатын-кызлары моннан элек ирләр генә булдыра алган иң катлаулы профессияләрне һәм специальностьларны уңышлы рәвештә үзләштерәләр. Тимер юл транспортында хатын-кызлар машинистлар булып, металлургиядә корыч коючылар булып, күмер промышленностенда күмер казу машиналарының машинистлары булып эшлиләр һәм башка Советлар Союзының эре промышленностенда хатын-кызларның тоткан урыны 41,6 процентка җитте...»

«ВКП(б) Үзәк Комитеты партия оешмаларын, – халыкара коммунистик хатын-кызлар көнен – 8 Мартны массовый-политик кампания итеп үткәрергә, СССРның хезмәт ияләрен капиталистик коллыктан азат итүнең бөтен дөнья күләмендәге тарихи әһәмиятен, совет хатын-кызларының коммунистик җәмгыятьне актив төзүчеләрнең тулы хокуклы, ирекле хәле белән капиталистик илләрдәге хатын-кызларның изелеп яшәве арасындагы тирән аерманы күрсәтергә мәҗбүр итә.»

Фото: Актриса Галия Булатова апасының кызы Әлфия Позднякова белән. «Сөембикә» («Азат хатын») журналы архивыннан.

ГҮЗӘЛ ЗАТЛАР ҺӨҖҮМЕ

Атлас ГАФИЯТОВ, «Татарстан яшьләре» газетасының баш мөхәррире



Тарихта матриархат чоры булуы билгеле. Исеменнән үк күренгәнчә, ул чорда дөнья белән, нигездә, хатын-кызлар идарә иткән. Соңгы вакытта гүзәл затларның зур-зур предприятиеләр белән җитәкчелек итүе, министр, хәтта президент, премьер-министр вазыйфаларын башкарулары на да шактый мисаллар китереп булыр иде. Мин инде аларның элек ир-атлар гына башкара торган авыр физик эшләрдә дә катнашуларын әйтеп тормыйм.

Кызыкмы, кызганычмы – алар спортта да ирләр белән бертигез «атлый» башлады. Гүзәл затларыбыз ерак дистанцияләргә йөгерәләр, көрәшәләр, тукмашалар (бокс, каратэ, тхеквондо...), ду китереп футбол, хоккей уйныйлар, штанга, гер күтәрәләр... Аларның волейбол, баскетбол теннис уйнаганнарын, чаңгыда узышканнарын аңлап та, аклап та буладыр, ә менә ирләр белән бертигез булабыз дип дзю-до, самбо, ирекле көрәш ярышларында катнашуларын, үз гәүдәләреннән авыррак штанга күтәрүләрен, рингка чыгып бер-берсен тукмауларын тыныч кына күзәтеп булмый. Нәрсә бу – матриархат чорына кире әйләнеп кайтумы әллә? Югыйсә тарихтан билгеле: безнең эрага кадәр үк борынгы Грециядә үткәрелгән Олимпия уеннарына хатын-кызлар бөтенләй кертелмәгән. Борынгы заман ир-атлары хәзергеләреннән акыллырак булган шул – алар хатын-кыз стадионда йөгереп йөрергә тиеш түгел, беренче чиратта гаилә җылысын сакласыннар, балалар үстерсеннәр дип куйганнар. Кайберәүләр мин фәкыйрегезне дә тар карашлыкта, искелектә һәм субъективлыкта гаепләргә мөмкин. Әмма алар дөрес аңласыннар: 30 елдан артык спорт хакында язган кеше буларак, мин гүзәл затларыбызның нәфис гимнастика, фитнес, йөгерү белән шөгыльләнүенә, волейбол уйнавына, чаңгыда, тимераякта йөрүенә каршы түгел. Ә менә кайбер төрләрне чыннан да карап тора да, алар хакында мактап яза да алмыйм. Әйтик, көрәштә, бокста кызларны көндәшләрен сугып егарга, аяк-кулларын, башларын каерырга, тупаслыкка өйрәтәләр. Аннан соң әлеге төрләр белән озаклап шөгыльләнүчеләр, чыннан да, хатын-кызларга хас гәүдә нәфислекләрен югалталар, йөрешләре, хәтта сөйләшүләре белән дә ир-атларга охшый башлыйлар. Заманында үзе дә көчле спортчы булган, соңрак Мәскәүдәге Үзәк травматология һәм ортопедия институтында эшләгән профессор Зоя Миронова болай дип язган иде: «Хатын-кызларның спорт белән шөгыльләнгәндә алган микрожәрәхәтләре, яши-яши, макрожәрәхәтләргә әйләнә. Алар ядрә ыргыту, штанга күтәрү, көрәш кебек төрләргә бөтенләй якын килмәскә тиеш. Чөнки әлеге төрләр белән шөгыльләнүче кызлар ана булу бәхетеннән мәхрүм калырга мөмкин». Спорт функционерларына әнә шундый белгечләр фикеренә колак салырга иде дә бит, юк шул – Олимпия уеннары программасына да, Дөнья чемпионатларына да элегрәк ир-атларныкы гына дип саналган байтак спорт төрләре кертелә. Хатын-кызлар гандболы, чирәмдә уйналучы хоккей, футбол... Кулларына кәшәкә тотып боз өстенә дә чыктылар, штанга күтәрү дә алар өчен Олимпиада программасына кертелде. Әллә кайларга китеп мисаллар эзлисе дә юк: Мамадыш районының Җөри авылында керәшен кардәшләребезнең ел саен үткәрә торган кечке Сабантуй программасына хатын-кызлар бил алышуы да кертелгән. Авырлыклары 80–100 килограммга җитүче хатыннарның мәйдан уртасында бер-берсен күтәреп алып яшел чирәм өстенә ыргытуларын карап торганыгыз бармы? Бер дә күңелле күренеш түгел.

Әгәр янә тарихка мөрәҗәгать итсәк, илләр белән илләр сугышканда да хатын-кызларыбызның ир-атлар белән рәттән кулларына корал алуларын күрербез. Россиядә алар хәтта йодрык сугышларында да катнашкан, дуэльләрдә дә атышкан. Хәтта дуэльләренең ир-атларныкына караганда рәхимсезрәк, мәкерлерәк, ягъни астыртын булуын язып калдырганнар. Аларны көндәшләренең яралануы гына канәгатьләндермәгән, аны үтерергә тырышканнар. Кайчагында шпагаларының очына агу сөртүчеләр дә, пуляларын агулаучылар да очраган. Ярый әле дуэль заманнары артта калды.

Күптән түгел генә «Комсомольская правда» танылган якташыбыз, чаңгыда узышу буенча ике тапкыр Олимпия уеннары чемпионы, дүрт мәртәбә Дөнья чемпионы Ольга Данилова хакында язып чыкты. Шәһәрнең физкультура һәм спорт бүлеге начальнигы Ольга кабинетына кергән спорт мәктәбе директоры Екатерина Шагова белән талаша башлаган һәм соңрак аны Яңа ел чыршысы белән кыйнаган. Хәзер прокуратура әлеге эшне тикшерә икән.

Соңгы вакытта спортчы хатын-кызларның көч арттырырга теләп, төрле тыелган матдәләр (допинг) кулланулары да күп кенә җәнҗаллар китереп чыгарды. Хәзер допинг куллнамы-юкмы икәнлеген тикшерү белән бергә, спортчыларның хромосомаларын да тикшерәләр. Тупас кына итеп әйткәндә, спортчының ир-атмы, хатын-кызмы икәнлеген ачыклыйлар. Ни өчен дигәндә, ир-атларныкы дип саналган спорт төре белән шөгыльләнүче, көч арттырам дип төрле дарулар, препаратлар кулланучы хатын-кызларның организмында ир-ат хромосомалары күбәя башлаган. Кем әйтмешли, килеп җиттек...

ЗУР СЕРЕ СИН



«Шулай матур гадәткә әйләнде инде: 8 Март алдыннан безнең хатын-кызлар дөньясында күңелле ыгы-зыгы башлана. Дулкынланып көтеп алган ул көн – гүзәл затларыбыз яратып өлгергән «Ел хатын-кызы. Ел ир-аты: хатын-кыз карашы» республика бәйгесе тантанасы. Җиңүчеләр тагын гаҗәпләндерә, тагын сокландыра! Хатын-кызларыбыз серле чәчәк кебек ачыла анда. Бу бәйге аша республикабызның йөзләгән-меңләгән хатын-кызы узды инде! Һәр ел яңа исемнәр, яңа язмышлар ача. Яшьләрнең дә теләп катнашуын күрү аеруча күңелле! Ә күпмесе эшче һөнәрләрне үз иткән! Татарстанда Эшче һөнәрләр елы игълан ителү, августта Казанда узачак WorldSkills Дөнья чемпионатына әзерлек безнең бәйгедә дә чагылыш тапты. Хатын-кызның җәмгыятьтә тоткан ролен күрсәтү өчен оештырылган бу бәйге елдан-ел камилләшә, аңа яңа сулыш өстәлә. Хатын-кызларыбыз барысын да булдыра: эштә зур казанышларга ирешәләр, гаилә җылысын саклыйлар, карьера баскычларыннан күтәреләләр… Заман үзгәрү белән алар да үзгәрә. Шундый ханымнарыбыз белән дөнья гел алга бара. Афәрин, кызлар! Чын хатын-кыз бәхете телибез сезгә!»















* * *

Шәмсия КЛУШЕВА («Хатын-кыз – ана» номинациясе, Зәй) чыгыш ясап бетергәч, янына балалары күтәрелде. Сәхнә тулды! Шулай булмыйча, үзенекеләр – дүртәү, тәрбиягә алганнары сигезәү ләбаса! Шулар янына инде кияү-киленнәрне, оныкларны да кушсаң… Һәммәсенең дә кулында чәчәк! Берьюлы бу кадәр чәчәк бәйләмен Шәмсия ханымның беркайчан алганы булмагандыр. Әни кеше күз яшьләрен тыймады…

– Бәхетле генә булсыннар… Шул миңа иң зур бүләк!

Микрофонга әйткән бу сүзләре, әлбәттә, алдан сценарийга язылмаган иде. Йөрәктән чыккан, ихлас сүзләр…

«Минем кер юуу машинам юк. Бөтен керне кул белән уам. Улларымның ак күлмәкләрен машина минем кебек агарта алмый», – дип шаккаттырды ул безне. Һәркайсыбыз бер минутка гына үзен аның урынына куеп карады бугай…

* * *

Луиза ПОДЬЯЧЕВА («Өченче буын героинясы», Әлмәт). Үзе әйтмәсә, мөгаен, яшен чамаламас та идек. Тәвәккәл икәне, яңалыктан курыкмавы тормыш юлына күз салуга ук күренә: «Әлмәтнефть» нефть һәм газ чыгару идарәсенә лаборант булып эшкә килә, аннан… «Нефтьче» күптиражлы газетасына күчә, аның мөхәррире (!) була. Инженер (!) булып эшли. Әлмәт өстәмә белем бирү колледжында укыта (!). Бүген ветераннар советын җитәкли. Әнә тагын яңа һөнәр өйрәнгән! 78 яшендә!

– Руль артына утырдым, – ди. – Юлда бик әкрен йөрим – миңа шулай җайлы. Төрле кеше бар: «Бераз шөрепләрең бушадымы әллә?» – дип тә күрсәтә кайсы. Исем дә китми – ашыгалар икән – узсыннар!

* * *

…Сәхнәдән төшүгә ул: «Тыңламыйлар бит, күлкегә калдым», – дип елап җибәрде. Тәрбиягә алган берсеннән-берсе кечкенә җиде баласы чыгышы вакытында сәхнәдә борчак урынына таралдылар. Хәер, батырлыгына таң калган тамашачы моңа артык игътибар да итмәде бугай. **Алсу ВӘЛИЕВА** («Хатын-кыз – ана» номинациясе, Лаеш районы) балаларын ялгызы үстерә! Иңгә-иң куеп яшәр чакта, ире көтмәгәндә вафат була. Сабыйларының бишесе авыру әле җитмәсә. Иң кечкенәсенә яшь тә дүрт ай… Бәйге нәтиҗәләре билгеле булганчы 5-6 яшьләрдәге дүрт баласы белән залда көтеп утырган бердәнбер гаилә дә булды бугай әле алар. Зал буйлап чабып йөрү, кычкырышу түгел, урыннарыннан да тормадылар балалар. Утырган җирдә тыныч кына уйнадылар да,

ДӨНЬЯНЫҢ...

алҗыгач, чиратлап әниләренең кочагында йоклап алдылар. Тыңламаган балалар өч сәгать буе әнә шулай тәртипле генә утыра алмыйдыр ул...

* * *

«Кияүгә чыгарга фатиха биргәнче, булачак иремне күрергә бабам мәктәпкә килде», – ди Әтнә районы Күлле Киме авылы мәктәбенең инглиз теле укытучысы **Ирина ХӘМИДУЛЛИНА** («Хатын-кыз: мәдәният һәм рухият» номинациясе). Килерсең дә: Мари илендә туып-үскән оныгың күрше республикага эшләргә китеп, татарга кияүгә чыгам дисен әле. Кияүне ошаталар. Яратмасалар, кызларына ислам динен кабул итәргә рөхсәт бирмәсләр иде, мөгаен. Ике якны тигез күреп яши Ирина: догасын да укый, туган телен дә саклый. Уллары, әнә, мари телендә ничек матур итеп шигырь сөйли!

* * *

«Кишер үскән, ә җыеп алырга хуҗабикә юк: концертлардан кайтып керми. Җырласын да, күңел көрлеге генә бетмәсен, әби белән бабай гына түгел, ире дә эшен ташлап кайтып, хәтта ихатадагы эт белән мәче дә ярдәм итәргә әзер». Балалар бакчасы тәрбиячесе **Алсу ШӘРӘФИЕВА** («Хатын-кыз: мәдәният һәм рухият» номинациясе, Әтнә районы) турында хезмәттәшләре әнә шундый скетч та куйды. Сәхнәдә ирең белән кара-каршы басып: «Күңел унҗидедә, йөрәк унсигездә, / Гомер үткәнлеге сизелми», – дип җырлау үзе бер зур бәхеттер ул...

* * *

5 бала, 15 онык, 12 оныкчык... «Өченче буын героинясы» номинациясенең җиңүчесе – Саба районы Кызыл Мишә авылында яшәүче **Зәләфрүз ГАТТАРОВА** бәйгегә оныкчыклары белән килгән. Борчуы гына бар: бабае авырып киткән. 64 ел бергә яшәгән Тәлгате бит ул!..

* * *

Зона бәйгесе үтәсе Балык Бистәсе мәдәният йортына барып кергәч, аптырап калдык: клубка килдек ләбаса, фермага түгел... Баскыч астында сыер басып тора, алдына кибәне белән печән куелган. Баксаң, Саба районы Сатыш хуҗалыгыннан бозау караучы **Язилә СӨНГАТУЛЛИНА** «Һөнәрем – минем тормышым» номинациясендә катнашырга әнә шундый әзерлек белән килгән икән. Сөтбикә чын булмады булуын, Язилә дә бозаулар арасында эшләмидер, сәхнәдә җырлап кына йөридер кебек тоелды. Менә шушындый талантлар булганда авыл яши әле.

* * *

Итальян телендә бер сүз белмәгән килеш Италиягә сыр ясарга өйрәнергә бару; ялгышып, бер порция сырны исраф итү һәм Кырымга барып укып-өйрәнеп кайту; салым системасын белмәгәнлектән әллә ничә штраф алу... «Миңлебай» сыр әзерләү хуҗалыгын оештырган **Чулпан МИҢНЕБАЕВА** («Хатын-кыз – эшмәкәр» номинациясе, Түбән Кама) ул чорларны хәзер көлә-көлә иткә ала.

– Чынлап торып сыр ясарга өйрәнәсе килү һәм гаиләмне, гомумән, халыкны сыйфатлы ризык белән сыйлысы килү теләгем зур иде, – ди ул.















Тынгысыз, тәвәккәл, туры сүзле... Ул шундый шагыйрәбез безнең. Тормышы, иҗаты милләт өчен янып көю, шатлану, борчылулардан торадыр кебек. Халык язмышы, тел, мәгариф мәсьәләләре буенча үткен сүзе, тирән чыгышлары, фәлсәфи шигырьләре берәүне дә битараф калдырмыйдыр... Әйе, бу – Нәҗибә Сафина.

Башка төрле Нәҗибә Сафина да бар әле. Балаларны маҗаралы әкият дөньясына алып кереп китә, ярату тулы шигырьләре белән җаннарны дәвалый, төртмә-шаян теле белән елмайта торган... Аның мәхәббәт шигырьләрендә йөрәк белән акыл – сөю сагында...

Бу көннәрдә юбилей язларын каршылаучы шагыйрәне гомер бәйрәме белән котлыйбыз! Иҗат уңышлары, сәламәтлек телибез!



Нәҗибә САФИНА

ЯЗМЫШЛАРНЫҢ ЯЗЫ – МӘХӘББӘТТӘ!

Аккош сагышы

Язлар очраштырды безне, –
Килдек Аккош күленә.
Аккош күле алып керде
Чын мәхәббәт иленә.

Син – аккош сагышым, дидең,
Уйламадым ул хакта.
Аккош сагышының серен
Белмәгәнмен ул чакта.

Мәхәббәтне ут, дидең дә,
Кердем шул утка гына.
Уттан алып суга салып,
Калдырдың юкка гына.

Аккош күлләренә киләм,
Аккошлар һаман парлы.
Сагышларны аңлатырлык
Телләрдә сүзләр бармы?

Кара аккош, кара аккош,
Җанымда минем ак кыш.
Җан – мәңгелек, син җанымда
Мәңге сүнмәслек балкыш.

Әллә нәрсә булды

Бүген миңа әллә нәрсә булды,
Синең хәлең ничек?
Мин утырдым шулкадәрле озак,
Ялгызым чәй эчеп...

Чәй табыны – болай, сәбәп кенә, –
Уй табыны инде.
Көтмәгәндә, җанга ташкын булып,
Чорлар шавы иңде.

Әйтерсең лә барлык заманнарда
Яшәгәнмен мин дә:
Шахталарга төштем, урак урдым,
Уйлар, утлар миндә...

Сабырлыклар һаман сакта тора,
Сына күрмә! – диеп.
Җанда – болыт, күз яшьләре дисәм,
Яңгыр ява коеп...

Көне буе күгә елап тора, –
Әллә нәрсә булган.
Минем генә түгел, бар галәмнең,
Ахры, күңеле тулган.

Бүген миңа, әллә күкләргәме
Әллә нәрсә булган? –
Ничәнче көн тоташ яңгыр ява, –
Минем күңел тулган.

Ни явалмый ачы күз яшьләре,
Ни болыты китми.
Көннәр генә түгел, еллар буе
Күз яшьләрем кипми.

Язмышыма әллә нәрсә булган.
Синең язмыш ничек?
Күзләремдә сиңа кайтып киләм,
Күпме язлар кичеп...

Язмышларның язы – мәхәббәттә!
Сөйгән җанда көз юк!
Бүген миңа әллә нәрсә булды, –
Аңлатырга сүз юк...

Нокта гына

Бүген синең йөрәк ни хәлләрдә?
Акылыңа буйсынамы? Юкмы?
Кайсы туктатмакчы: йөрәк? Акыл? –
Сөйләп йөрмә диеп һаман юкны!

Мәхәббәт юк, – анысы акыл сүзе, –
Өтердән соң фикер дәвам итә:
Кадерен белмәгәннәр язмышыннан
Башкаларны эзләп чыгып китә.

Мәхәббәт бар! –
монысы йөрәк сүзе. –
Өтерләр юк йөрәк тибешендә!
Типкән саен бары нокта гына,
Мәхәббәт юк йөрәк юкта гына.

Сүз көткәндә

Сүз генә көтәсең бары,
Шул сүз дә юк көткәндә.
Юатучы гына кирәк
Җанны сагыш өткәндә.

Сүз генә, бары сүз генә,
Моңлы, җылы тавышың
Туктатырга сәләтле бит
Җанга хәсрәт агышын.

Ә син суларга төшкәндәй
Бер хәбәрсез югалдың.
Мин сиңа ничә тапкырлар
СМС хат юлладым...

Яз көткәндә сары яфрак
Сагышы җанга ява...
Юкса бары бер җылы сүз
Көткән кешеңнән дәва...

Адаштым... гомер көземдер, –
Сукмаклары сап-сары...
Җанда – яз, ә чәчләремдә
Гомер кышымның кары...

Гомер буе сөйгәнемнән
Сүз генә көттем бары.

Аңлашу

Ник дәшмисең?
Мин көтәм бит
Синең эндәшүеңне.
Әле алай гына түгел,
Хәтта көнләшүеңне
Чәчләремне сыйпап искән
Ваемсыз җилләрдән дә.
Итәкләремне тарткалап,
Җилләр тик көлсәләр дә,
Күңел дигән могҗиза бар,
Буйсынмый бернигә дә.
Инде ап-ак карлар кунган
Синең-минем чигәгә...

Галәм кадәрле киң күңел,
Дәрья кадәрле тирән.
Мин сиңа җаның алмашка
Шулкадәр сөю бирәм.

Ник дәшмисең?
Мин көтәм бит –
Ярый көтәр кешем бар!
Минем җанда мәңгелек ут
Дип аталган хисем бар!

Дәшмә, янудан курыксаң
Мәхәббәт дигән утта!
Җансызларга кагылмый ул,
Син борчыласың юкка.

Бәхетсезнең бәхете

Уянам да сөенәм мин:
Ярый әле төшләр бар.
Төшләремдә син бит миңа
Бердәнбер кадерле яр.

Син төшләрдә минем янда,
Син мине иркәлисең.
Син бит мине бердәнберем,
Тиңдәшсез иркәм дисең.

Төшләр – мәхәббәт тәхете,
Бәхетсезнең бәхете...
Мәхәббәтсез өннәр, ахры,
Бу дөньяның ләхете...

Кара төннән көнгә кайтам,
Төшләрдән өннәремә.
Синле төшләр куа мине
Тик синсез өннәремә, –

Кояш балкый, кошлар сайрый,
Чәчәк тулы урман-кыр.
Әмма күңелдә яңгырый
Төштә син җырлаган җыр:

Алсаң иде өннәреңә,
Кояшлы көннәреңә...
Сөю сорап тилмерәсең
Кемнәрнең кемнәренә...

Ишектәге гөлләр...

Чәчәкләр... бер кочак чәчәк, –
Хат юк кош теле кадәр.
Гөл арасыннан эзләдем
Тик синнән җылы хәбәр.

Ашык-пошык, качып-посып
Язылган сөю хатын
Алырга да юкмыни соң,
Юкмыни минем хакым...

Чәчәкләр тамырларыннан
Өзелгән минем өчен.
Минем хакка өзелергә
Җитмәде синең көчең...

Бер кочак өзелгән гөлләр –
Мәхәббәт учагында.
Мин түгел, ул иркәләнә,
Ул – синең кочагыңда...

Комлы уй

Комнан аркан ишү диләр,
Ком – ишелгән бәхет ул.
Бәхетен тапмаганнарга
Җирдәге өй – ләхет ул.

Гомер гасырлап саналмый,
Еллар... айлар, көннәрме?
Сәгать түгел, мизгелләре
Алып китми кемнәрне...

Бәхетнең гомере – мизгел!
Шуны кеше аңламый.
Мизгел түгел, сәгатьләрне
Бәхетлеләр санламый.

Санламаганга үч итә,
Вакыт шундый мәкерле!
Кабатланмый, әмма ләкин
Шулкадәр дә хәтерле!

Кадерсез үткән мизгелләр
Җиргә ком булып ята.
Ишләрен тапмаган хисләр,
Ахры, таш булып ката?!

Таулар иңә, комнар күчә, –
Кемнәрнең бәхетләре?
Таштан кисеп төзиләр шул
Һаман да тәхетләрне...

Күңел фасыллары

Дөньяның сары сагышка
баткан мәлләре – көзме?
Бәгырьләргә ачы итеп
кадалганнары – сүзме?

Кайсылары ачырактыр,
көзге җилме, сүзләрме?
Авыр, авырдан да авыр –
мөлдерәмә күзләре.

Дөньяның моңнарга баткан
бар әле язгы мәле.
Каеннардан шуып төшкән
кыш ябындырган шәле.

Көзнең сагышлары ачы,
моңнары тирән язның.
Авыр, авырдан да авыр
тавышы ялгыз казның.

Дөньяның моңга-сагышка
баткан мәлләре авыр.
Ул – кеше гомерләрендә
назларсыз үткән дәва..





Ралия КӘРИМОВА

КӨТЕП АЛГАН БӘХЕТ

(Хикәя)

Әллә күзенә күренәме, сискәнеп китте Гөлгенә. Гамилне күргәч, ни уйларга да белмәде, чөнки бу очрашу көтмәгәндә, кинәт булды. Унсигез еллап гомер үтсә дә, шундук таныды аны: шул ук озын буй, киң җилкә, серле караш, тик куе кара чәчләренең чигә тирәләренә ак бәс яткан. Күзләрендә ниндидер сагышмы, назмы... Теге вакытта – ерак үткәннәрдәге иртәнге тынлыкта шашынып сөю турындагы шигырьләрен укыгандагы дәрт сүнгән иде инде ул зәңгәр күзләрдә. Метро вагонында урыннары капма-каршы туры килде аларның. Бер-берсенә текәлеп, карашлары очрашуга, Гөлгенәнең гәүдәсеннән ток үткәндәй булды. Ир дә аны таныды, нидер әйтергә теләп урыныннан калкынгандай итте. Тик тукталышта кереп тулган кешеләр арага басты. Электричка «Тукай мәйданы» станциясенә килеп туктауга, хатын тиз генә вагоннан чыкты да, ашыгып «Кольцо» сәүдә үзәгенә таба китте. Халык төркеме арасыннан Гамилнең дә артыннан чыгуын, куып җитәргә теләп, ашыгып атлавын күрде, тик адымнарын кызулатты. Аңа ялгыз калып уйланырга кирәк иде, чөнки үткән еллар хатирәсе тагын күңелен биләп алды...

Кышкы урман аланлыгындагы зур гына йорт тәрәзәләрендәге ут шәүләсен күреп шатланды Гамил. Ул куе урман ешлыгында адашып йөреп бик арыган иде. Нишләп бабасын тыңламады, ялгызы йөреп кайтырга, очраса, куян атарга уйлап, тыюлыктан биш-алты чакрымлап читкәрәк ауга чыккан иде егет. Казанда яшәсә дә, кечкенәдән җәйләре Башкортстанның төньягындагы авылда, әби-бабасы янында үткәнгә, авыл эшен белеп үсте Гамил. Менә хәзер дә картларның күңелен күрәсе килде, нидер эшләде, какты, сүтте, җыйды. Берничә көн эчендә урам як киртәләрне ныгытты, утын ярды. Әти-әнисе еш кайта алмый, ә хуҗалыкта ирләр кулы кирәк... Бигрәк тә авырып яткан бабасы шатланды, хәтта торып утырды. Сөйләшергә иптәш булгач, кызыксынып, бер ай элек кайткан оныгының ничек

хезмәт итүен, кайларда булуын озаклап сораштырды. Яраган кадәресен генә сөйләп, бабасының сорауларына җавап бирде Гамил. Тик Чечняда булган мәхшәр хакында авыз ачып бер сүз әйтмәде, чик буен саклавы турындагы уйдырмасын кызыклы вакыйгалар белән баетты. Грозный шәһәрендә тимер юл вокзалын алу өчен яңа ел төнендәге дәһшәтле сугыштан исән калган санаулы солдатларның берсе ул иде. Майкоп бригадасы... Болар искә төшкәндә дә чәчләр үрә торырлык... Нык коралланган Дудаевчыларга каршы әзерлексез кертелгән яшел томшыклар – яшь солдатлар иде алар ул вакытта. БМП машиналарын дошман шартлатып юк итте. Батальон штабы начальнигы майор Чмырев һәлак булгач, алар тәүлек буена чолганышта булдылар. Истән чыкмаса да, тизрәк хәтердән җуярга тырышырга кирәк боларны... Шагыйрь әйтмешли, «Үлем турында уйлама, илең турында уйла»... Әби-бабасы янында тагын бер атна торуга, ирек таләп иткән җаны авыл өенә генә сыя алмыйча, киң болыннарга, куе урманнарга омтылды. Бер көнне җыенып ауга китте Гамил, бала чагында бабасы белән йөргән урман аланындагы энҗедәй ак кар патшалыгын ялгызы гизде. Күзләр камашырлык сафлык! Саран гына күренеп алган кояш нурларында җемелдәгән ап-ак кар өстеннән, кызыксынып, төлке, куян эзләрен карады, карт миләш тирәсендә чуарланып беткән кош эзләрен күздән үткәрде. Кар өсте – ул ачык китап бите кебек, ди бабасы. Киң чаңгы эзләре буйлап эчкәрәк керде ул. Урманда шундый тын, рәхәт. Аксыл чуар нәфис каеннар, кытыршы кайрылы юан наратлар, кап-кара кәүсәле юкә агачлары, шомыртлар, эреле-ваклы яшел чыршылар ак кар бүрекләрен киеп, горур гына басып торалар. Менә моннан озын колак чабып үткән! Ә биредә яшәү өчен көрәш булган кебек, эзләр чуалган... Әллә бүре эзләре инде?

Шулай бара торгач, байтак юл үтелде, көн кичкә авышты. Урман эче караңгыланып киткәндәй булгач, Гамил кайтыр юлга борылды. Озак барганнан соң, кире якка киткәнлеген сизде ул. Урман эченнән чыгар юлын югалтып шактый йөрде. Төн дә җитеп килә, кайсы якка барырга? Урманда төн үткәрер микәнни? Арып, агач төбенә чүгәләде егет. Бераздан бик еракта эт өргән тавыш, ниндидер гөрелте тавышы ишетелгәндәй булды. Гамил ай яктысында тавыш килгән якка юнәлде. Юл юк, аркылы ауган агачларга абынмаска, чаңгыларны сындырмыйча сакларга иде. Шактый ара үтеп, урман авызына чыккач, еракта ут шәүләсе күренгән йортка таба китте. Койма буенда ярсып өргән эт тавышыннан туктап калды. Менә йорт эченнән чыккан хатын-кыз тавышы ишетелде:

– Кем бар анда? Кем йөри инде төн уртасында?

– Мин Ирәкте авылыннан, Сәхәү бабай оныгы.

– Акбай, на место! – диде ачулы тавыш. – Кемгә әйтәм!.. Әйдә, кер!

Капка келәсе шалтырап ачылды. Егет тынычлана төшкән Акбай яныннан ишегалдына үтте.

– Адашып йөрдем, – диде ул кыенсынып. Яп-якты буш өй эченә кергәч, Гамил ишек төбендә туктап калды. Артындагы кызга кызыксынып карап алуга, тегесе:

– Сәхәү бабайның оныгы, димәк... Аны беләбез. Ярый, иртән юлны күрсәтермен. Мин өстәл әзерләгәнче, бар, мунчада юынып чык, суы җылыдыр әле, – дип, тир исе килеп торган егеткә сөлге сузды.

Гамил эссе мунчада рәхәтләнеп чабынды, юынды, киенгәндә инде аруы бетеп киткәндәй булды. Өйдә өстәл өстендә итле бәрәңге, тозлы кыяр, бер тәлинкә җирән гөмбә һәм кечкенә графин тора иде. Хуҗабикә өстәлгә кашык куйды да Гамилгә эндәште:

– Нәрсә, мунчаның җылысы бетмәгәнме? Сәхәү бабай нихәлдә соң, чирләп ята дигәннәр ие?

Бабасының хәле яхшыра башлавын әйтеп, йорт эченә күз салды, кызга рәхмәт әйтеп, сөлгесен куйды да өстәл янына килеп утырды ул. Бу өйдә бер дә ир-ат заты булганга охшамаган...

– Әйдә, танышыйк, мин Гамил булам. Ә син кем?

Үзе яшьләрендәге бу чибәр кызның кара куе чәчләре иңбашына төшкән, кофтасы төсендәге сорыяшькелт күзләре кыю карый, бит очлары алсуланып тора. Сөйкемле, чибәр күренә!

– Минем исемем Гөлгенә. Әйдә, җитеш, аша, аруың бетәр, – диде ул табынга ишарәләп. Егет бәрәңге алып капты, графиннан кечкенә стаканга салып, эчеп куйды. Көмешкәсе куәтле икән. Бераз ашап алгач, батырая төшкән егет Гөлгенәгә борылды:

– Чәчәк кенә, гөл генә, шигырь сөйлим, тыңлыйсыңмы? – диде Гамил елмаеп һәм кайчандыр беренче мәхәббәтенә багышлап язган шигырен сөйли дә башлады. Шигырьләре байтак иде аның, алар искә төшеп кенә торды. Гөлгенә егетне бирелеп тыңлый, гүя бу тавыш якты өметләргә, тормышка ашмастай хыялларга канат куя. Гамилнең бу кадәр игътибарлы тыңлаучыны очратканы юк иде әле. Ул тагын бер чәркәне күтәреп куйды да дәртләнеп укуын дәвам итте. Сәгать төнге өченчене күрсәтсә дә, кыз урыныннан торып китмәде, тыныч кына тыңлап утыруында булды. Тыштан гына тыныч күренде Гөлгенә, аның җанында гүя учак кабынды, ялкыннары күккә үрли иде. «Нинди сөйкемле караш! – дип уйлады егет. – Күзләрендә очкын кабынган сыман. Басынкы, тыйнак, ялгыз... Башка кызлар муенына сарылырга гына тора, ә бу, егеткә һич исе китмәгәндәй, тик тыңлап утыра...» Гамил урыныннан торып, дәртләнеп сөйли-сөйли, Гөлгенәгә якынлашты:

Бүген көнем синсез – тәссез иде,
Төнем якты итте тулган ай...
Сөю агыла сыман күзләреңнән,
Йөрәк яна, нигә бу шулай?..

Хисләренә исергәндәй, ул арттан килеп кызны кочаклап алды да җилкәсеннән үбә үк башлады. Тегесе пышылдап кына кирәкми дип, аны этеп җибәрмәкче булды, тик бу кызган егетне ярсытты гына. Ул кызга сүз әйтергә ирек бирмәде, аның уймактай иреннәренә үрелде. Өстендәге кофтасын салдырды, алар кырыйдагы диванга якынлаштылар. Гөлгенә,



карышып, аны бар көченә этте, тик Гамил кызны ашыгып, шашып үпте, иркәләп назлады. Гөлгенә тыпырчынды, торырга теләде, тик кычкырмады, тавыш чыгармады. Бераздан каршылыгы кимеде, аннары тәмам тынды, ул үзе дә егеткә җавап биргәндәй, дугадай бөгелеп, ыңгырашу авазы чыгарды...

Тиз генә диваннан торып, башын иеп чыгып киткән Гөлгенәнең һаман кермәвенә аптыраган егет ни уйларга да белмәде. Көмешкәсен эчмәскә булган, канны шул кыздырды. Ялгышты бугай, болай ярамас иде... Нишләргә соң инде? Егет диван кырыендагы тастымал белән тирләгән муенын, битләрен сөртте, әрле-бирле йөренде. Эчәргә су эзләп як-ягына каранды да ябык пыяла ишекне ачып, зур бүлмәгә күз салды. Ярым караңгы бүлмәдәге караватта яткан кеше гәүдәсен күреп, сискәнеп китте. Билдән ак япма астында ятса да, тәрәзәдән төшкән тулган ай яктысында кечкенә гәүдәсе күренеп тора. Ах, кем икән бу?.. Якынрак килде Гамил, ә гәүдәнең кулбаштан ике кулы, бот төбеннән ике аягы юк иде... Йә Хода... Ул бит барысын да ишетеп яткандыр... Гамилнең аркасына салкын тир бәреп чыкты, ул уңайсызланып, ирексездән бүлмә эченә керде. Гарип егетнең күмер кебек күзләрендә яшь тамчысы ялтырады. Янына якын ук килеп баскач, Гамил кинәт кычкырып ук:

– Взводный! Бу синме? Син исәнмени?.. – дип чайкалып китте, караваt янына килеп тезләнде. Әйе... хезмәт срогын башлап, чечен сугышына килеп эләккәч, аларның взвод командиры булган татар егете Марс Камалов иде бу! Гамилнең кыенсынудан, оялудан йөзенә генә түгел, колакларына да ут капты... Соңгы сугышта аларны – яшь солдатларны үлемнән саклап, взвод командиры дошман ыргыткан граната өстенә ауган иде... Теткәләнеп беткән, нык яраланган кан эчендәге батырны – рядовой егетләрдән өч-дүрт яшькә генә өлкәнрәк командирны көч-хәл белән госпитальгә озатырга өлгергәннәр иде алар... Ампутациядән соң аңына килә алмаган диделәр, аның үлеме турында хәбәр килгән иде... Взводный авыр яраланса да, исән калган икән бит! Гамил аны ерак Башкортстанда, тын урман буендагы каравылчы йортында шушы хәлдә күреп тәмам аптырады, бермәлгә аңгыраеп китте. Мөлдерәмә тулы күңел савытын кысып тоткандай, бер үк утта канатлары көйгән ике күбәләк сыман, бер мизгелгә алар тын калдылар.

– Тәмәке! Тәмәке бир! Син?..

Тулган ай яктысында ул да егетне танып алды. Гамил юл капчыгыннан калтыранган куллары белән тәмәке алып кабызды да Марска каптырды. Бер-ике суыруга, ул күңелендәге каршылыклы хисләрдән тынычлана төшкәндәй, сүз башлады.

– Әйе, – диде ул, – бәхетсезлеккә каршы, мин исән калдым, мине яңадан сүтеп җыйдылар... Тик тормышка ярар җирем юк инде. Балабыз да булмый калды ичмасам. Аңлыйм, Гөлгенәгә бик авыр. Бәлки авырга узар... Безнең өчен тормышның сынаулары бетмәгән икән әле... Син хәзер үк кит, монда бүтән күренеп йөрмә! Авыздан тәмәкене ал! Таң беленә башлады, урман буйлап бар да, уңга таба борыл, юлны күрерсең...

– Командир, кичер мине булдыра алсаң... Гафу ит, братан!

Гамил, капчыгын эләктереп, башын иеп торды да тиз генә өйдән чыгып китте.

Төнге күк йөзеннән җиһан куенында уйнап очкан ак күбәләкләр сыман кар бөртекләре бөтерелеп җиргә төшә. Гамилнең башында каршылыклы уйлар өермәсе... Кайткач, шуны белде: элек бабасы белән бергә урман каравылчысы булып эшләгән Зиннәт хастаханәдә ята икән. Өйләнеп, армиягә киткән бердәнбер улы, Чечнядә авыр яраланып, ел буена госпитальдә яткан. Соңрак аны өенә аяк-кулсыз кайтарып салганнар. Улы кайгысыннан хатыны үткән ел ук дөнья куйган...

Гамил озак уйланып йөрде: менә нинди авыр язмышка дучар булган бу яшь пар... Бәхетле булып яшәр урында... Их, Гөлгенә! Кем соң сине җил-давылдан саклар? Кавказ таулары буенда никадәр язмышлар җимерелде, күпме гомерләр өзелде... Каһәр суккан сугыш, кирәкмәгән, чит сугыш!

Гамил авыр тойгылар белән поездда Казанга кайтып китте. Тормышының һәр мизгелен язмыш бизмәненә салып үлчәр өчен алда байтак еллар, билгесез озын юллар көтә икән кешене.

* * *

Фатирына кайтып керүгә, Гөлгенә тиз генә аш куйды, йомырка сытып коймак камыры әзерләде. Тик күз алдында Гамил, аның серле карашы, олпат гәүдәсе, назлы елмаюы тора иде. Ничә еллар буена хәтереннән чыкмаган оятлы да, татлы да, газаплы да сагышы иде ул аның! Әйе, бар тормышы кабат кинофильмдагы кебек Гөлгенәнең хәтер иләге аша үтте...

Ире каршында гаеплелек тойгысыннан газаплануын ана булу шатлыгы җиңеп, ул бераз тынычланган иде инде. Хатын-кызның җирдәге бурычы – бала табу, нәсел калдыру бит. Ире дә аны аңлады. Бала тугач шатланды, сөенде, күзләрендәге җан әрнүен, сызлавын күрсәтмәскә тырышты. Ә кайнатасы бәбигә агач караваt ясап куйды, сиртмәле арба алып кайтты, баланы нишләтергә белмәде. Тик кадерлесе – Марсы балага 3 яшь тулганчы гына яшәде. Беренче чечен сугышында ук алган төзәлмәс яралары белән озак интекте ул. Гөлгенә аны бала урынына карады, хәлен ничек тә җиңеләйтергә тырышты. Дәвалау өчен Кытайда укып кайткан доктор тапты. Тик болар аның гомерен беразга гына озайтты. Военкоматтан ярдәм өмет итеп йөреп караган иде дә, пенсия акчасыннан башка әллә ни ярдәм булмады. Ире үлгәннән соң, баласын алып китәргә җыенгач, кайнатасын кызганудан тагын биш елга тоткарланды хатын... Күрше авылда бухгалтер булып эшләде. Катлаулы, болганчык, авыр ике меңенче ел иде. Югарыга үрмәләгән оятсызлар аркасында үзен гаепләп, утыртып куя яздылар үзен. Дөреслек өчен көрәште, дәлилләде, акланды. Ялгыз хатынның көчле булмый



Рәсем: Наталья Васильева

чарасы юк. Тормыш аңа бернинди дә ташламалар ясамый шул. Акыллы Зиннәт абзый килененә киңәшләре белән ярдәм итте. Аннары: «Бу яшьтән шулай ялгыз яшәмәссең, кызым. Тормышыңны җайларга уйласаң, бер сүзем юк. Кияүгә чыгарга кирәк сиңа. Баланы үзем карашырмын, ярдәмемнән ташламам. Улыма шулай дип сүз бирдем бит, аның бердәнбер баласы ич ул», – диде. Ах, белсә иде әтисе!.. Сабырлык, зирәклек сирпелгән күзләрендә, тәҗрибә туплаган күңелендә бары яхшылык кына чагыла аның. Ә Гөлгенә башканы ярата алырына ышанмады. Кайнатасы, җыйган акчасын биреп, Казаннан фатир алырга булышты. Үзе урманын, кадерле кешеләренең каберләрен калдырып китә алмады. Гөлгенә Татарстанда, башкалада яши башлады. Гамилнең дә Казаннан икәнлеген белә иде ул. Ә кызы – Зифасы тәртипле булып үсте. Әтисе кебек шигырьләр белән мавыга, алар басылып тора, мәктәпне алтын медальгә тәмамлады. Финанс-икътисад институтының беренче курсында гына укыса да, тизрәк һөнәр алырга, эшләргә омтыла. Курсларга йөреп, инглиз телен үзләштерә. Әнә, кайтып та җитте үзе. Әнисен күргәч, күзләрне чагылдырып торган кояштай карашы тоныкланып киткәндәй булды:

– Әни, нәрсә булды, төсең киткән димме...

Зифа, борчылып, әнисенең сагыш-моң тулы күзләренә карады. Гөлгенә, елмаеп, кызын тынычландырды.

Берничә көн үткәч, Бауман урамы чатында алар Гамил белән кабат очраштылар.

– Гөлгенә, бу синме соң? Исәнме! Мин сине күптәннән эзлим бит инде. Ә син һаман да элеккечә чибәр, һич кенә дә үзгәрмәгәнсең! – дип кулларына үрелде ул.

– Исәнме, Гамил! Менә ничә еллар үткәч очраштык...

– Тормышлар ничек, Гөлгенә кадерлем? Мин сезнең Казанга күченеп килгәнегезне ишеткән идем. Очрашу турында хыялланып, өметемне өзми яшәдем. Мине гафу итәрме икән дип уйладым... Онытa алмадым мин сине, Гөлгенә, өйләнә дә алмадым. Аптырагач, Себергә киттем, ун ел анда эшләп карадым. Күңел борчуларына җавап тапмыйча, тагын Казанга кайттым.

Аның куе керфекләре астына яшерелгән күзләрендә сөю чаткылары өмет нуры чәчә иде. Алып гәүдәле чибәр бу ирнең күзләрен тутырып карап торуыннан ук, әйтерсең лә җанга җылы агылды, аның кайнар хисләреннән салкын көн кояшлы, нурлы булып тоелды. Шигъри күңеле белән кайчандыр җанын әсир иткән егет кенә түгел, ничә еллар буе көтеп алган бәхете иде ул аның! Бүтән беркая да җибәрмим мин сине, дигәндәй, Гамил Гөлгенәне кочаклап ук алды...

Кадерле «Сөембикә» редакциясе!

Белмим, әллә тамырларым белән авылга тоташканга, инде шактый еллар шәһәрдә яшәсәм дә, җае чыккан саен туган якларыма кайтмый калганым юк. Авылдан тәннәремә генә түгел, җаннарыма да сихәт алып киләм.

Әле менә тагын әнием янына авылга кузгалдык. Машина радиоалгычыннан Вадим Захаров җыр суза: «Көттермәсәк иде әнкәйләрне, сызламасын иде җаннары...» Ирексездән күзне яшьләр томалый. Машинадан да тизрәк йөгереп, әнкәй янына кайтып сыенасы килә. Безнең кайтуны дүрт күз белән көтә ич ул. Башта тәрәзәдән тәрәзәгә йөри, аннары, түзә алмыйча, өстенә дә кияргә онытып, капка төбенә үк чыгып баса. Әниемнең кайгыртучанлыгы хәтта йорт хайваннарына да күчкән. Ишегалдында сакта торучы эте Миңнебим (!) да, иркә песие Асылъяр да безне көтеп ала. Чөнки без аларга да күчтәнәчләр алып кайтырга онытмыйбыз. Хайваннар бит җылы мөнәсәбәтне кешедән дә ныграк аңлыйлар.

Әниемнең бисмилла белән пешкән тәмле бәлешләре, ашлары белән сыйланып, каен себеркеләре белән парлана-чабына мунчалар кереп, атна буена җитәрлек көч-дәрт туплап, кабат шәһәргә юл тотабыз. Әни исә күз яшьләрен күрсәтмәскә тырышып, тыкрыктан борылганчы кулын изәп озатып кала. Кайтыр кешең барда кайткала, дип белми әйтмиләр шул. Әле дә ярый кайтыр нигезебез бар, әнкәйнең җылы өенең тәрәзләрендә нурлар балкый, үзе исән-сау дип, Ходаема шөкрана итәм.

Әти-әниләре исән булып та, яннарына сирәк кайтучы туң йөрәкле бәндәләрне бөтенләй аңлый алмыйм. Өзелергә торган көзге яфрак хәлендә бит өлкәннәрнең күңел халәте. Исән чакларында аларны кадерләргә, хөрмәтләргә җитешә алсак, яннарына кайтып йөрсәк, тирән газапларга салып көттермәсәк иде әткәй-әнкәйләрне!

Гөлчәчәк САДРЕТДИНОВА-ХАҖИЕВА. Азнакай шәһәре.



Кунаклар гына килгәндә куллана торган бик матур бер сервизым бар минем. 25 ел элек «Сөембикә» журналы бүләк иткән кадерле ядкарем ул.

90 нчы ел урталарында «Минем кайнанам мировой» бәйгесенә килгән ике меңнән артык язма арасыннан «Алтын йозак» дигән язмамны сайлап алып, мине дә җиңүче ясаган идегез. Сезгә язарга тагын бер форсат чыкты бит әле.

Язмам герое – Миннесәүдә Гыйльмулла кызы Әхмәдуллина Бондюгта туып-үсә. Алабуга мәдәни-агарту техникумын тәмамлаган кызны 1956 елда безнең авылга, моңарчы колагы да ишетмәгән Борнашка эшкә җибәрәләр. Әйтергә генә ансат, республиканың көнчыгышыннан көнбатышына барып җитү ул елларда үтеп чыга алмаслык карурман булган шул.

Килеп төшүгә, колхоз рәисе аның кулына клуб ачкычларын тоттыра. Авылда китапханә юк икән. Миннесәүдә югалып калмый, 1878 елда салынган клубта һәм күршедәге мәдрәсә бинасына урнашкан избачта мөдир булып эшли дә башлый. Ул хәзер шулай, елмаеп-көлеп, эшләп киттем дисә дә, аңынчы монда әллә ничә кеше килеп, эшнең авырлыгына түзә алмыйча китеп барган була. Ә ул теше-тырнагы белән ябыша. Әле алай гынамы, яңа клуб салыр өчен акча кирәк дип, гомерендә бер тапкыр да барып күрмәгән Казанга чыгып китә! Авылдашы Мәрзияттәйнең сеңлесе Хәдичә апаның ире Сәет абый депутатлыкка сайланган икән. Әнисе шулай дип хатка язган. Телефон заманы түгел, хат аша

адресын белешә дә, бер белмәгән шәһәргә кузгала. Үзе курка, ишекне ачмасалар, кая барыр? Алай да ул чор кешесе миһербанлы: ишекне ачалар, чәйләр эчереп, кундырып та чыгаралар. Депутатны Борнашка халык белән очрашуга чакыра. Әнә шулай итеп, тәки теләгенә ирешә ул: 1958 елда авылда яңа клуб ачыла. Авыл яшьләре белән урманнан алып кайтып, клуб бакчасына ике меңгә якын агач утырталар. Клуб эчендә китапханәгә дә урын табыла.

Безнең клубта хәтта Әлфия Афзалова да концерт куя. Ул концертны Миңнесәүдә апа үзе алып бара.

Уйлыйм да, исем китә, юлсызлык та, утсызлык та куркытмаган бу бәләкәй генә буйлы, шомырт күзле Бондюг кызын! Бәхетен дә шушында – Борнашта тапкан ул. Ленин исемендәге колхозның агрономы Камил Әхмәдуллин белән кавышып, менә инде 57 ел бер сукмактан атлыйлар. Борнашны ярата Миңнесәүдә апа. Туган җирләрен дә бик сагына ул. Бигрәк тә яз айларында, табигать уянганда күңеле үрсәләнә. Берсендә фатир хуҗасы Саймә апага үз өйләре каршындагы шомыртларын сагынуын әйтә дә үксеп елап та җибәрә. Борнаш урмансыз як шул. Авылга беренче килгән вакытларында кызны гаҗәпләндергәне дә шул була: «Алмагач, чия дип әйтмим дә инде, ник соң шомырт белән миләш булса да үсми?» – ди ул. Саймә апасы өзгәләнгән кызга карап, ни әйтергә дә белми. «Әнә Йолдызда (Югары Ослан районы) бар да инде ул шомырт, анда кадәр ерак шул, 20 чакрымлап булыр», – ди. Кызга шул җитә кала, кичен авыл яшьләрен үгетләп, китәләр болар урман эчендәге Йолдызны эзләп. Анда Саймә апасының туганы Һадия апа яши икән. Ул аларны үз туганнарыдай каршы ала, кич кунып калырга үгетли. Кая ул куну, куеннарына шомырт чәчәкләрен кочып, кире кайтып китәләр. Һадия апаның аларны ак оннан коймак пешереп көтеп торганын (1958 ел бу, ак онны каян тапты икән?!) әле бүген дә тыныч кына сөйли алмый Миннесәүдә апа. Бүген ул Апасыбызның гына түгел, бөтен тирә-як авылларның да абруйлы кешесе. Узган гасырның 60 нчы елларында авыл советы рәисе булып эшләгәндә тирә-юньне агачларга күмде ул. Мәктәп укучылары, яшьләр белән бергәләп меңәр төп агач утырттылар. Бакчагызга утыртыгыз әле дип, авылдашларга чәчәк үсентеләре, гөл орлыклары да өләшә иде.

(Фотода: Миннесәүдә апа авыл яшьләре белән. Сулдан – өченче, беләгенә сәгать такканы.)

Зәйнәп ЯРУЛЛИНА.
Апас районы.

Мөслимнең «Туган як» музеennан халык бер дә өзелми. Яшьләр үзләренә таныш булмаган үткән гасырлар мохитенә чумса, өлкәннәр монда балачак хатирәләрен яңарта.

Музейда карарлык та, танышырлык та әйберләр күп. Әле менә «Картлар сүзен кар басмас» дип исемләнгән проект эшләп килә. Өлкәннәр үзләренең истәлекләре белән уртаклаша, кул эшләреннән күргәзмәләр оештыра... Мөслим районы Мәлләтамак авылында туып, хәзер Актүбә төбәгендә яшәүче Земфира Нуретдинова-Шәмсуллинаның әбисе турындагы истәлекләрен сезгә дә тәкъдим итмәкче булабыз.

«Әбием Гыйльмисафа Миңкулова 1906 елгы иде, – дип сөйли Земфира ханым. – Гомере буе Мәлләтамак авылында яшәде. Салам түбәле иске генә өенең тәрәзә төбе тулы яран, кына, исле гөлләр иде. Әбинең керосин лампалары, мичеңә салам якканнары әле дә күз алдымда. Саламның җылысы янган вакытта гына, янып бетте исә, бер җылысы да калмый. Әби үзе кул эшенә бик оста: тегә дә, бәйли дә, паласлар, ашъяулыклар, җәймәләр дә суга иде. Мин үзем 1961 елгы, аның бу эшләренең шаһиты булып үстем.

Ир-атка бик хөрмәтле булды әби. Берсендә көянтә-чиләген күтәреп капкадан чыкты да, тиз генә кире кереп, капканы япты. Аптырап торуымны күреп: «Буш чиләк белән каршысына чыгу ир-атны хөрмәт итмәү була», – дигән иде. Урамда берәр ир-ат очрап: «Гыйльмисафаттәй, хәлең ничек?» – дисә, авызын яулык очы белән каплап кына җавап бирә иде ул.

Яңа йорт җиткереп кергәч, әбинең ничек шатланганын белсәгез! Идәненә кадәр берәүдән дә юдырмыйча, үзе генә юа иде. Аның чиста, пөхтә өе әле дә күз алдымда тора: тәрәзәләрендә ап-ак челтәр пәрдәләр, стенада чигүле гөлләр... Кич утырырга күрше апалары: Мәсүфәттәй, Галияттәй, Рабигаттәй, Зәйтүнә апа, Зәйнәп апа, Фәния апа, Шәмсенур әби, Нурзидә апалар керә. Китап укыйлар, яңалыклар сөйләшәләр, самавырдан чәй эчәләр.

Әбием бер ихатага салынган ике йортта килендәше белән күрше булып яшәде. Безнең Хәбибулла бабай 1940 елда үлгән, ә Шәйхрам бабай сугышта һәлак булган. Ике килендәш гомер буе бер-берсенә ярдәмчел, бик тату булдылар. Олыгайгач, килендәше саңгырауланды, ләкин әбинең әйткәнен аңлый иде.

Яшьлеген еш искә төшерә иде әби. «Кияргә бер генә күлмәк, урак урып кайткач, шуны ук юып, кичке уенга киеп чыга идек...» Бәләк белән су буенда кер уганнарын, кышын бәкедә чайкаганнарын, тула оек басканнарын, селте суы белән чәч юганнарын, кер агартканнарын сөйли дә көрсенә. «Яшь баланы арбага салып, урак урырга барабыз. Бала шул арбасында килеш басу башында йоклап кала. Урак урып, басуның икенче башыннан әйләнеп килгәнче ул инде елап арыган, кабат йоклап киткән була... Үзен чебен баскан булыр иде тагын», – дип сөйли иде. Әбиемнең әйткән сүзләрен гомер буе йөрәгемдә сакладым. «Сабыр бул, кызым, сабыр төбе – сары алтын», – ди иде ул.

Мин үзем нәселебезнең шундый сокланып туймаслык кешеләре булуга горурланып яшим. Мең рәхмәт аларга, рухлары, җаннары шат булсын!»

Йолдыз ЗӘКИЕВА.
Мөслим районы «Туган як музее» экспонатларын саклаучы.

Хөрмәтле укучыларыбыз! Сездән хатлар көтеп калабыз. Безнең адрес: Казан, Декабристлар урамы, 2. e-mail: ssuum@yandex.ru



«БЕЗ АЕРЫЛЫШМАС ИДЕК...»

Вакыт барысын да оныттыра: үпкәләрне, көтү-сагынуларны, хәтер калуларны... Ул барысын да үз урынына куя. Шуңа да, еллар түреннән артка борылып карагач, кемнең сиңа кем булганлыгын ныграк аңлыйсың... Берсе – күренекле балалар язучысы, «Кирлемән», «Курай-малай маҗаралары», «Актәпи ник моңая» кебек искиткеч матур әкиятләр авторы Роза Хафизова, икенчесе – медицина фәннәре кандидаты, Татарстанның атказанган медицина хезмәткәре – Руфина Фәттахова. Алар кайчандыр икесе дә бер үк кешегә – Татарстанның халык язучысы, Габдулла Тукай бүләге иясе Нурихан Фәттахка гашыйк булалар. Хәер, ул чакта әле гап-гади Нуриханга... Бу ике күркәм ханымныниләр берләштерә, ә нәрсәләр аера, алар бер-берсенә кем? Әңгәмәдәшем – Руфина ханым ФӘТТАХОВА. Ачыктан-ачык сөйләшәбез.



Нурихан белән өйләнешкәндә, мин, билгеле, аның моңарчы өйләнгән булуын, хатыны, баласы барлыгын белә идем. Алар бергә бик аз торганнар. Без танышканда, аерылышуларына биш-алты ел гомер узган, Нурихан күптән ялгыз ир иде. Шулай булгач, Роза ханыма мин берничек тә көндәш булмадым: араларына кермәдем, аермадым...

Алар I курстан башлап бергә укыганнар. Группалары бик данлыклы: Гарәф Шәрәфетдинов, Зәет Мәҗитов, Рафак Тимергалин... Күп группадашлары инде бакыйлыкка күчте. Исәннәрдән мин белгәне – академик Мирфатыйх Зәкиев калды. Сүз уңаеннан, Мирфатыйх белән Роза ханым икесе бер яктан – Бөгелмәдән. Сөйләүләренә һәм хатларына караганда, Нурихан белән Роза II курска күчкәч дуслашып китәләр. Яратыша башлыйлар... Бер үк елны диплом алалар. V курсны тәмамлагач, бер-берсен югалтмау өчендер, ЗАГСка барып языла шалар, ләкин әле ир белән хатын мөнәсәбәтләренә кермиләр. Розаны юллама белән эшкә Себергә, Тобольск шәһәренә укытучы итеп җибәрәләр. Нурихан Чистайга «Сталин байрагы» дигән газетага тәрҗемәче булып эшкә урнаша. Язылышуларын алар берәүгә дә белгертмәгәннәр. Бәлки сынау үтәселәре, мәхәббәтләренең ныклыгын сынныйсылары килгәндер, белмим. Әмма соңыннан моңа үзләре дә үкенгән бугай. Документ бар, алар анда ир белән хатын, ә аерым торган бер ел эчендә хисләр шактый сүрелгән, аралар салкыная башлаган. Дөрес, Роза ханымның хатларында сагыну хисе күбрәк. Бу табигый да, ул – кыз бала, читтә берүзе. Аның күңелендә Нуриханны гына түгел, гомумән, Казанны сагыну хисе мөлдерәмә. Себер татарлары теленә, андагы мохиткә ияләшкән-

Фото: Роза Хафизова кызы Наилә белән.

че, үз диалектларында сөйләшүче балаларны якын итә, ярата башлаганчы өч-дүрт ай узган. Ә башта бик авыр булган: фатирда торган, җылы кием-салымы юк. Илленче еллар бу, юклык заман... Ярты кышка кадәр итеге дә булмый аның. Нурихан кыш уртасында гына киез итек алып җибәрә. Калын пальто да хыялда гына... Бер ел буе алар хатлар алышып торалар. Әмма ул хатларның күбесендә үпкәләшү дә үпкәләшү: мин яздым, син язмыйсың, мин җавап бирдем, син юк... Роза Себердән көнаралаш, хәтта көн саен диярлек хатлар җибәреп торган. Ә Нурихан ул, гомумән, күп сүзле түгел. Холкы шундый... Кирәген генә язгандыр йә ике хатка берне генә җавап биргәндер. Розаның хатлары исә өчәр-дүртәр биткә сузылган. Әмма шул ук вакытта алар икенче әйберләр турында да язышканнар. Мәктәп, татар теле турында. Нурихан аңа үзенең хикәяләрен җибәргән, фикерен сораган. «Син сызгалап бетер», дигән. Алар, язучы буларак, бер дәрәҗәдә сөйләшкән. Роза ханым да татар телен әйбәт белгән. Әйбәтрәк тә белмәдеме икән әле, ул бит Татарстаннан. Без бит Яңавыллар «бармаем», «кайтмаем» диебрәк сөйләшәбез. Кичә хатларын кабат укып утырдым әле. Роза Нуриханга: «Бер үк» сүзе аерым языла, – ди бер хатында. Алар шулай бер-берсен өйрәтеп, төзәтеп, тәнкыйтьләп, мактап үстергәннәр. Роза ханымның бик җылы хатлары бар: «Инәкәйне (Нуриханның әнисенә ул шулай дип эндәшкән) алып кайттыңмы инде Яңавылдан? Фатир таптыгызмы? Нишләп ике генә урындык алдыгыз, ә миңа урындык кайда? Квартир хуҗаларыгыз ничек?»... Нурихан белән әнисе гел кеше өстендә торганнар бит: әле анда, әле монда. Бер фатирдан икенчесенә, өченчесенә күчкәннәр. Мин кияүгә чыкканда да әнкәйгә 58 яшь кенә иде әле. Димәк, ул чакта аңа әле 50 дә тулмаган булган. Нигә шулай бик яшьли Казанга, Нурихан янына күченгәнме? Яңавылда да торыр җире юк, анда да кеше почмагында яшәгән ул. Икенчедән – Нурихан аның бердән-

«Бик аз сүзле, бу кадәр дә атасына охшар икән», – дия иде Наилә турында әнисе.

■ Руфинә Фәттахова: «Роза ханым белән сердәшләр булдык дия алмыйм, әлбәттә. Әмма миңа карата ул һәрвакыт киң күңелле булды».



Рәсемдә: Руфинә ханым ире Нурихан Фәттах белән.

бер улы. Ул аны юклык белән укыткан, югары белем биргән. Инде менә улы аякка баскан, язучы дигән даны бар, ананың аңа өметләре зур... Бер елдан соң Нурихан Розаны Себердән барып алып кайткач, болар өчәү булып китәләр. Алар бергә яши башлаган йортны миңа күрсәткәннәре булды. Чехов базарыннан ерак түгел иде ул. Йорт та түгел, хуҗаларның сарае. Кеше торырлык итеп күпмедер үзгәрткәннәр дә, мич чыгарганнар. «Аның салкынлыгы иде, – дип сөйли иде кайнанам. – Стеналар бозланып ката. Баланың чүпрәкләрен алыштырыр өчен, өскә пальто каплап, шуның астында гына алыштыра идек». Күз алдына гына китереп карагыз: кечкенә генә бүлмә. Җиһазлардан сандык та, тар гына карават. Яшь хатын белән ир һәм кайнана. Уйлап карасаң, анысы да яшь хатын бит әле. Нуриханга 6 яшь булганда ул тол кала һәм башка кияүгә чыкмый. Җитмәүчелек тә зур, тавыш шуннан да чыга. Балага нәкъ 1 яшь булганда, Роза ханым кызын алып Нуриханнан китә һәм аны әниләренә кайтарып куя. Аннары карьерасы башлана. Тырышлыгын, талантын күрәләр, аны партия мәктәбенә укырга җибәрәләр. Ә Нурихан белән әнисе фатирдан фатирга йөреп арып, аптырап беткәч, Киров районында начар гына бер йорт сатып алалар. Мин инде шунда килен булып төштем. Иске, начар йорт булса да, анда һәркайсыбызның үз почмагы бар иде. Нуриханның үз язу бүлмәсе. Анда үзе эшләгән бер агач шкаф, (ул шкаф әле дә исән, сарайда тора), караваты, өстәле тора. Кайнана зуррак бүлмәдә йоклый иде. Уртада ашханә кебек бүлмә дә бар. Күмер белән мичкә ягабыз. Мич артында урын бар иде, шунда Нурихан миңа – студентка – өстәл ясап бирде, китапларыма шүрлек тә эшләде. Иң әйбәт почмак минеке иде: мичкә арканы терәп утырам, каршыда тәрәзә, ул көньякка карап тора. Рәхәт...

Нурихан белән без Яңавылда таныштык. Минем I курста укыганда кышкы каникулга кайткан чагым иде. Өйдә генә утырасы килми бит, көн саен китапханәгә йөрим – классташым Әлфия анда мөдир булып эшли. Иске мәктәпне китапханә итеп үзгәрткәннәр иде. Сугыштан соңгы елларда әти шул мәктәпнең директоры булып эшләгән елларны аның бер бүлмәсендә яшәгән идек без. Ул миңа шуңа да бик якын иде – анда барсам, өйгә

Алар бер-берсенең иҗатларын күзәтеп барганнардыр, читтән булса да.

кайткан кебек булам. Әтинең фуражка элә торган элгече дә шул килеш тора, тәрәзәләр, хәтта рамнарга сылаган замазкалар да...
«Иртәгә Казаннан язучы Нурихан Фәттах кайта, укучылар конференциясе уздырабыз, син дә кил әле», – дип чакырды мине Әлфия. Бардым. Конференциясе дә, китап язган авторы да әллә ни ошамады.
Мин бит Уфада мәдәни тормышның уртасында кайнап яшим. Ә монда... район китапханәсендә ниндидер бер язучы, аның ниндидер бер китабы.... Икенче көнне миңа инде китәргә кирәк иде. Без Нурихан абый белән Яңавылдан Уфага бер үк рейста очтык. Урыннарыбыз да янәшә туры килде кебек. Саквояж кебек чемоданы бар иде кулында.
«Уфа буйлап күтәреп йөреп булмас, сезнең бүлмәгә куеп торырга ярыймы?» – диде. «Ярый», – дидем.
Ике көннән ул аны килеп алды.
Бер классташ кыз белән без аны поездга озатырга да төштек әле.
Соңыннан ачыкланды: Нурихан да мине ул чакта ошатмаган. Мине дә, дус кызымны да. Ул елны беренче тапкыр платформа модага керде – икебез дә шуны кигән идек. Кыз бала нәфисрәк булырга тиеш дип саннаган.

Аннан хатлар язышa башладык. Минем хатларның да берсен дә ташламаган ул, саклаган...

III курсны тәмамлап Яңавылга кайткач, җәй көне без кабат очраштык. Юк, Таһир-Зөһрә кебек үлеп ярату булмады безнең арада.
Ике яктан да... Ул әле тора-тора хасил булды. Хатын-кыз асылына торган ир-егет түгел иде бугай ул. Әмма аның эчке культурасы көчле, ул укымышлы иде – мине шулар җәлеп иткәндер. Ә аннан хөрмәт мәхәббәткә күчкәндер. Иҗатына гына да түгел бу хөрмәт. Ул беркайчан алдашмас, кеше сөйләмәс, башкаларның кимчелегенә төртеп күрсәтмәс. Шул ук вакытта рецензия язса, фикерен ап-ачык итеп әйтер. Әйткән сүзе белән кылган гамәле тәңгәл килде. Һәрвакыт үзенең фәненә чумып яшәде.
Кыскасы, мин ул җәйне Нуриханга кияүгә чыгарга ризалаштым..
Тулай торактан да бик туйган идем. Үлеп торган егетем дә булмагандыр, күрәсең. Әнкәй: «Күршеләр шундый матур кызыгыз карт кешегә чыккан икән, диләр», – диде. Безнең яшь аермасы тугыз ел, ул чор өчен шактый күп саналгандыр, күрәсең.

Роза ханым белән беренче очрашуны төгәл хәтерләмим. Уфада медицина институтының өч курсын тәмамлап, Казанга дүртенчегә килдем. Ә Роза ханым кызы белән ул чакта Чехов урамында торган. Безнең институт та шул якта бит. Шунда ничектер берничә мәртәбә урамда очраштык. Мин аны фотодан күреп, ул икәнен чамаладым. Матур киенгән яшь хатын. Эшкә Бутлеров урамыннан җәяү йөри иде шикелле. Бик текәлеп карап узганын хәтерлим. Мин ул чакта яшь, шат күңелле, һәрвакыт группадашлар белән, бер корпустан икенчесенә йөреп укыйбыз.

Элек Бауман урамындагы Нәшрият йортында тормыш кайнап тора иде. Тукай клубы эшли, бәйрәмнәрдә безне әле бер, әле икенче редакциягә чәй эчәргә чакыралар. Залда танцылар була. Менә шунда якыннан күрдем аны. Яңа ел иде бугай. Роза ханым кызы белән иде. Наилә ул чакта 2-3 нче класста укыгандыр. Алар баскычтан төшеп, ә без менеп киләбез. Беркем беркемгә эндәшмәде. Таныдым, әлбәттә... Бер кат өскәрәк менгәч: «Карале, бу синең кызың түгелме соң? Бар, тиз генә шоколад алып кил», – дидем. Эндәшмәде. Редакциядә чәй эчеп утырганда, кайсыдыр: «Нурихан, монда синең кызың да килгән иде әле. Ул балага берәр нәрсә алып бирергә кирәк», – диде. Нурихан буфетка барып, шоколад алып, тегеләрне эзләп йөргән, әмма тапмаган – кайтып киткән булганнар. (Нәшрият уздырган бәйрәмнәрдә Роза Хафизова башкалардан аерылып тора иде: язучы, редактор, яшьләрнең кумиры, чибәр, өс-башы гел әйбәт, прическа ясалган... Ә мин әле ул чакта студент. Бердәнбер байлыгым яшьлек булган. Тик аның алтын-көмештән зуррак байлык икәнен аңлаганмыни ул чакта?!)

Соңыннан да очрашкаладык. Бер шәһәр бит ул... Исәнләшә башладык. Бервакыт күрше хатыны Флера белән театрга киттек. Соңга калдык, без залга кергәндә утлар сүнгән, ләкин спектакль әле башланмаган иде. Урыныбызга кадәр озатып куйдылар. Ул арада пәрдә ачылды. Флера янәшәсендә утырган хатын, сузылып-сузылып, берничә тапкыр миңа карады. Антракт булып, утлар кабынгач кына таныдым – кызы белән Роза ханым икән. Алар торып чыгып киттеләр. Яңадан килеп утыргач, Роза ханым миңа: «Наилә этинең хатыны чибәр икән дип әйтә», – диде. «Роза апа (ул чакта ханым дип сөйләшми идек әле), кызыгыз белән таныштырыгыз инде», – дидем. «Менә Наилә», – диде ул. Наилә ул чакта студент булгандыр инде. Шуннан артыгын сөйләшмәдек – залда утлар сүнде. Нурихан да, кызы да бер-берсе белән аралашырга тырышмадылар кебек. Кем башлап беренче адымны ясарга тиеш булгандыр, белмим. Әнисе каршы булган очракта да, теләсә, буй җиткәч качып та килгән булыр иде әтисе янына. Кайбер гаиләләрнең балалары шулай аралашып үсә бит. Моңа мин дә, Роза ханым да бернинди киртә ясамадык. Нурихан белән дә бу хакта сөйләшкән булды. Аның аңлатуы буенча, алиментка биргәннән соң да, Роза Хафизова белән алар кат-кат судлашканнар. Китап чыгып, гонорар алган саен, ул Нуриханны судка биргән.
Күп мәртәбәләр суд юлында йөрү аны биздергән ахрысы. Шул исәптән, кызыннан да суынган.
Роза соңыннан әйтте: «Иң азакккы алиментын түләгәндә, 18 яшь тулды, соңгы тапкыр күчерәм, дип язды. Әмма кызымны туган көне белән

тәбрик итәм дигән сүзләр булмады», – диде. Аның да үз ягыннан хәтере калган булгандыр.

Белүемчә, Наилә мәктәпне медальгә тәмамлаган. Күрәсең, әтиәнисе кебек талантлы һәм тырыш булгандыр. Кандидатлык диссертациясен Уфада яклады. Шуның алдыннан безгә Нуриханның китапларын күтәреп, Тавил Хаҗиәхмәтов килде. Наиләнең Уфадагы җитәкчесе: «Әтиеңнең китапларыннан башка килмә», – дигән. Нурихан барысына да автограф язып бирде. Ә докторлык диссертациясен Наилә кайда яклагандыр, әйтә алмыйм. Аның уңышлары өчен әтисе сөенгәнме, юкмы икәнен белмим, белгертмәде. Бер көнне күрше Әминә апа белән бакчада койма аша гына сөйләшеп торабыз. «Карале, Нуриханның тагын бер кызы бар икән бит», – ди. «Беләм, беләм, Әминә апа», – дим. «Республика Татарстан» газетасында аның турында язганнар», – ди. «Үзеңә кирәкмәсә, бир әле, мин дә укыйм», – дип сорап алдым. Газетаның беренче битендә үк Наиләнең 50 еллык юбилее уңаеннан чыккан язма иде ул. Фотосы да бар. Укыдым да Нуриханга бирдем. Каршында берничә көн тотты ул аны.

Нуриханның «Әттә» дигән бер хикәясе бар. Яшь-яшь килеш премия ала ул аның өчен. Әйбәт хикәя! Хатыны кызын алып киткәч, аны сагыну тәэсирендә язылган.

Роза ханымның дачалары Займищеда, Аяз Гыйләҗевларныкы белән күрше иде. Аязлар бакчасына Нурихан белән парлап бер кунакка баруда, ул мине үзенә дәшеп алды. Кара-каршы утырып икәү генә сөйләштек, чәй эчтек, күчтәнәчләр биреп чыгарды. Менә шундый бер якынаю булып алды.

Бер тапкыр мин аңа: «Сезнең бөтен хатларыгызны да укыдым», – дидем. «Алар исәнмени? – диде ул. – Миңа бирмәссезме?» «Юк инде, Роза ханым, алар бит Нуриханның шәхси әйбере», – дип көлеп кенә куйдым. Мин ул хатларны Нуриханның башка кәгазьләре, кулъязмалары белән бергә архивка тапшырырга җыенам. Нурихан исән булганда, бу хатларның барлыгын да белмәдем. Аның язу бүлмәсенә тузан сөртергә, идән юарга гына керә идем. Ул, гомумән, бернәрсәне дә ташламаган.

Роза ханымның вафаты хакында соңлап ишеттем. Шунда ук Наиләгә шалтыраттым. «Наилә, мин Руфина апаң, белми калдым, кайгыгызны уртаклашам, кайда җирләдегез?» – дип сорадым. Әйбәт кенә сөйләштек. Аралашсалар, Наиләнең туганнары артыр – энесе белән сеңлесе булыр иде. Безнең Чулпан кечкенәдән бик күп укыды. Укымаган әкияте калмады аның. Әле сөйләшеп утырдык. «Роза Хафизова – менә дигән балалар язучысы, аның әкиятләре искиткеч», – ди. «Кайда соң алар, өйдә тапмыйм», – дим. Күрәсең, ул аларны үз балаларына укырга алып киткән.

– Торыр өчен юньле шартлар булса, без, билгеле, аерылышмаган булыр идек...

Нуриханны озатырга килгәч, залда, мәет янында, кеше алдында әйтте бу сүзләрне Роза ханым. Гөлчәчәк апа, Әхмәт абый Галиевлар белән бергә килде ул безгә. Тик монда шартлар гына түгел, кайнананың да роле зур булган дип уйлыйм. Шактый кырыс иде ул, килененә көн күрсәтмәгәндер. Үзе дә бәхетсез хатын булган кайнанам. 22 яшендә аны хатыны үлгән ике балалы карт иргә кияүгә бирәләр. Туган балалары бер-бер артлы үлеп бара. Бердәнбер улы исән кала – Нурихан. Кайнанасы шулкадәр усал була, «Болын кадәр бакчага бәрәңге утыртсак та, бәрәңге пешереп ашарга да хакым юк иде, палас сукканда җепне манган буяулы суда яшереп пешерә идем», – дип сөйли иде. Беренче елларны бездә дә төрле хәлләр булды. Мин әле студент, алар җилкәсендә яшим. Ә аннан, еллар үткәч, без дуслаштык. Икебез дә картайгач: «Нигә син, әнкәй, беренче елларда шулкадәр мине яратмадың?» – дип сорадым. «Ә мин сине тормассың дип уйлаган идем», – диде ул. Мине ачуланырга бер сәбәп тә тапмаса, сүзне: «Менә синең атаң...» – дип башлый иде. Әти мәктәп директоры булганда, ул аның кул астында эшләгән. Кайнанамның әтигә булган мөнәсәбәте шулай миндә чагылгандыр. Әмма әйбәт яклары да бар иде аның. Туганнарыма караңгы чырай күрсәтмәде. Читкә минем хакта начар сүз чыгармады. Юмарт иде. Без 23 ел бергә гомер иттек.

Инде ахырда Роза ханымның хатларыннан берничә өзек укыйк. Икесенең дә рухларына дога булып барсын.

«Нурыйхан, хәзер безнең дәрес бетте, директор «педагогическое чтение» дип алып калды. Мин өйрәндем инде, мине берәр нәрсәгә ачулана башласалар, тотам да синең турында уйлап утыра башлыйм. Рәхәт була шундый. Кеше сине ачулана, ә син рәхәтләнеп утырасың».

«Нурыйханкаем, дим, ничек мин сине сагынам! Просто үлеп-үлеп. Ярый әле эш күп, әз генә вакыт калса да, синең турында уйлыйм. Ә син уйламыйсың да булыр, уйласаң, хат язар идең. Хатны көн аралаш язмасаң, үпкәлим. Бичәң».

«8 Март көнне бөтен кеше телеграмма алды. Безнең көн бит ул. Ә син өч сүздән торган телеграмма да җибәрә алмадың. Син әйтерсең инде, имеш, син ике кешене карыйсың, акчаң булмады телеграмма бирергә. Ерунда! Инәкәйнең пенсиясе үзенә җитә. Син шул үзең турында гына уйлыйсың, юк, үзең турында да уйламыйсың. Просто синең өчен үз дөньяң гына бар».

«Инде минем сиңа үпкәләгәнгә әллә никадәр вакыт узды. 4 хатыңа да җавап язмадым. Үпкәм ул хатлар белән генә басылырлык түгел шул. Хатларыңны әйтерсең законлы хатыныңа язмыйсың, ә әллә кемгә, чит кешегә язасың».

«Нурыйхан, әллә беренче пароход белән киләсеңме соң? Бик тә сагындым инде. Беренче пароход апрель азагында килә Тобольскига. Нурыйхан дим, кил соң, ә? Эшләргә өйгә ал. Бер 10 көннән әйләнеп кайтырсың. Ничек уйлыйсың? Синең шул мине күрәсең килмидер. Шулай булгач, исең дә китми. Мин син килүгә әзерләнеп торыр идем».

Гөлнур САФИУЛЛИНА әзерләде.



Тулысынча сайтыбызда укыгыз.



БАЛАН АЧЫЛАРЫ



Лилия ГӘРӘЕВА

Әйдәгез, без бу хатынның исемен күрсәтмибез. Шулай исемсез генә булсын ул. Аның ни атлы булуы мөһим дә түгел бит. Ул – шушы көндәлекләрнең хуҗасы. Теләсәгез, бастырыгыз, гыйбрәт булсын дип, егерме ел элек язылган дәфтәрләрне, миңа биргән иде. Биш еллап өстәл тартмамда ятты әле алар: бер алдым, бер куйдым. Гаилә серен бар җиһанга чыгарып селкергә йөрәгем җитмәдеме соң? Алай дисәң, мондый гына серләр кемдә юк икән? Башта мин язмамны «Хыянәт көндәлеге» дип атарга теләгән идем, аннары шушы исемне сайладым. Бигрәк ачы шул ул хыянәт. Ачы баланнардан да ачырак.

«...Ул көн әле дә хәтеремдә. Хәтта кайсы көн икәнен дә беләм. 14 ноябрь – танышкан көнебез иде ул. Укудан иртәрәк бушадым да, юл уңае тәм-том ала кайтып, кечкенә генә табын әзерләдем. Матур савыт-сабаларым юк югын, бар булганы өч тәлинкә дә ике чынаяк. Савыт-саба түгел, әле торыр урыныбыз да юк. Вакытлыча сыенган бу бүлмәне тиздән бушатасы.

Үзем әни бүләк иткән табадан өчпочмакларымны кубарам, үземнең күзем сәгатьтә. Токарлана бит бу кеше! Секундлар – минутка, минутлар сәгатькә тоташты. Баштарак, эш белән мавыгып, әллә ни хафаланмаган идем, вакыт узган саен, шөбһә кортым зурайды. Аллакаем, ниләр генә булды икән?

Кесәдә генә йөртә торган телефоннар юк иде әле ул чорда. Ут йотып, төнге уникене суктырдым. Өчпочмакларым табында килеш суынды. Бер-бер хәл булган инде, югыйсә шушындый истәлекле көнебездә вакытында кайтыр иде ул. Үземә урын таба алмыйча, тугыз квадрат метрлы бүлмәдә ишекле-түрле йөреп арыганнан соң, салкын урын-җиргә барып яттым. Иртәнге өч булып килә. Урамдагы һәр аяк тавышына сагаеп, ул бугай, дип ята торгач, йокымсырап киткәнмен. Ачкыч борган тавышка чәчрәп уяндым. Әле генә бар җанымны биләгән курку мизгел эчендә ярсуга әйләнде. Ишек яңагына сөялеп, аңлату көтәм. Ә ул, берни булмагандай, сызгыра-сызгыра чишенде дә юыну бүлмәсенә чыгып китте. Бик озаклап юынды. Юри вакытны сузар өчен шулай мыштырдыйдыр кебек тоелды миңа. Чыкты. Миңа аз гына да игътибар итмичә, урынга барып ятты. Шаккаттым! Иртәнге дүрткә кадәр юньле эш белән йөрмәгән бит инде ул! Пышылдап кына (юка такта стена аша күршеләр йоклый) кайда йөргәнен сорыйм. Пышылдаганым ысылдау булып чыга. Ә ул, берни аңлатмыйча, стенага таба борылып ятты да гырлап йоклап та китте. Гасабиланып, касыгына төртәм: «Кайда булдың?» Йокы аралаш нидер мыгырдый. Ярсудан, гарьлегемнән тешем тешкә тими. Күңелемә әллә нинди гоманнар килә. Миңа аның эштә токарлануына ышануы җиңелрәк. Дөреслеккә якын булганы өчен түгел, хисләрем кимсенмәсен өчен. Ләкин аның эшендә берничек тә токарлана алмаганын беләм.

...Ул көнне безнең мәхәббәт кенә түгел, күңелемдә аңа булган ышанычым да чатнады. Кемдә-кемдә, бездә болай булырга тиеш түгел иде. Әле бит өйләнешкәнебезгә дә ярты еллап кына! Ә ничек яратышып кавышкан идек. Хәтта минем укып бетереп диплом алганны да көтеп тормадык. Ул да яңа гына эшкә урнашып йөри, уч тутырып акчасын да алганы юк. Әнә шуңа да туйдан соң безнең хәтта торыр урыныбыз да булмады. Ул – үз туганнарында, мин үзебезнекеләрдә яшәдек. Очрашу урыныбыз – ишегалдындагы аркалы эскәмия иде. Кулны – кулга, башны башка куеп кара төнгә кадәр бер-беребездән аерыла алмый утырабыз да, ул мине үзем яшәгән катка кадәр озата менә. Артыннан үзәкләрем өзелеп калам. Инде менә шушы бүлмә булып, бәхет куышыбызга тиендек, дисәм...

...Аның токарланулары кабатланды. Мин елыйм, ярсыйм, үпкәлим... Барысын да уртага салып сөйләшмәкче булам, ә ул дәшми. Иң авыры да – аның дәшмәве. Һичьюгы ялганласын иде ул, аклансын иде, гафу үтенсен... Өйдәге тынлык атналарга сузыла. «Кайда булдың? Эштә түгеллегеңне беләм бит», – дим. «Белгәч, ник сорыйсың алайса?» – ди исе китми генә. «Ничек инде сорамыйм?! Без бер гаилә хәзер. Кайда йөрүеңне белергә хакым бардыр бит?» – «Эштә булдым». Әнә шундый өзелмәс бәжра. Ярсуымнан түземем төкәнеп, йөзенә кизәнәм. Ул беләзегемнән эләктерә дә диванга ата. «Аһ, син әле алаймы! Хыянәтче син!»

Яңагына чалтыраткannan ул үзе дә бер мәл аптырап калды бугай. Мизгел эчендә күзендә усал аҗагаyнар кабынганын күреп алам. Аннары ни булганын исемә дә төшерәсем килми. Күңелем тулы рәнҗү белән үземә урынны аерым җәям. Төне буе керфек какмый алга таба ничек яшәргә икәнен уйлыйм. Бергә яшәп булмасы көн кебек ачык. Хатын-кызга кул күтәргән кеше – ул инде кеше түгел. Ләкин... әнигә бу хәбәрнең никадәр авыр булачагын әлегә уйларга да базмыйм. Ул да иреннән яшьли аерылган һәм моның өчен үзен гомере буе битәрләде. «Барган урыныңда таш бул!» – мине шулай дип үстерде ул. Их, әни, таш түгел, каурыйга әверелеп, әллә кая, күз күрмәгән якларга очасы иде хәзер. «Кая очасың? Аерылып, кеше көлдермәкче буласыңмы? Ул да авылга кайтыр, син дә кайтырсың, юлларыгыз гел кисешеп торыр» – күңелемнең бер почмагында каһкаһә белән кемдер көлеп куйды. Кемдер түгел, ул мин үзем идем. Күңелем сыкраса да, чын-чынлап аерылышу турында уйлыйсым килми икән әле минем. Бәлки... мин үзем гаепледер? Ләкин ничек кенә баш ватсам да, гаебемнең нидә булуын ачыклый алмадым. Әлегә.

...Иртән укшытканга уянып киттем. Тагын! Нинди хәл булды соң инде бу көн саен? Санымны көч-хәл белән күтәреп, укырга чыгып киттем. Бүген барысына да нокта куярга кирәк. Кич кайткач, аңлашырга тырышып карармын. «Бәхете дә, бәхетсезлеге дә үз кулыбызда, – диярмен. – Гаилә булып яшәүнең үз кануннары бар, иң мөһиме: бер-береңне ихтирам итү. Вакытында өйгә кайтмыйча йөреп, син мине кимсетәсең. Кояшлы көн ул менә бүген, иртәгә нәрсә буласын беребез дә белми. Бүген матур итеп яшәп калыйк», – диярмен...

Әмма ул көнне аңлашу насыйп булмады. Безнең өчен язмыш барысын да уйлап куйган иде инде. Тәнәфестә буылып-буылып укшыганымны күргән кураторыбыз мине кайтарып җибәрде. Дөресе, кайтарып түгел, ә хатын-кызлар табибына күренергә кушып җибәрде. Инде үзем дә сәбәбенә төшенә башлаган идем.

Укуым тәмамланмый торып, бәби алып кайтмабыз, дигән идек әле. Яңарак кына операция кичердем. «Балага узсаң да, берничә елсыз аны организмың күтәрә алмас», – диде табиблар. Яшьлек дәрте үзенекен итә шул, тулысынча сакланып бетеп булмаган, димәк. Күңелем бу борылышка риза түгел иде. Яшәп буламы, юкмы дип икеләнгәндә, нинди бала ди? Ә ул шат иде.

Фото: Газинур Хафизов



Күзләремнән, битләремнән үбә-үбә: «Әйдә, бүгеннән матур итеп яшибез», – дигән сүзләре күңелемә май булып ятты. «Бер болганмый су тынмый», – ди иде әбием. Тагын бер сүзе бар иде әле аның: «Утызга җитми, ирләргә акыл керми». Туачак җан хакына 23 яшьлек акылсыз иремә тагын бер ышанып карарга булдым.

...Мин аның белән көтмәгәндә очраштым. Мунчага барырга дип трамвай көтә идек. Халык күп. Ирем вагонга беренче булып үтте, ә мин, озын итәкләремә абынып, артка калдым. «Җимешем!» Назлы тавыш иясе, трамвайдагыларга игътибар итмәстән, иремнең муенына сарылды. Анысы ялт кына минем якка күз ташлап, әле ябылырга өлгермәгән ишеккә томырылды. Юл уңае терсәгемнән эләктереп, мине дә тартып төшерде. «Трамвай белән йөргәнче... Халык та күп, йә сытарлар үзеңне...» Ләкин мин барысын да күреп өлгергән идем. «Шул хатын янына йөрисеңме эштән соң?» – дигән соравым тагын һавада эленеп калды. «Мине кайнатып чыгаруның иң шәп ысулын белә бу», – дип уйладым эчемнән. Шушы мизгелдә минем йә аны, йә үземне трамвай асларына саласым килде. «Болай яшисем килми!» – дип гасабиланып кычкырды җаным. Бар көчемә беләгемне ирем кулыннан йолкып алдым: «Кагылма миңа!» Ул тукталышта басып калды, ә мин, бозлы юлдан тая-тая, олы корсагымны күтәреп өйгә йөгердем. Югыйсә үз-үземне тыеп торырлыгым калмаган иде инде. Күңелемдә бары бер уй бөтерелде: тизрәк үләргә дә, бу әрнүдән тизрәк котылырга.

...Бүген ул бөтенләй кайтмады... Хәтта икенче көнне дә... Баланы күтәреп, аның эш урынына киттем. «Бер атнага үз хисабына ял алды бит ул», – диде минем бихәбәрлегемә үзе дә аптыраган мөдир. Димәк, әйтми генә авылга кайтып киткән! Күршеләрнең телефон номерын җыям, әнине генә чакырырлар әле. «Юк шул, монда кайтмады бит ул, аһ-һһ...» – кайнанамның аһын телефонның пипелдәве бүлә, мин теләнә басып, тиз генә элемтәне өзәм. Каударланып, 02 номерын җыям. «Алло! Кеше югалса, аны ничек эзлисе? Заявка кабул итегез әле!» Гаризалар өч көнсез кабул ителми икән. Кесә төбендәге соңгы жетоным беткәнче, больницаларга, моргларга шалтыратып иремне эзлим. «Кайтыр», – дип тынычландыра элемтәнең теге очындагы миңа бөтенләй дә таныш булмаган кешеләр.

Үкереп елаган баланы күтәреп, кире өйгә кайтып аудым. Башымда ниндидер бәйләнешсез уйлар. «Ничек??? Ничек болай?!! Аз гына булса да яраткан кеше хатынын шундый газапларга салырмы? Мине генә түгел, газиз баласын да кызганмый бит!» Үзебезне кызганудан, кимсенүемнән балама кушылып илереп еладым. Мин – гарьлегемнән, ә балам – ачлыктан. Артык дулкынланганга, сөтем беткән иде минем...

...Өчме-дүртме көннән кайтты ул. Кайтышына бөтен киемнәрен сумкасына тутырып куйган идем. Өйгә кертмәдем. Ишекнең читен ачып, сумканы подъездга гына ыргыттым. «Эзең булмасын бүтән! Кем янынннан кайттың, шуның янында яшә!» Ә ул әйтерсең шуны гына көткән, киемнәрен иелеп алды да, сызгыра-сызгыра баскычтан төшеп китте. Гафу да юк, аңлату да... Бәлки, китүе яхшырактыр... Болай кимсенеп яшәгәнче...

...Кесәмдә йөз егерме сум акчам калган иде. Бик тырышсаң, аңа бер атна яшәргә була анысы. Балага сөт кухнясыннан бушка сөтен, кефирын биреп торалар. Ә аннан соң? Нинди акчага яшәрбез дә, квартира өчен кайдан алып түләрбез? Тормышыбызның чәлпәрәмә килгәнен әлегә беркемгә дә белдерәсем килми иде.

Баланы дус кызыма калдырып, ЖЭУга юнәлдем. «Боз вата алсагыз гына. Безгә дворниклар кирәк кирәген...» Иртәгә үк эшкә чыгу шарты белән теркәлеп үк кайттым. Югары белемле ишегалды җыештыручы мин хәзер. Кесәмдәге барлы-юклы акчамның сиксән сумы көрәк алырга китте. «Аллаһы Тәгалә ярдәмен бирер әле», – дип тынычландырдым үземне. Безме инде кар көрәп үсмәгән?! Иртәнге якта балам тынычлап йоклый, ул уянганчы тиз генә җыештырып керермен.

...Ялгызлык тормышым әнә шулай башланып китте. Аны сагынмадым, көтмәдем, дип алдый алмыйм. Бик сагындым, көттем дә. Килсә, бар үпкәләремне, горурлыгымны җиңеп кабул итәсе идем. Әтиле балаларга кызыгып үскән балачагымның һәр мизгеле күз алдымда иде әле. Дусларым: «Безнең әти», – дигәндә, минем дә ул сүзләрне әйтәсем бик килде. Инде хәзер минә балам ятим үсәчәк. Тулыр-тулмас ике еллык ирле тормышымны анализлап, үземнең дә күп хаталар ясаганымны аңлаган идем инде. Иң зурысы, мөгаен, үпкәчеллегем булгандыр. Юк-бар өчен дә авызым турсаерга гына тора иде шул. Ялгызын калдырып гел авылга кайтып китүем дә дөрес булмады. Кайтмыйча да булмый: әни ялгызы. Назымны кызганып та аз үртәмәдем.

...Ял көне иде. Кемдер ишек какты. Ул килгән! «Кертәсеңме? Баланы сагындым», – диде нәүмиз генә. Инде дүрт айлап күрешкәнебез юк иде. Бүлмәгә кайчан гына мине иләсләндергән шулкадәр таныш ис – аның исе тулды. «Ашыйсыңмы?» – дидем, тәлинкәгә өчпочмаклар тезә-тезә. «Ашыйм», – диде ул. Без, арадагы үпкәләрне читкә куеп, үткәннәрнең бары матурларын гына искә ала-ала, өчәүләшеп чәй эчтек. «Каласыңмы?» – дидем. «Калам! – диде. – Кичерерсеңме?» Кичә генә култыклашып атлаган матур парларга кызыкканым йөрәгемне чеметтереп узды. «Ирсез тормыш – эт тормышы», – дип әйтергә ярата әни. «Артка түгел, алга карарга кирәк!» – монысы, мөгаен, берәр укытучымның сүзләре булгандыр. «Әче баланнар белән сыйламассыңмы?» – «Мин сине баллы чияләр белән генә сыйлармын...»

...Чынлыкта, баллы чияләре дә, ачы баланнары да булды әле. Чияләргә караганда, баланнары шулай да күбрәк иде».

АЧУ – АГУ



Илнар хәзрәт
ЗИННӘТУЛЛИН,
«Туган авылым»
мәчете
имам-хатыйбы

Ачуланганда ачуны эчтә тыеп калу мөмкин эшме?

– Ачу турында аерым хәдис бар. Бер кеше пәйгамбәребез янына килеп: «Миңа киңәш бир әле», – дигәч, ул: «Ачуланма», – ди. «Тагын нинди киңәш бирәсең?» – дигәч, кабат: «Ачуланма», – ди. Өченче тапкыр да янә шул ук сүзне әйтә. Моннан чыгып та ачу, кызып китү, ярсуның яхшы сыйфат түгеллеген аңларга була. Ачу – нәрсәдәндер риза һәм канәгать булмаудан килеп чыга. Әйтик, эшләгәндә кулыңнан чүкеч төшеп китте, ди. Яки син «бөке»дә утырасың. Ачуланасың, эчтән кыза башлыйсың (шуңа күрә «кызма», диләр). Әлеге халәт әкрен генә башыңа менеп җитә һәм акылны сүндерә. Бу – ачуның төп зыяны. Син инде хәзер теләсә нәрсә әйтергә, эшләргә сәләтле, чөнки акыл белән эш итмисең. Шуңа да галимнәр ачу килүне сизү белән бернәрсә дә сөйләшмәскә, әйтмәскә кирәк, диләр. Нидер эшләргә дә ярамый. (Балага җәза бирергә теләсәң, моны ачуың беткәч кенә эшләргә тиешсең.) Ачуны аз гына тынычландыру өчен җиргә якынрак халәткә күчәргә кирәк: басып торсаң – утырырга, утырып торсаң – ятарга. Ачуны тәһарәт алу да сүндерә. (Ким дигәндә, юыну.) Ни өчен тәһарәт алырга кирәкме, чөнки пәйгамбәребез «ачу, ярсу – ул шайтаннан, ә шайтан – уттан» ди. Ә су, белгәнебезчә, утны сүндерә. Шайтаннан булган бернәрсәне дә яхшы дия алмыйбыз. Ачу килү аркасында шайтан сине бик түбән дәрәҗәгә төшерә. Ярсып кычкырганда, кеше кызарып чыга, бик ямьсез була. Ачу белән, уйламыйча, ниндидер адым ясап, җинаять кылырга да мөмкин. «Состояние аффекта» дигән термин бар: үзеңне контрольдә тота алмаган ярсу халәте бу. Мондый ачуның нәтиҗәсе кайчакта бик аяныч та тәмамлана ала. Ачу килгән вакытта «әгүүзү билләәһи минәшшәйтаанир-раҗииим» дип әйтү дә булыша.

Гомумән, ачуны булдырмас өчен нишләргә кирәк?

– Үзеңдә ризалык һәм канәгатьлек хисе үстерергә кирәк. Бу – Аллаһы Тәгаләдән, аның тәкъдиреннән риза булу дигән сүз. Дөньяда ни генә булса да, Аллаһы Тәгаләнең әмере белән башкарыла, ул сиңа яхшылык кына тели. Моны аңлау сине тынычландыра: ачу чыгарга сәбәп калмый. Ачу килмәсен өчен хәләл ризык ашау бик мөһим. Әйтик, галимнәр, дуңгыз ите кешенең ачуын чыгарырга этәргеч булып тора, диләр. Һәрбер хайван да суйган вакытта курку кичерә – адреналин бүленеп чыга. Гадәттә ул кан белән чыгып бетә. Ә дуңгызныкы канга түгел, иткә тарала икән. Адреналин безнең үзебездә дә җитәрлек, инде читтән дә керә башлаcard... Кеше тик торганнан да шуңа кызып китә, бер дә сабырлыгы юк хәзер. Өченче сәбәп – дөньяны ярату, аңардан күпне өмет итү. Бу очракта ул синең күңелеңне төшерә, чөнки дөнья бервакытта да безнең өметләрне акламаячак. Шуңа да дөньяны артык яратмаска кирәк. Ачуның синонимы – сабырсыз дигән сүз. Дога кылып, Аллаһы Тәгаләдән балалар өчен тәүфыйк, күркәм холык сорау бик мөһим.

Шулай да, ачуны сиздерергә кирәк булган ниндидер очраклар бармы?

– Әйе, кеше һәрвакыт бөтен нәрсәдән дә риза була алмый. Мәсәлән, гаделсезлектән. Кемнеңдер җинаять кылуыннан. Балаларының тәртипсезлегеннән. Хатынының (иренең) начарлык эшләвеннән. Ачуның хәләл, ягъни рөхсәт ителгән очрагы бар: дингә начарлык кылынган вакытта ачуыңны күрсәтергә тиешсең. Ул, әлбәттә, башыңны, контрольне югалта торган ачу булырга тиеш түгел. Әмма тышкы кыяфәтеңә ачу чыгарга тиеш. Пәйгамбәребезнең дә ачуы килгән, әмма ул бервакытта да бу халәттә нидер эшләмәгән. Бераз тавышын күтәреп, үзенең риза булмавын күрсәтә торган булган. Шуңа күрә кайбер очракларда моны эшләргә була. Әйтик, ире начарлык кылса, хатыны аны елмаеп әйтә алмый бит: кашын җыера, ачулана. Бу – табигый халәт, ачуны бөтенләй бетерергә түгел, аны кирәкле урында куллана белергә кирәк. Хәзерге заманның бәласе шунда: кешенең ачуы гаделсезлеккә түгел, ә юк-барга чыга. Әйтик, ялгыш сүз ишетсә дә, ул дөртләп кабына, ә чын гаделсезлек күрсә, беркемнең ачуы килми. Кондуктор билет өчен түли алмаган әбине кыйнаса, бөтен автобус карап тора. Берәр баланы, акчаң җитми дип, салкында төшереп калдырса да, беркем аңа сүз әйтми. Бу дөрес күренеш түгел, замананың кире якка борылуы. Пәйгамбәребез «авыр күтәрүче түгел, ә ачу килгәндә үзен тотып калган кеше көчле» ди. Шундый чакта үз-үзеңне тотып калырга өйрәнсәң, димәк, син инде үзеңә-үзең хуҗа дигән сүз. Диннең дә максаты – кешенең үз-үзенә, хисләренә, нәфесенә хуҗа булырга өйрәнүе. Ачу халәте озак бармый – бер мизгел генә. Аның иң югары ноктасы була, шул вакытта үзеңне тота алсаң (ә моңа бер минут җитә), аннары ул төшә башлый. Ул көчәйгәндә, шартлап, нидер эшләсәң – үз гамәлләреңнең колына әйләнәсең. Ачуың килгәндә бишкә, унга кадәр сана, дип, юкка әйтмиләр. Бу – файдалы киңәш.

«Состояние аффекта» дигән нәрсә ислам динендә дә бар. Кеше үзен контрольдә тотмаган халәттә берәр нәрсә эшләсә, әйтик хатынын аерса һәм моны үзе хәтерләмәсә, бу дөрес саналмый. Әгәр кеше дөрес тормыш белән яшәсә, «состояние аффекта» аңарда беркайчан булмаячак. Ачу – ут кебек дидек, ул янсын өчен гел нидер өстәргә кирәк. Аны «тукландырмасаң», бу халәтең сүрелә, кими, син аны җиңәсең. Ачу килү белән көрәшәсең килсә, тәкәбберлек белән көрәшергә кирәк. Ачуның сәбәбе тәкәбберлеккә дә бәйле.

«УЛ БҮГЕН ДӘ МАТУР!»


Фото: https://kamalteatr.ru

Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя... Ә ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән? Сүзне аларга бирик.

Равил ШӘРӘФИЕВ,
Россиянең һәм Татарстанның халык артисты. Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты;
гаилә стажы – 47 ел;
балалары – Равия, Вильям.

1 Иң элек хатын-кызның нәрсәсенә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...

– Күзләр бөтенесен сөйли... Тышкы кыяфәте белән чибәр генә ханымнар... Күзләренә карасаң, кем икәнен шундук аңлыйсың. Шулай ук сәхнәдә уйнаган артистларның да кем икәнен күреп торам... Тормышта да беренче карашка әллә ни тоелмаган хатын-кызлар, сөйләшә-сөйләшә, башкача ачыла: күңеле чиста, уйлары матурларның бай эчке дөньясы күзләрендә чагыла.

2 Нәрсә өчен бик якын хатын-кызны да гафу итмәс идегез?

– Яратып өйләнгәч, ул синең хатыныңда булырга да тиеш түгел бит инде. Гафу итеп булмый торган әйбер... хыянәттер. Мин, мәсәлән, аны гафу итә алмас идем. Яһүдләрдә кызыграк ул: үзе дә йөри, хатыны да... Шуны белә торып, алар бер-берсен гафу итәләр. Юк, без андый түгел.

3 Хатын-кызлар икегә бүленә: ир-атны илһамландыручы алиһәләр һәм өйдә аның өчен комфорт тудыручы хуҗабикәләр. Сезгә аның кайсы якынрак?

– Мөгаен, икенчеседер. Ризык мәсьәләсендә бик таләпчән, четереклерәк идем мин. Ә Раушания бик уңган булып чыкты: рецептларын үзе уйлап чыгарып та пешерә. Мин әле ул вакытта аш яратмый идем. Ә татар ирләре аш ашый һәм аларның ашау ягыннан капризлары булмый икән. Чөнки кайнар шулпа, бөтен җанга-тәнгә үтеп, рәхәтлек бирә. Аш ашый башлагач, минем дә капризларым кимеде. Хатынга да җиңелрәк булып киткәндер... Хатын ул аш пешерүче генә түгел, сиңа комачауламый гына иҗатыңа да ярдәм итүче булырга тиеш, минемчә. Ул җәһәттән Раушания шактый акыллы хатын. Театр сәнгатен аңлый, киңәшләрен дә бирә. Зәвыгы әйбәт аның.

4 Ир кеше өчен хатыны аңа дус та була аламы?

– Була ала гына түгел, дус булырга тиеш тә! Ромео-Джульетталарныкы кебек мәхәббәт, ярату шул көенчә сакланмый бит ул – соңыннан күбрәк хөрмәткә әйләнә. Хәзер инде бездә дә күз карашыннан да аңлашыла торган дустанә мөнәсәбәтләр... Каприз кеше мин. Чак кына, ярты тонда гына тавыш күтәрү дә ярамый миңа. Башта ук әйттем Раушаниягә: «Минем белән бәхәсләшмә, – дидем. – Вак-төякләр буенча гомумән бәхәсләшмә! Ә зуррак әйберләрдә «фәлән итәргә кирәк!» дип түгел, «болай итсәк ничек булыр икән?» дип әйт». Юкса мин аны диктат итеп, дорфалык дип кабул итәргә мөмкин.

5 Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганыгызны хәтерлисезме?

– Мин үземне өйләнми торган кеше, урыслар әйтмешли, убежденный холостяк дип йөри идем. Сәбәбе бер генә инде: хәерчелекне нигә арттырырга, янәсе. 34 яшькә кадәр яшәдем шулай. Әни борчыла башлады: «Улым, өйлән инде, әллә ничек бит, кешедән уңайсыз», – ди. Берзаман күңелсез була башлады. Яшьлек узып бара... Якын кеше кирәк. Шундый ихтыяҗ тугач, өйләнергә булдым. Раушания театрда яктыртучы булып эшли иде. Баштарак сүз кушкалап йөрдем. Бер көнне озатып куярга булдым. «Ашарга пешерә беләсеңме?» – дип сорадым. «Белмим, ләкин өйрәнермен», – диде. Шул сүзе белән яулап алды ул мине. «Бу минем хатын булачак!» – дип куйдым эчтән генә. Шуннан – шул, озак тормый тәкъдим ясадым инде. Ризалык бирде. Бу – 1972 елның апреле, Раушаниягә ул вакытта 21 яшь иде. Кыз сорарга бармадым – Актаныш бик ерак – «переговорный пункт»та кызның кулын телефон аша әнисеннән сорадым. Ничек җавап биргәндер, һәрхәлдә, кире җавап түгел иде... Өйләнешкәч, Раушаниянекеләрне «әти, әни» дип йөртә башладым. Мин ул вакытта филармониядә эшли башлаган идем. Таһир Якупов бригадасы белән шул якларга чыгып китәчәкбез. Администраторыбыз – 75 яшьлек ап-ак чәчле бабай – Актанышка концертлар турында сөйләшергә барырга җыена. Суыксуга сугылсагыз, безнең әти-әниләргә кереп чәй эчеп чыгыгыз, дим. Кергән, кунак булган. Кайнеш озата чыкканда күрше хатын туктатып, бу җизнәңме әллә, дип сораган. Тегесе, шаяртып, әйе, дигән. «Кара, яшь икән әле, бик карт кешегә чыкты дип әйткәннәр иде», – ди икән. Концерт белән кайткач инде сәхнәгә чыктым. Халык гөжли башлады.

«Менә, күреп калыгыз, сезнең киявегез булам инде», – дидем.

6 Ир кеше хатын итеп әнисенә охшаган кызны сайлый диләр, шулаймы?

– Аны әле әнигә охшаган дип уйламый идем. Яши-яши шуны аңладым: гел әни инде! Раушания әнинең үз туфрагыннан иде. Киленен бик яратты. Раушания дә: «Рәхмәт, әнкәй, миңа әйбәт ул үстергәнсең», – дигән. Исемнәрендә үк ниндидер мәгънә охшашлыгы бар. Әнием Шәмседоһа исемле. Бездә Зоһа гына диләр иде, Илһам Шакиров исә дөрес итеп әйтеп, Доһа апа дип йөрде. Шәмседоһа – төшкә кадәрге бик кыздырмый торган йомшак кояш дигәнне аңлата. Исеме әнигә бик туры килә иде инде. Раушания дә шундый: йомшак, сабыр, җылы. Әнине гел көйләп яшәде, юындыра иде. Иртәгә вафат буласы көнне дә: «Әнкәй, оялма инде», – дип, йомшак кына сөеп, җайлап коендырды. Чип-чиста булып китте әни.

7 Хатыннары ирләреннән күбрәк мал тапкан гаиләләр бар. Ир кеше бу очракта үзен ничек тотарга тиеш?

– Әгәр хатын акыллы булса, ул ире янында үзен барыбер хатын урынында тотарга тиеш. «Мин кем дә син кем! Мал таба белмәдең, фәлән-төгән» дип яши башласа, ул хатын хатын булмый инде! Һәм ире дә ир булмый.

8 Гашыйк булуын хатын-кыз башлап үзе белдерүгә ничек карыйсыз?

– Ә нишләп белдермәскә тиеш? Хатын-кызның да яратырга хокукы бар. Ләкин әдәп белән генә сиздерергә кирәк. Басым ясый башласаң, ирләрнең гайрәтен чигерүең бар. Мәскәүдә укыганда мин бер кыз белән йөрдем. Ул үзе танышты минем белән. Әйбәт кыз иде. Хатын-кыз буларак бик үк яратып бетермәгәнмендер инде... Хөрмәт булган, яратуга кадәр җитә алмаган, күрәсең. Юк, ул әрсез кыланмады, сиздерде генә! «Син минеке бул!» дип әрсезләнгән булса, ташлап качар идем аны.

9 Хатын-кызларның үзегезнең кайсы якларыгызга игътибар итүне көтәсез?

– Урыста «порядочный» дигән сүз бар. Ул бик күп нәрсәне эченә ала. Порядочный кеше башкаларны сатмый, гайбәт йөртми, бүтәннәрнең эч серләрен читкә чыгармый... Мин шундыйрак. Зыялы дисәң, үземне андыйга ук кертә алмыйм, чөнки ул башка материя... Мин үзем турында шәхес дип әйтә алмыйм. Илһам – шәхес иде! Чөнки ул үз принципларына хыянәт итми, кемгәдер баш иеп яшәми, кемнедер сатмый, укымышлы... Үземне батыр дип тә әйтә алмыйм. Хәтта укол кадаудан да куркам. Шулай булса да, иләнндем: әллә ничә мәртәбә операция ясадылар. Мин уйлыйм. Уйламаган кеше сабый акылында кала.

10 Ир-атны артык чибәр һәм көчле хатын-кызлар куркыта...

– Шулайдыр. Артык көчле хатын-кыз миңа батмый ул. Ирдәүкәләрне кабул итмим. Әнием дә, Раушания дә гади, матур, пөхтә, йомшак булдылар...

Дөньяда мин белгән иң чибәр хатын дип Быстрицкаяны атар идем. «Тихий Дон»да Аксиньяны уйнавын гына искә төшерегез... Ул Донда кер чайкап ята. Кинәт атка атланган Григорий Мелехов килеп чыга. Кыз борыла да, куркып: «Чертяка бешеный!» – дип кычкырып җибәрә... Шул сүзләрне әйткәндә ярату да, куану да, курку да чагыла. Бер күз карашында бөтен мәхәббәт аңлашыла... «Исә Болгар җилләре» фильмын төшереп йөргәндә банкетта үзенә дә әйттем: «Дөньяда минем өчен иң матур хатын-кыз – Сез, Элина Авраамовна!» – дидем. «Нигә аны алданрак әйтмәдегез?» – ди елмаеп. Ә минем мөмкинлек бар иде! Мәскәүдә, Щепкин исемендәге театр училищесында укып йөргәндә булды ул. Быстрицкая Малый театрда төп рольдә – леди Уиндермирны уйный. Ул сәхнәдә чакта, мин аның игътибарын җәлеп итәргә, сөйләштерергә тиеш идем. Шулхәтле оялам, берни әйтә алмыйм. Мин нәрсәдер әйтерлек дәрәҗәдә идемме соң? Ул минем өчен алиһә иде бит! Бөтен тормышын үзе сөйләп чыкты. «Тихий Дон»да ничек уйнауларын да, киногa төшәр өчен махсус җиде килога тазартканнарын да...

11 Ир-ат белән хатын-кыз икесе ике галәмнән икәне билгеле инде. Кайчакларда аларның бер-берсен аңламаулары шуннан килеп чыга да.

– Дөнья булгач, була андый хәлләр дә... Бер үк нәрсәне кабат әйттермә дигәнем дә бар инде. Раушания артык игътибар күрсәтә миңа. Аны ашадыңмы, моны ашадыңмы дип, гел биеп тора. Аз ашыйсың, ди. Минем файдага дип тырышуы үзенчә. Ләкин артык күп ашау да көчне ала бит. Һич аңлата алмыйм шуны.

12 Шундый очракны күзаллыйк әле: сез, ачыгып, арыпталып эштән кайтып кересез, ә өйдә ашарга пешмәгән.

– Мин кайтуга табын һәрчак әзер. Кайчагында гына кайткан төшкә үк өлгереп җитмәскә мөмкин. Анысы инде иртәрәк кайтып кергән чакларда. Ун-унбиш минут кына көтеп тор, хәзер пешә, ди ул. Миңа кабак белән ботка булса, шул да җитә бит инде. Гел ял итә белми. Кунаклар барында инде утырып та тормый, һаман көйләп, сыйлап йөри. Вильям Уфада хореография училищесында укыганда, әнисе аның янына китте дә, кызым Равия белән икәү өйдә калдык. Ит, бәрәңге, суган салам да похлебка гына пешерәм. Әнисе кайткач, и мактана бала: пухли гына ашап тордык ди. Мин әле пылау да пешерә идем. Асия Хәйруллина өйрәтте, рецепты – аныкы. Өйләнгәнче минем пылау пылаурак иде, хәзер Раушаниянекен ашыйбыз.

13 Сер түгел, берәр җиргә җыена башласак, без, хатын-кызлар, соңга калучан.

– Хатын-кыз озаграк киенсә дә, Раушания көязләнергә яратмады. Ул беркайчан бизәнмәде. Табигый матурлыгы белән җәлеп итте. Хәзер дә шундый. Мин үзем дә бизәнгән, иннек сөрткән хатын-кызларны яратмыйм.

14 Хатын-кызлар еш кына... бүләк сайлауда ялгыша...

– Шарфлар, күлмәкләр дә алганы бар. Яка үлчәмен белә, минем кул озын икәнен белә... Ә үзенә алдырмый, сайлый белмисең ди. Туган көнендә чәчәкләрне бакчадан өзеп алып керәм. Өйләнешкән елны Ленинградта мин аңа туфли алып биргән идем. Икәү бик ошатып сайладык аны. Аннары шул ук җәйдә Ташкенттан бик матур үзбәк күлмәге алып кайттым үзенә. И килешә иде инде! Авырлы чагы. Ә күлмәк бөтенесен яшерә. Шулкадәр матур күренә иде Раушания! Ул бүген дә матур шулай!

Эльмира **ЗАКИРОВА** әзерләде



Тулысынча сайтыбызда: www.syuyumbike.ru

PRESSA



Егерме бөртек энҗе

«Энҗе» дигәннән үк, тешләр турында сүз барганын аңлагансыздыр. Бүген без балаларның сөт тешләре һәм аларны дөрес тәрбияләү турында сөйләшербез. «Сөт тешләре нибары егерме генә бөртек була, һәм балага 6 яшьләр тулгач, алар берәм-берәм коелып, яңалары – тамыр теш дигәннәре чыга. Күпләр сөт тешләренең тамыры юк дип уйлый, бу – ялгыш фикер», – ди Республика балалар клиник хастаханәсенең табиб-стоматологы Анна ПАВЛУЦКАЯ.

Балаларда кариес процессы бик тиз бара һәм берничә атнадан пульпитка, периодонтитка әйләнергә мөмкин. Шуңа да балаларның тешләренә игътибарлы булу сорала.

Сөт тешләрен кайчан чистарта башларга, дип сорый күпләр. Тешне чыга башлаган мәленнән үк чистартырга кирәк. Ашатып, 30–40 минут узуга, әни кеше кулын яхшылап юып, бармагына махсус салфетка яки кайнаган суга манылган бинт чорнап, баланың уртларын, авыз эчен сак кына сөртеп ала. Әйләнмәле хәрәкәтләр белән уртларга массаж да ясарга ярый. Бу кан әйләнешен яхшырта, уртларның сызлавын баса. Хәзер сатуда яшь балалар өчен дисклы махсус щеткалар сатыла. Кулына тоттырсагыз, ул аны кимереп, уртларын үзе дә бик шәп массажлый. Берочтан тешләрен чистартырга да өйрәнер. Ә инде сөт тешләре күренүгә, резин кыллы йомшак щеткалар куллана башларга кирәк. Алар авыз эчен җәрәхәтләми, шул ук вакытта йомшак ризык калдыкларын да яхшы чистарта. Тешләр күбәйгән саен, щетканың гадәтиен дә алырсыз. Ә менә бәләкәч авызындагысын төкерергә өйрәнми торып, теш пасталары куллану кирәкмәс.

6-7 яшьләренә кадәр баланың тешләрен олы кеше үзе чистартса, яхшырак. Аннары инде дөрес итеп чистартуын күзәтеп торыгыз. Өске тешләр – өстән аска таба, аскылары астан өскә таба өч минут чистартыла.

Баланы теш табибына елга ике тапкыр күрсәтәләр, ләкин мин кечкенәләрне өч ай саен чакырам. Теш сызлый башлагач кына табибка күренү бала өчен зур стресс булачак.

Күпләрне кариесның сәбәпләре борчый. Тешләрнең бозылуына баллыны ярату яки тешләрне тиешенчә чистартмау гына түгел, нәселдәнлек, йөклелекнең ничек узуы, баланың туклануы һәм нинди чирләр кичерүе дә йогынты ясый.

Кайчак, сөт тешләрен дәвалыйсы да юк, дигән фикерне ишетергә туры килгәли. Кичекмәстән дәваларга кирәк! Дәваланмаган теш – даими инфекция чыганагы, һәм ул гомерлек тешләрнең яралгысына зыян китерә.

Табиб киңәше

■ Тешләрне көнгә ике тапкыр чистартырга, ә щетканы ике-өч ай саен алыштырырга кирәк. Балаларга әлеге гигиена чарасын сайлауның үз таләпләре бар. Аның башы түгәрәкләнеп килсен, зур булмасын (1–1,5 см), кылы – йомшак, ә сабы резиналы булсын. Бала аны тамак төбенә кадәр тыгып бетермәсен өчен, чикләгече булганны сайлагыз.

Бозылган сөт тешен вакытыннан алда алып ташларга да ярамый. Янәшәдәгеләре шунда күчеп, аның урынына чыгучы тамыр тешкә урын калмаска һәм шуның аркасында казналык та дөрес формалашмаска мөмкин.

Әйе, балаларның күбесе теш дәвалатудан бик тә курка. Бигрәк тә уколдан. Хәзер анестезиянең әллә нинди заманча ысуллары бар. Казанда кайсыбер клиникаларда азот закисе кулланалар. Болар берьюлы берничә тешне дәваларга мөмкинлек бирә.

Тешне кариестан саклауның да төрледән-төрле ысуллары барлыкка килә тора. Әйтик, фиссураларны томалау. Табиб тешнең уртадагы батынкы урыннарына сыек герметик агыза.

3 яшькәчә балаларның тешенә көмеш ягу ысулы да кулланыла. Боларның кайсысы файдалырак булуын, тешләрнең сәламәтлегенә карап, табиб үзе хәл итә.

Мифмы, чынбарлыкмы?

■ Шоколад зыянлы. Шоколадның зыяны булу-булмау хакында табибларның фикере төрле. Әче шоколадны тешләр өчен хәтта файдалы диючеләр дә бар. Кемдер исә аның составындагы углеводларны мисалга китерә. Ә углеводлар, чынлап та, кариесның бер сәбәпчесе.

■ Тимер препаратлары эчү аркасында тешләр бозыла. Дөрестән дә, тимер препаратлары кулланганда тешләргә юып та бетми торган көрән куңык утыра. Аны фәкать профессиональ чаралар гына бетерә ала. Йөкле вакытта әнисе тимер препаратлары кулланганга баланың теше бозыла дип әйтү – дөрес түгел.



Холестеринны төшерәбез

Атеросклероз килеп чыгуның төп сәбәбе – канда холестерин күләме югары булу. Ә моның азагы шактый аянычлы – инфаркт яки инсульт белән тәмамланырга да бик мөмкин. Гәүдәнең артык авырлыгы, даими рәвештә югары калорияле һәм майлы ризык белән туклану, стресслар – болар бар да холестерин күтәрелүгә сәбәп булып тора. Организмның гомуми хәлен нормальләштерү, холестеринны төшерү өчен җиләк-җимеш күбрәк ашарга кирәк. Табиб-кардиолог, терапевт Альбина ШАҺИДУЛЛИНА безгә шул хакта сөйли.

Холестерин безнең организмга ферментлар, гормоннар һәм башка элементлар барлыкка китерү өчен кирәк. Шуңа күрә дә «күп булып киткән» дип, холестериннан бөтенләй «котылырга» омтылырга кирәкми, дөресрәге, ярамый: бары тик аны нормага китерү турында гына сүз бара. Әмма аның алышыну тәртибе бозылганда, канда күләме югары булып киткәндә кан тамырлары стеналарында шактый зур үзгәреш – атеросклероз башлана.

Хатын-кызлар канында холестерин ни сәбәпле арта соң?

Холестерин күрсәткече тиешле дәрәҗәдән югары күтәрелүнең төп сәбәпләре байтак: тәмәке тарту; физик активлыкның сүлпәнлеге; озак утырып эшләү; исерткеч эчемлекләрне еш куллану; шикәр чире белән авыру; нәселдә бу чирдән интегүчеләр булу; чамасыз симерү; кан басымы югары булу; ашказаны асты бизе авырулары; бавырда үзгәрешләр килеп чыгу.

Холестерол артуга китергән сәбәпләр арасында менопауза вакыты җитү дә бар. Бу чорда хатын-кыз организмында, гомумән, бөтен саклык функцияләре көчсезләнә.

Хатын-кыз бәби көткән чакта да шушы ук хәл күзәтелә. Булачак әни кеше организмында барган үзгәрешләр аркасында күп вакыт болай да үзен бик үк рәхәт хис итми, шуңа күрә кан тамырларына холестерол утыру белән бәйле төп проблеманы сизми калырга, күз уңыннан игътибар итмичә уздырырга да бик мөмкин.

Холестеринны төшерү өчен тәкъдим ителә торган җиләк-җимешләр

Башта ук искәртеп куям: бары тик җиләк-җимеш ашап кына холестеринны төшереп булмаячак. Бу проблеманы хәл итүгә бар яклап якын килергә кирәк: физик күнегүләр белән шөгыльләнергә, табиб билгеләгән даруларны кабул итәргә, бер үк вакытта булган башка авыруларны дәваларга, диета сакларга. Әмма кайбер ризыклар (моңа җиләк-җимешләр дә керә) организмда холестерин күләмен тиешле дәрәҗәдә тотуга тизрәк ирешергә булышачак.

Әгәр канда холестерин югары икән, әледән-әле авокадо ашарга кирәк. Бу җимештә фитостерин да, бета-ситостерин да бар.

Грейпфрут (кызылы), әфлисун һәм лимон кебек цитруслар да холестеринны төшерергә ярдәм итә. Әмма аларны чамадан тыш куллану зыян да салырга мөмкин.

Ананас канны сыеклата, кан басымын төшерә һәм аш кайнату белән бәйле процессларны җайга сала. Аңарда бромелаин кебек бик сирәк очрый торган матдә бар, ул исә майларны тарката, йөрәк тамырларында барлыкка килгән тромбларны «эретергә» сәләтле.

Файдалы сыйфатлары һәм составы ягыннан үзебезнең алма да читтән кайткан җиләк-җимешләрдән бер дә калышмый. Көнгә бер яки ике алма ашап кую да бик җитә. Аңарда булган пектин кан тамырларын чистартырга һәм аш кайнатуны җайларга сәләтле.

Холестеринның кандагы күләмен банан да төшерә ала. Әмма моның өчен аны даими рәвештә ашарга кирәк – бер генә атна, хәтта бер генә ай да түгел. Гаҗәпләнергә дә кирәкми, чөнки начар холестерин безнең организмда бер-ике ай эчендә генә тупланмаган бит.

Җиләк-җимешне көндәлек рационга кертү белән генә чикләнмичә, аларның без кабул иткән терлек майларын тулысынча алыштыруына да ирешергә кирәк.

Табиб киңәше

Холестерин күтәрелмәсен өчен, түбәндәге ризыклардан баш тартырга кирәк:

- майда кыздырылган, ысланган ризыклар;
- тәмләткечләр, соуслар;
- гөмбәләр;
- колбасалар;
- пешкән камыр әйберләре, макарон ризыклары;
- баллы, газлы эчемлекләр, шоколад;
- куе каһвә, чәй, какао;
- бик күп күләмдә консервантлар, ароматизатор кушылган ризыклар.



Фото: www.pixabay.com

Яз җитә, кызлар!

Барыбыз да түземсезләнеп язны көтә. Яз якынлашкан саен, көзгегә дә ешрак карыйбыз. Әмма... кайчак андагы чагылышыбыз белән үзебез күрергә теләгәне тәңгәл генә килеп бетми. Кышкы салкыннардан, усал җилләрдән арыган, төссезләнгән, кипшергән, җыерчыкланган йөз бага көзгедән. Әйе, кыш айлары бит тиресе өчен бик зур стресс. Язны тәүге чәчәкләрдәй балкып каршылар өчен, инде бүгеннән үк ныклап торып чарасына керешергә кирәк. Косметолог Эльвира КУЛИК безне бит тиресен дөрес итеп язга әзерләү һәм тәрбияләү чараларына өйрәтер. Әйдәгез, аның киңәшләренә колак салыйк әле.

Бит тиресен тәрбияләү дүрт төп этаптан тора. Болар: чистарту, тонусын күтәрү, дымландыру һәм тукландыру.

Чистартуның иң беренче һәм иң төп шарты – куллана торган препаратлар составында сульфатлар (лаурил һәм лаурет сульфатлар) булырга тиеш түгел. Әлеге матдәләр тиренең картаюын тизләтә, аның саклагыч функцияләрен боза, тиренең ялкынсынуына, купшаклануына китерә. Хәтта аллергия дә башланырга мөмкин. Шуңа күрә битне чистарту чараларын сатып алганда, составына игътибар итегез. Иң яхшысы, аларны даруханәләрдән яки косметологтан сатып алу. Күпләр хәзер мицеляр су куллана. Аның белән чистарткannan соң, битне су белән юарга киңәш итәм. Мицеляр суның составында да тирене ярсыта торган матдәләр булырга мөмкин.

Тире коры һәм сизгер икән, косметик сөткә яки сөт өстенә тукталыгыз. Майлы яки катнаш тире өчен гель яисә мусс яхшырак.

Чистарту чаралары кулланып, битне көнгә бер-ике тапкыр бүлмә температурасындагы кайнаган яисә фильтрдан узган су белән юалар. Кечке юыну йокларга ике сәгать

алдан башкарыла. Иртән исә фәкать тоник кына кулланыла. Тоник сыйфатында яшел чәй яки шифалы үләннәр төнәтмәсен сынап карарга була.

Тониктан соң, бит тиресенең торышына, үзенчәлегенә һәм яшенә яраклы крем кулланыла. Бит тиресе шешенмәсен өчен (отек), крем йокларга сәгать ярым-ике сәгать кала ягыла. Дымландыргыч үзлеккә ия көндезге кремны салкында урамга чыгарга сәгать ярым кала ягарга кирәк. Югыйсә салкын һавада бит тиресендә кызыл тимгелләр барлыкка килергә мөмкин.

Тиренең бер үзенчәлеге бар: язгы-җәйге чорда аның төре үзгәрүчән. Кыш көне коры булса да, көннәр җылыта башлагач, май бизләре яхшырак эшли. Әгәр дә тиренең шушы үзенчәлеген сизсәгез, яз көне кремның моңарчы кулланганына якын торганын сайлагыз. Әйтик, моңарчы кремыгыз нормаль тире өчен булса, хәзер инде нормаль һәм катнаш тире өчен дигәнен алыгыз. Ләкин бу һәркем өчен индивидуаль. Нәкъ менә сезнең биткә нинди тәрбия чарасы кирәген фәкать косметолог кына дөрес итеп билгели ала. Матурлык базарында препаратлар гаять тә күп, үзегезгә кайсысы туры килүен сайлап алуы кыен. Тире – организмның бер органы, ул башка органнар белән тыгыз бәйләнештә. Бит тиресендә безнең сәламәтлегебез чагыла. Аны тәрбияли торган препаратларны сайлаганда да таләпчәнрәк булырга кирәк.

Тирене тәрбияләү алгоритмы шушы: чистарткан һәм тонусын күтәргән тирегә иртән – дымландыргыч, кич тукландыргыч крем ягыла. Кайчак иртән дә, кичен дә бер генә крем кулланыла. Ул дымландыра торганы да, тукландыра торганы да булырга мөмкин. Сывороткалар, концентратлар кулланып, кремның тәэсирен көчәйтә дә алабыз. Яз көне составында Е һәм С витаминнары, пантенол булган кремнарга игътибар итегез. Болар бик көчле антиоксидантлар. Алар тирене саклый һәм йомшарта.



Эльвира КУЛИК, косметолог:

– Яз көне бит тиресен кояш нурларыннан саклау да бик актуаль. Язгы кояш зарыктырса да, бит тиресе өчен ул файдалы түгел: сипкелләр, тутлар чыга башлый. Битне зарарлы ультрашәмәхә нурлардан саклар өчен SPF кремнар куллану зарурлыгы туа. Тональ кремнар куллану да тирене берникадәр кояш нурларыннан сакларга булыша.

Шулай ук язын организм витаминнар кытлыгы да кичерә. Әлеге халәттә яшел үләннәр, цитруслы җимешләр, яшелчәләр, үсемлек майлары, балык, оеган сөт ризыкларын күбрәк куллану булыша. Шулай ук суны да күбрәк эчәргә киңәш итәм.

Яз җиткәндә битнең төсе дә кәефебезне кыра. Ул соры, тышкы катламы калынайган (гиперкератоз), җыерчыклы, көпшәк... Бу проблемаларны пилинг ярдәмендә хәл итәргә мөмкин. Алар әчеле (кислотный) яки энзимлы була ала. Ә менә скраблар составында каты кисәкчәләр (абразив матдәләр) бар, алар тирене җәрәхәтләргә мөмкин. Шуның аркасында тире ялкынсына, кызара. Скраблар бөтен кешегә дә туры килми. Мин клиентларыма кремнар, сабыннар, маскалар алганда әчелеге аз булган препаратларны сайларга киңәш итәм. Алар гиперкератоз белән дә көрәшә, тирене тирәннән чистарта һәм аны профессиональ пилингка әзерли.

Әйткәнемчә, энзимлы яки ферментлы пилинглар да була. Алардагы актив матдәләр сыйфатында папайя, ананас, пептин, кофеин һәм башкалар кулланыла.

Пилингларны еш кулланырга ярамый. Югыйсә тире артык корырга, аның саклагыч функциясе бозылырга мөмкин. Өй шартларында 7–10 көнгә бер генә рөхсәт ителә.

Салондагы процедураларга килсәк, кыш азагы, яз башлары – пилинглар ясау төгәлләнә торган вакыт. Инде хәзер төп игътибар тиренең ресурсларын тулыландыруга юнәлдерелә. Әлеге процедураларның максаты: тирене витаминнар белән баету, тиешенчә дымландыру. Яз көне иң популяр процедуралар – фракцион мезотерапия, микроток, аппарат ярдәмендә башкарылучы креотерапия, смас лифтинг, матурлык инъекцияләре.

Массажлар да бик актуаль. Алар төрле-төрле була: лифтинглы, буккаль, целлюлитны бетерә торган, лимфодренажлы... Массаж бит тиресе өчен пассив гимнастика ролен башкара, битнең овалын нормада тотарга булыша, кан һәм лимфа әйләнешен яхшырта.

Әмма шуны белегез: тире матур булсын өчен сәламәт яшәү рәвеше мөһим. Дөрес туклану, җитәрлек күләмдә су эчү, физик активлык – болар бар да тиренең сәламәтлегенә йогынты ясый. Күбрәк елмаегыз, үзегезне, якыннарыгызны яратыгыз. Кешене мәхәббәт яшәртә.

Белгеч киңәше

■ Коры һәм нормаль тире өчен дымландыргыч һәм тукландыргыч маска рецепты: өлгергән бананны изеп, 2 аш кашыгы сөт кушабыз һәм бит белән муенга 20–30 минутка ягабыз. Аннары җылымса сөткә манылган мамык белән сөртеп алабыз.

ЗАРАРЛЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЛӘШҮ СОРАЛА

Ак, борчак, плиссе – язгы мода быел шундый



Мода кабатланучан, диләр. Дөрес сүзләр. Менә быелгы – 2019 елгы язгы-җәйге сезонда да кабаттан 1970, 1980, 1990 нчы еллар модасы әйләнеп кайта диярсең. Мода белән бер адымда булу өчен нинди төскә, стильгә һәм нинди тукымаларга игътибар итәргә кирәклеге турында стилист Ләниза ЧИРСКОВА белән сөйләшәбез.

БЕЖ ТӨСЛЕ КҮН

Киемдә артык бернәрсә дә булмау – быелгы моданың бер үзенчәлеге. Мода белән бергә атлыйм дисәгез, гардеробыгызда беж төсендәге күннән тегелгән берәр кием булдырыгыз. Ул юка гына пальто да була ала, чалбар, блузка, хәтта күннән тегелгән күлмәк тә булырга мөмкин.

БАШТАНАЯК КРЕМ ТӨСЕ

Кием үзе нинди булуга карамастан – ирләр җилкәсеннән генә салдырып алган кебек мул пиджакмы, итәкләре киңәеп киткән идәнгәчә озын күлмәкме яисә йон тукымадан тегелгән затлы костюммы – анысы мөһим түгел, иң мөһиме: ул крем төсендә булсын. 2019 елның тенденциясенә чын-чынлап туры килим дисәгез, шушы төсне сайлагыз.

АК МИНИМАЛИЗМ

Очлы чабулар, туп-турыга кырт кисеп тегелгән җөйләр, артык бер генә деталь дә юк һәм монохромлылык – «Матрица» фильмын искә

төшерүче тагын бер минималистик тренд. Быел ак төс модада. Аның да кар кебек ап-ак төсмере.

ВИКТОРИАН ДӘВЕРЕ

Итәге идәнгә җитеп торган корсетлы күлмәкләр, фонарь җиңнәр, «ленточка»лар, «рюшечка»лар, челтәрләр – узган гасырларның борынгы нәфисслеге кабаттан модада. Үзен принцесса итеп тоясы килмәгән хатын-кыз юктыр, викториан стиле безгә шул мөмкинлекне бирәчәк.

ВЕЛОСИПЕДКАЛАР

Иң сәер һәм безнең өчен иң ят трендларның берсе, мөгаен, шушыдыр. Ничек кенә сәер булмасын, костюм белән уңышлы гына ансамбль тәшкил итә ала ул. Кыю модницалар өчен яхшы идея.

МОДАЛЫ БОРЧАК

Иң романтик образларны тудыручы борчак быел да модада. Ул теләсә нинди варинтларда да актуальлеген югалтмый бугай: аклы-каралы, каралы-аклы, хәтта чуары да! Быел җәй безнең күзләрне эреле-ваклы борчак иркәләр ахрысы.



Лениза ЧИРСКОВА, стилист:

– Бантиклы, корсетлы, амурлы-зефирлы Викториан стиле дә кабаттан бик актуаль. Ә шәрык бизәкләре торт өстендәге чия ролен башкарачак. Шәрык костюмнарына игътибар зур булырга охшаган.



ВАРЕНКА

1980 нче еллар модасының иң актуаль трендын искә төшерер өчен, шул чор фильмнарын тагын бер кат карап чыгыгыз әле. Пешкән деним – татарчага шулай дип тәрҗемә итик – быел кабат модада булачак. Урыны-урыны белән төсе уңа төшкән денимнан тегелгән комбинезоннар, пиджак, курткалар көтә безне.

КИҢ ИҢСӘЛӘР

1980 нче елларның модасы колачын киң салмакчы. Киң иңсәле блейзер, пальто кабат әйләнеп кайтачак.

КИҖЕ-МАМЫК ЧЕЛТӘР

Челтәрле күлмәкләрне борынгылык калдыгы дип санаучыларның фикере үзгәрер инде – киҗе-мамык челтәрләр быел кабат модада. Итәк очларына нәфис челтәр кайма тотылган «бәләкәй кызлар» күлмәкләре ала торсагыз да була.

ПЛИССЕ

Плиссировканы модадан чыгарып ташларга ашыкмагыз әле. Яңа сезонда «гармошка» иң төп трендларның берсе булачак.

СОЛДАТ КИЕМЕ

Көчле һәм гаярь кызлар баштанаяк хаки төсләренә төренә ала. Быел хәрби стиль кабат модада. Сезгә үрнәк – солдат Джеймс.

ШӘРЫК ӘКИЯТЛӘРЕ

Күп кенә дизайнерлар, сүз берләшкәндәй, язгы-җәйге яңа коллекцияләрендә көнчыгыш бизәкләренә өстенлек бирә. Катлаулы бизәкле яулык-итәкләр, челтер-челтер тәңкәләр тагылган билбаулар, бахрома, ком төсенең барлык төсмерләре – дизайнерлар шәрыкны әнә шулай тасвирлый.



Фото: www.pixabay.com

PRESSA

Тжвжик – әрмән ашы



Бүген җир шарында 12 миллион әрмән кешесе яши дип исәпләнә. Шунысы кызык: төп ватаннары булган Әрмәнстанда аларның нибары 3 миллионга якыны гына гомер итә. Россиядә исә 2 миллионга якын әрмән бар. Татарстанда алар 20 меңгә якын. Әрмән халкы дөньядагы иң борынгы милләтләрнең берсе буларак кына түгел, христиан динен дәүләт дине сыйфатында иң беренчеләрдән кабул итүчеләр буларак та билгеле. Һинд–Европа семьялыгына керүче әрмән теле дә – иң борынгы телләрнең берсе. Бу телдә кырыклап диалект бар. Әле бүген дә кулланылышта булган әрмән әлифбасы 1600 елдан бирле бер үзгәрешсез диярлек кулланылып килә.
Әрмән халкы белән аралашучылар аларның нинди кунакчыл икәнен белә булыр. Ул кунакчыллык турында хәтта легендалар яши. Аларның ышанулары буенча, кунакны күбрәк сыйлаган саен, йортка бәрәкәт иңә, бәхет арта икән. Әрмән кухнясы бөтен дөньяга билгеле дип әйтү дә һич арттыру булмас. Шашлык, хашлама, хаш, ламаджо... Кайнар көньяк халкына хас булганча, чак кына кырку, чак кына борычлы итеп, итен, яшелчәсен мул салып әзерли алар ризыкларны.
Журналыбызның бүгенге кунагы – Россиядә дистәләгән әрмән ресторany ачкан, Казанда унбер елдан артык шеф-повар булып эшләгән Самвел ПОГОСЯН, хатын-кызларыбызны бәйрәм белән тәбрикләп, әрмән милли ризыгы – тжвжик әзерләргә тәкъдим итә. Безнең телгә исеме катлаулырак тоелса да, әзерләве кыен түгел икән.



Кирәк

- 500 г йөрәк һәм бавыр (сарыкныкы);
- 100 г курдюк мае (аның урынына елкы мае да ярый. Бер дә булмаса, үсемлек мае куллана аласыз);
- 3 баш суган;
- 1 помидор;
- 1 сары төстәге баллы борыч;
- 1 зәһәр борыч;
- 1 тотам кинза, укроп, кыяклы суган;
- тәменчә тоз-борыч, төелгән кызыл борыч (паприка).



Фото: Анна Арахамия

Эш барышы

■ Курдюк маен ваклап турап, коры табага салып эретәбез. Майның яртысын икенче бер табага агызып, калганында саламлап туралган йөрәк белән бавырны кыздырабыз. Утны баштарак көчле итеп ачып торабыз, аннары киметәбез. Бавыр белән йөрәк 15 минут чамасы кыза. Артыгы кирәкми, югыйсә бавыр катып китә.

■ Ярымбоҗралап туралган суганны икенче табадагы майда кыздырабыз. Суган аллангач, янына ваклап туралган зәһәр борыч белән саламлап туралган баллы борычны кушабыз. Соңыннан ярымтүгәрәкләп тураган помидорны салабыз.

■ Табадагы яшелчәләр йомшарып киткәч (5–10 минут), кыздырылган йөрәк белән бавырны кушабыз. Тәменчә тоз һәм борыч, бер чеметем паприка сибәбез, бер дәфнә (лавр) яфрагы батырабыз. Анысы сарыкның үзгә тәмен киметер өчен кирәк. Яраткан кеше чеметеп кенә кипкән рәйхан (базилик) да өсти ала.

■ Табаны уттан алыр алдыннан гына яшел аштәмләткеч үләннәрне сибәбез. Берازын соңыннан бизәр өчен калдырырга мөмкин.

■ Тжвжик – әрмән ашы. Шуңа да аны табынга үзләренчә чыгарабыз. Зур сай тәлинкә төбенә зуррак шакмакларга бүленгән әрмән лавашы түшибез. Чит-читләренә матурлык өчен яшел салат яфраклары кыстырабыз. Лаваш өстенә тжвжикны өеп салабыз. Редиска белән кишердән чәчәкләр кисеп тә бизәргә була.

ХАШ – иң борынгы әрмән ризыкларының берсе. Туклыклы, хуш исле бу ашны гадәттә иртән бирәләр. Бер тәлинкә кайнар хаш – көне буена җитәрлек энергия һәм яхшы кәеф чыганагы.

Әзер терлек аягын тәүлек буе салкын суда тотып (суны 5-6 тапкыр алыштырасы), талгын утта 8 сәгать пешерәбез. Бернинди тәмләткечләр, хәтта тоз да салынмый. Сөякләрне шулпадан алып, итен аерып турыйбыз, шулпасын сөзәбез, кипкән петрушка белән укроп кушабыз. Итне тәлинкәләргә бүлеп, кайнар шулпа өстибез, туралган яшел аштәмләткеч үләннәр сибәбез. Иң ахырдан гына вак итеп уылган сарымсак өстәп чыгабыз. Хашны табынга лаваш белән бирәләр. Ә тозны һәркем кирәгенчә генә үзе сала.

23 МАРТ

17:00
ПИРАМИДА

ТАТАР МУЗЫКАЛЬ ТЕЛЕКАНАЛЫ

TMTV*

ПРЕМИЯСЕ

* "ТатМузТВ"

6+


297 43 77

ВСЕ БИЛЕТЫ KASSIR.RU



TATAR RADIOSI
сеть радиостанций



Рәсми партнер:



VIP – партнер:



Автопартнер:



Партнерлар:





РЕКЛАМА

Кучкар. Бер яктан, айның энергиясе уңай, икенче яктан, көчле энергия уйларны тупларга комачаулый да. Тәвәккәллегегез артыр, яңа эшкә керешсәгез, тиз иялəшерсез. Бәхәстән сакланыгыз.

Үгезбозау. Ай башы ыгы-зыгылар белән узар. Көтелмәгән чыгымнар булырга мөмкин. Ай урталарыннан энергия агышы үзгәрә, көчегез артуын, эшләрегезнең җайлануын тоярсыз. Кайберләре эшегезнең әҗере булыр.

Игезәкләр. Катлаулы ай. Ешрак сабыр итәргә туры килер. Акчаны юк-барга сарыф итми торыгыз, зур әйберләр сатып алу өчен кулай чор түгел. Моңарчы ышанычлы тоелган кешенең астыртын гамәленә юлыгуыгыз ихтимал.

Кысла. Һөнәри өлкәдә берникадәр киеренкелек күзәтелер. Чит вазыйфалар өяргә мөмкиннәр. Сабырлык күрсәтмәсәгез, эшегезне алыштырырга ук туры килмәгәе. Түземлелек әҗере коллективта абруегызның артуы булыр.

Арыслан. Вакыйгалар агышына күз иярми. Айның беренче яртысында бер мөһим мәсьәләне хәл итәрсез. Сезне ниндидер кысаларга кертергә, шартлар куярга телиләр. Ризалашканчы, барысын да ныклап уйлагыз әле.

Сөмбелә. Комфорт зонасыннан чыгарга туры килер. Әйе, бу кыен, ләкин гел кабыкка бикләнеп тә яшәп булмый бит. Гүя йокыгыздан айныгандай булырсыз, эш дәртегез артыр, яшәү көче бөтереп алыр.

Бизмән. Хисләрегезне йөгәнләргә тырышыгыз. Артык эмоцияләр аяк чалырга мөмкин. Ниндидер яңа хезмәттәшлек башланырга тора. Ул уңыш китерер. Гаиләгезгә күбрәк игътибар итү кирәк.

Чаян. Ай башы мәшәкатьләр белән ялкытса да, ай ахыры яхшы хәбәр, күңелле очрашу белән сөендерер. Акча белән сак эш итү сорала. Шулай ук яңа эшләргә дә алынмый торсагыз әйбәтрәк.

Укчы. Ыгы-зыгылы, киеренке чор. Уйламый эш итүдән сакланыгыз. Хискә бирелеп китә торган гадәтегез бар, аек акылны югалтмаска тырышыгыз. Ялганны чын дип ышандырырга тырышырлар, уяу булыгыз.

Кәҗәмөгез. Бу айның бөтереп ала торган энергиясенә ияреү кыенрак булыр. Әлеге чорда игътибарлылык икеләтә кирәк, чөнки вакыйгаларның тиз алышынуы зиһенне чуалтырга мөмкин.

Сукояр. Һөнәри осталыкка сынала торган чор. Мөһим мәсьәләләрне хәл иткәндә күкләрнең ярдәмен тойгандай булырсыз. Яңа проектларга курыкмыйча алыныгыз, бар да уңышлы булачак.

Балык. Киеренке вакыт – хисләр ташкыны күңелне ярсыта, вәсвәсәгә этәрә торган. Юк-барга игътибар итмәскә, тоткан юлыгыздан тайпылмый барырга тырышыгыз. Файдасы тиярдәй яңа танышыгыз барлыкка килер.

Зирәк кешедән – нәфис сүз

ИҢ КӨЧЛЕ ҺӘМ ИҢ КӨЧСЕЗ КЕШЕ

Борынгы заманнарда җир йөзендә бер падишаһ яшәгән. Көннәрдән бер көнне ул үзенең вәзиренә дәүләтләрендәге иң батыр һәм иң куркак, иң көчле һәм иң көчсез дүрт кешене табып китерергә кушкан. Бик озак эзләгән вәзир. Ниһаять, падишаһ каршына бер хатын-кызны китереп бастырган. «Мин синнән дүрт кеше табып китерүне сорадым, ә син бер хатынны җитәкләп килгәнсең», – дип ачуланган падишаһ. «Безнең илдәге иң батыр, иң куркак, иң көчле һәм иң көчсез кеше шушы була инде, – дигән аңа вәзире. – Бу ханым бик интегеп тугыз ай буе баласын йөрәге астында йөртте, ничә айлар юньләп ашамады-эчмәде, йоклый алмады, күңеле болганган вакытларда җаны да чыгар кебек иде – ул барысына да түзде. Тугыз айдан соң мең газап белән аны дөньяга тудырды. Тулгак ачысын кичергәндә ач бүреләр әчен умыра кебек тоелды, ләкин ул түзде. Димәк, бу ханым иң көчле кеше. Баласы тугач, ул аның бер тамчы күз яшен дә күтәрә алмас булды. Шулай булгач, аннан да көчсез кеше булырмы? Берзаман аның йөрәк парәсенә арысланнар өере ябырылды. Ул аларның бугазына үзе ябышты, җан көченә көрәште, сугышты – баласын саклап калды. Улмы иң батыр кеше түгел?! Син аның төннәрен баласы өчен дога кылып, Аллаһка ялварганын тыңласаң иде! Аның киләчәге өчен, исәнлеге һәм бәхете өчен бу хатыннан да ныграк курыккан кеше юк, баласы өчен ул дер калтырап тора».

Чынлап та шулай бит, баласы хакына хатын-кыз иң батыры, иң көчлесе һәм... аның күз яшьләре алдында иң көчсезе дә...

* * *

Без гомер буе Ана дигән хатын-кызга дан җырлыйбыз.

Муса Җәлил

Дөнья белән аналар идарә итсә, кешелек сугышларның ни икәнен белмәс иде.

Маргарет Филд

Ана йөрәге – төпсез упкын, аның төбендә һәрчак кичерү ята.

Оноре де Бальзак

Әтисез калган балага әтисен алыштыра алган әни – иң яхшы әни.

Иоганн Гёте

Ана мәхәббәте кодрәтле, шулкадәр табигый һәм ихлас. Ул бернәрсәгә дә бәйле түгел.

Теодор Драйзер

Кеше авызыннан чыккан иң матур сүз – әни сүзе.

Хәлил Джебран

«Хатын-кыз галәме» сәхифәсен әзерләүче – Лилия Гәрәева





ЧӘЧӘКЛӘРЕ ХУШ ИС ТАРАТА

Сәнгать тарихында шундый исемнәр бар: язмыш тарафыннан аларга гел беренчелек, гел яхшыларның да яхшысы булу язылган. Татарстан сынлы сәнгатендәге беренче профессиональ хатын-кыз рәссам Гайшә Рахманкулова – шундыйлардан.


1913 елда Башкортстанның Кырмыскалы районында туа. Крестьян гаиләсендә үскән Гайшә бәләкәйдән бөтен эшне белә, кечкенәдән кул арасына керә башлый. Алсуланып таң атулар, кичке шәфәкъ кызыллыгы, кышкы озын кичләр, көзнең җете буяулары Гайшә күңелендә туган як матурлыгына соклану булып языла. Ул күргәннәрен рәсемгә төшерә, балчыктан төрле сыннар әвәли. Автобиографиясендә мондый юллар бар: «8 яшькәчә авылда яшәдем, аннары әти-әнием мине Уфага укырга алып китте. 1931 елда без Казанга күчендек... Заводта эшләп, кичләрен стенография курсларында укыдым. Художество училищесына укырга кереп, 1941 елда тәмамладым, алга таба да укуымны дәвам итәргә теләдем, әмма сугыш комачаулады...»


Бөек Ватан сугышы елларында ул үзе язган агитплакатларны, лозунгларны промышленность объектларында элеп йөри. 1942 елда аны СССР Рәссамнар берлеге әгъзасы итеп алалар. Гайшә Рахманкулова – СССР Рәссамнар берлеге әгъзасы булган беренче хатын-кыз рәссам. XX гасырның 60 нчы елларына кадәр станоклы сынлы сәнгать техникасында эшли, аннары инде акварель буяуларга күчә. Иҗатында ике чор аеруча игътибарга лаек. Беренче чор, 1930 елдан 1961 елга кадәрге вакыт аралыгын колачлап, студент елларындагы сынлы сәнгать әсәрләрен үз эченә ала. Алар, нигездә, майлы буяулар белән эшләнгән портретлар, натюрмортлар, пейзажлар, жанрлы картиналар... Иҗатының икенче яртысына караган чор исә акварель буяулары белән җәлеп итә. Күпләр акварельне бик гади, майлы буяулар кебек прогрессив түгел дигән фикердә. Чынлыкта акварель техникасы шактый катлаулылардан исәпләнә, аңарда осталыкка ирешү өчен күп укырга, күп өйрәнергә кирәк. Ул вакытлар узгач кына рәссам алдында чикләнмәгән мөмкинлекләр ача. Аны аңлар-тояр өчен вакыт, кыюлык, түземлек һәм күп кәгазь кирәк. Акварельне еш кына алдан ни буласын белеп булмый торган техника дип тә йөртәләр. Өстенлеге һәм катлаулылыгы да шунда. Анда төзәтүләр кертү мөмкин түгел. Акварель – менә хәзер кулланыла торган буяу – ничек салсаң, шулай языла. Ул җай гына җәелеп, башка төсмерләргә үтеп керә һәм гаҗәеп төсләр күчешен хасил итә. Ярымтоннарның үтә нечкә нюансларын акварель генә шулай җиткерә ала. Халык авыз иҗатын тирәннән белү, туган як турында матур истәлекләр картиналарында поэтик символиканы калку итеп бирергә, аларның яңгырашын җиткерергә ярдәм итә. Шуңа да натюрморттагы чәчәкләр җәй хуш исен тарата кебек. 1974 елда Гайшә Рахманкулова – ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе исеменә, ә 1984 елда ТАССРның халык рәссамы дигән мактаулы исемгә лаек була.

Рәссамның эшләрен Татарстан Республикасы музейларында күрергә мөмкин. Ә инде сынлы сәнгать әсәрләренә битараф булмасагыз, «Ренессанс» антиквар салонынннан картиналарын сатып та ала аласыз.

Рәмзия КАШАПОВА

16+ РЕКЛАМА ХОКУКЫНДА









Фото: Елена Сунгатова



ГАЙШӘ РАХМАНКУЛОВА

8 Март безнең өчен һәрчак яз, кояш, чәчәкләр, әниләрнең балкып елмаюы, болай да серле хатын-кызларның тагын да чибәрләнеп китүе, сылу кызларның шаянлык, наз тулы күзләре булып күңелгә кереп калган.
Елның иң якты, иң җылы, иң нәфис көнедер ул. Гөлләргә күмелгән, елмаюларга төренгән бәйрәмне башкача атап та булмыйдыр!
Шул гүзәлләрне сөендерер өчен без – ир-егетләр әллә нинди могҗизалар тудырырга да әзер! Дөньябызны ямьгә, җаныбызны назга төреп, якты йолдыз кебек балкучы илаһи затлар, иң кадерле кешеләребез!
Матур бәйрәмегез котлы булсын! Бәхеткә тиенеп, яратып һәм яратылып яшәгез!

«Ренессанс» салоны директоры
Адел ФӘЙЗУЛЛИН

Салоннарның адресы:
■ Казан шәһәре, Бауман ур., 44 нче йорт, «Родина» мәдәни-күңел ачу үзәге, 1-2 нче кат.
Эш вакыты: 10–19.

■ Казан шәһәре, Н. Ершов ур., 1 нче А йорт, «Корстон» кунакханә, сәүдә һәм күңел ачу комплексы, 1 нче кат.
Эш вакыты: 10–22.

www.antik-renessans.ru
Инстаграм: antiksalon

16+

Ренессанс®





РЕКЛАМА